**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГАПОУ «АРСКИЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ КОЛЛЕДЖ ИМ. Г.ТУКАЯ» -
РЕСУРСНЫЙ ЦЕНТР ПО ПОДГОТОВКЕ НАЦИОНАЛЬНЫХ КАДРОВ**

# Татар “Әлифба” сы авторы Вагыйзов Сәләй Гатат улының 115 еллыгына багышланган I Республикакүләм Вагыйзов укулары конференциясе материаллары

# Материалы республиканской научно-практической конференции «I Вагизовские чтения», посвященной 115-летию автора татарской «Алифбы» Вагизову Салею Гататовичу




**АРСК, 2023 ГОД**

**УДК 373**
**ББК 74.1, 74.2**

**Составители:**
**Тухфатуллина А.Г.** – зам. директора по национальному образованию ГАПОУ «Арский педагогический колледж имени Г.Тукая», к.ф.н., преподаватель высшей квалификационной категории.
**Гарашнина Р.М.** – заведующий ресурсным центром ГАПОУ «Арский педагогический колледж им. Г. Тукая», преподаватель высшей квалификационной категории.

**Научный консультант, редактор:**
**Шамсутдинова Р.Р. -** кандидат филологических наук, доцент КФУ, заведующий кафедрой ИРО, Заслуженный учитель РТ, Заслуженный работник высшего образования РФ

**Ответственный за выпуск:**

**Яруллина А.Р.,** зам. директора по научно-методической работе ГАПОУ «Арский педагогический колледж имени Г.Тукая», к.п.н., преподаватель высшей квалификационной категории.

**Технический редактор:**
**Гумеров И.А. - инженер-программист**

**Материалы республиканской научно-практической конференции «I Вагизовские чтения», посвященной 115-летию автора татарской «Алифбы» Вагизову Салею Гататовичу** (7 ноября 2023 года, Арск). - Арск, 2023. - Вып. 1, - 307 с.

Материалы публикуются в авторской редакции. За содержание ответственны авторы публикаций.

# СЕКЦИЯ 1. ОТРАЖЕНИЕ НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУРНЫХ ТРАДИЦИЙ В ТРУДАХ ВАГИЗОВА С.Г.

# 1 НЧЕ СЕКЦИЯ С. Г. ВАГЫЙЗОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ МИЛЛИ МӘДӘНИ ТРАДИЦИЯЛӘРНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Арсаева Лилия Равил кызы,*
Арча муниципаль районы, «Хәкимов Д.Г исемендәге
Түбән Мәтәскә урта гомуми белем
мәктәбе», башлангыч класслар укытучысы
*Арсаева Чулпан Тамир кызы,*
Арча муниципаль районы, «Арча 3 нче башлангыч
гомуми белем мәктәбе - балалар бакчасы»,
озынайтылган көн төркем тәрбиячесе

## ХАЛЫККА ХЕЗМӘТТӘ ҮТКӘН ГОМЕР

Аннотация: Каюм Насыйри исемендәге премиясе ияләре Сәләй Вагыйзов һәм Рәмзия Вәлитова иң яхшы «Әлифба» авторлары. Алар көче белән 40 тан артык фәнни хезмәт язылган. Шулар арасында «Уку китаплары», «Татар теле» дәреслекләре, «Рәсемле әлифба», «Язу» һәм «Матур язу» дәфтәрләре, методик кулланмалар, дидактик материаллар, грамотага өйрәтү таблицалары бар. Бу хезмәтләр үзләренең төгәллекләре, камиллекләре белән аерылып торалар.

Ачкыч сүзләр: Сәләй Гататович Вәгыйзов, Рәмзия Гыйләҗевна Вәлитова, «әлифба», «Башлангыч сыйныфларда татар теле укыту методикасы», методик әсбаплар

Профессиональ осталык баскычының иң югары басмасына менә алучы, методик алымнарның иң нәтиҗәлеләрен, яңаларын кулланучы, үзенең яраткан эшенә чын күңелдән бирелеп, эшләү дәверендә укыту-тәрбия эшләрен бертуктаусыз камилләштерү нәтиҗәсендә могҗизалар тудыра белүче, тирән белемле, киң эрудицияле, кече куңелле, олы йөрәкле, әһәмиятле бурычларны хәл итәргә, башкаларны рухландыра алучы һәм үз артыннан әйдәп баручы гыйлем диңгезеннең тирәнлекләрендә йөзергә өйрәтүче һәм фән-белем биеклекләренә менү өчен сынмас канатлар куючы мөгаллимнәр бар.

Шундыйларның берсе – изге зат Сәләй ага. Галим, мөгаллим, бөек, хөрмәтле, тирән ихтирамга лаеклы кеше.

Вагыйзов Сәләй Гататович 1908 нче елның 20 нче октябрендә Самара губернасы Татар Байтуганы авылында туа. Аңа 6 ай булганда әтисе һәлак була, әбисе аны әнисенә бирми, үзенә алып кала. Әбисе укымышлы була, сабый беренче китапларын анда укый.

Тырыш малай бераз үсә төшкәч Камышлыга крестьян яшьләр мәктәбенә укырга китә. Укуга бөтен көчен сала. Малай шигырьләр яза башлый. Шул чорда Богырыслан рус педагогия техникумында мордва, татар бүлекләре ачыла. Сәләй шунда укый башлый. Аңа анда озак укырга туры килми. Татар теле һәм әдәбият

укытучысы Закиров аны Оренбургка татар-башкорт агропедагогия институтына укырга җибәрә.

Язмыш җилләре аны Казанга китерә. 1933 нче елда Казан педагогия институтының филология факультетына укырга керә. Ул институтны «5» ле билгеләренә генә тәмамлый.

1937 нче елда тормыш иптәше Вәлитова Рәмзия Гыйлаҗевна белән Арча педагогия училищесына эшкә килә һәм тәҗрибәле, көчле, дус коллективка эләгә.

Тирән белемле, акыллы укытучылар профессиональ уңышларга ирешә. Укыту-тәрбия эшләрен камилләштерү өстендә даими эшлиләр. Шәкертләрен татар телен сакларга, яратырга, хөрмәт итәргә өйрәтә.

1960 нчы елларда, яңа дәреслеккә ихтыяҗ туа. Моңа кадәр хәреф танырга өйрәткән Габбас Сайфуллин «Әлифба»сын алыштыру зарурлыгы килеп баса. Мәгариф министрлыгы әлеге эшне башкарып чыгарлык кешеләрне барлый башлый. Республика күләмендә конкурс игълан ителә, махсус боерык белән «Әлифба»ның яңа вариантын булдыруга тартылган педагоглар арасында Арча педагогия училищесы укытучылары Сәләй Вагыйзов һәм Рәмзия Вәлитова да була.

«Әлифба» дәреслеге 1960 нчы елда төзелә башлый. Сәләй Вагыйзов һәм Рәмзия Вәлитова 20 гә якын халыкның әлифбаларын бик җентекләп өйрәнәләр, шуларның иң камил якларын үз дәреслекләренә кертәләр. Авторлар рәссам Иван Язынинга да консультант булалар. Авторларга конкурс аша үтәргә кирәк була. Жюри әгъзалары Арча җирендә туган әлифбаны сайлап ала. Сәләй Вагыйзов һәм Рәмзия Вәлитова төзегән әлифба икенче урын ала. Россияда әлеге дәреслек бизәлеше буенча беренче урынга лаек була. 1965 нче елда мәктәпләрдә балалар кулына барып ирешә. Ул эчтәлеге белән дә, матур төсле рәсемнәре белән дә үзенә тартып торган зәңгәр тышлы әлифба. Шуннан башлап «Әлифба» ел саен меңләгән тираж белән 50 ел буена басылып тора. Сәләй Гататович Вагыйзов һәм Рәмзия Гыйлаҗевна Вәлитовалар авторлыгындагы «Әлифба» белән үзебез укыдык.

4 еллык башлангыч мәктәп системасына күчү дә яңа әлифба таләп итте. 6 яшьлекләр өчен төзелгән әлифба заман балаларының кызыксынуларына туры килерлек – экияти-фольклор мотивларына, милли компонентларга бай.

Мәгарифтә зур тәҗрибә җыеп, Вагыйзов һәм Вәлитова «Башлангыч сыйныфларда татар теле укыту методикасы»н да язганнар. Аның беренче басмасы 1975 нче елда монография рәвешендә язылган . Ә яңа басмалары (1993, 2000 елларда) шактый камилләштереп методик дәреслек итеп бастырылган. Инде берничә дистә еллар дәвамында шушы китап Татарстанда һәм Россиядә башлангыч сыйныф укытучылары әзерләүче барлык уку йортларында да дәреслек булып хезмәт итә. Ул укытучыларның өстәл китабына әверелде. Татар теле тарихында «Кызыклы грамматика» китабы да алар тарафыннан эшләнде. Бу китаптан башлангыч сыйныф укучылары гына түгел, ә барлык татар теле һәм әдәбияты укучылары да киң файдалана.

Сәләй абый һәм Рәмзия апа көче белән 40 тан артык фәнни хезмәт язылган. Шулар арасында «Уку китаплары», «Татар теле» дәреслекләре,

«Рәсемле әлифба», «Язу» һәм «Матур язу» дәфтәрләре, методик кулланмалар, дидактик материаллар, грамотага өйрәтү таблицалары бар. Бу хезмәтләр үзләренең төгәллекләре, камиллекләре белән аерылып торалар. Бу фәнни хезмәтләре өчен аларга 1988 нче елда Каюм Насыйри исемендәге премия бирелде. Латин графикасына нигезләнгән уку һәм язу китабын бастырып, милли мәгарифебезне галимнәр тагын бер баскычка күтәрде. Бу дәреслек латин, татар һәм рус язуы үзенчәлекләрен исәпкә алуы белән дә кыйммәтле.

С. Вагыйзов – Татарстанның атказанган укытучысы, РСФСР халык мәгарифе отличнигы, татарлар арасында беренче булып Ушинский медаленә лаек булган кеше. Рәмзия Вәлитова да – Татарстанның атказанган укытучысы.

Соңгы елларда төрле авторлар тарафыннан әлифба дәреслекләре шактый иҗат ителде. Иң соңгыларының берсе булган «Әлифба» дәреслеге Сәләй ага һәм Рәмзия апа методикасына нигезләнеп төзелгән. Белгечләр әйтүенчә, озак вакыт, төрле алымнар кулланып эшләп караганнан соң, нәкъ менә берничә буынны белемле иткән әлифба иң уңайлысы дип табылган. Бары тик, уллары Камил абый рөхсәте белән, кайбер сүзләр, рәсемнәр генә алыштырылган.

Озак еллар хәреф таныргa, укырга өйрәткән әлифба дәреслегенең авторлары Сәләй Гататович һәм Рәмзия апа Вәлитованы, аларның хезмәтләрен онытырга хакыбыз юк, алар безнең горурлыгыбыз.

Кулланылган әдәбият

1. Моратова Р.Ә., Исхакова М.Ә., Татарстан, 1999, №9
2. Саттарова Н., Вагыйзов Сәләй Гататович, Казан, 1998. – 24 бит
3. Таҗиев Д.Г. Арча хәбәрләре, 29.09.2023 №38. – 8 бит
4. Фәйзрахманов Ә. Мәдәни җомга, 27.04.2018, №16
5. Бармак белән каткан җирне казып булмый, Әлифбасыз язып булмый file:///C:/Users/KP/Desktop/3832455ba228ba89c3-%D0%9C%D1%83%D1%80%D1%82%D0%B0%D0%B7%D0%B8%D0%BD%D0%B0%20%D3%99%D0%BB%D0%B8%D1%84%D0%B1%D0%B0.pdf

# СЕКЦИЯ 2. ТРАДИЦИИ И ИННОВАЦИИ МЕТОДИЧЕСКОГО НАСЛЕДИЯ ВАГИЗОВА С.Г. (ЭВОЛЮЦИЯ «АЛИФБЫ»)

# 2 НЧЕ СЕКЦИЯ С. Г. ВӘГЫЙЗОВНЫҢ МЕТОДИК МИРАСЫНДА ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ИННОВАЦИЯЛӘР ("ӘЛИФБА" ЭВОЛЮЦИЯСЕ)

Гайнетдинова Алсу Азатовна
МБОУ "Нижнеметескинская СОШ имени Д.Г.Хакимова"

## С.Г.ВӘГЫЙЗОВ МЕТОДИК МИРАСЫНЫҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ИННОВАЦИЯЛӘРЕ

Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова - татар телен өйрәтүче әлифбаның тәүге авторлары. Китап үзгәреп торган, 41 тапкыр тулыландырылган, аның буенча татарстанлыларның 3 буыны укыган. Җир йөзендә кем генә булмасын, кайда гына эшләмәсен, ул зур дулкынлану белән үзенең нәни кулларына тәүге тапкыр Әлифба алганын искә төшерә. Чөнки һәркемнең дә белем дөньясына беренче адымы Әлифбадан башлана. Димәк, Әлифба китабы озын гомерле, тирән мәгънәле, бәһасез байлык ул.

Сәләй Гататдин улы Вагыйзов 1908 елның 24 октябрендә Самар губернасы, Богырыслан өязе (*хәзерге* Самар өлкәсе Камышлы районы) Татар Байтуганы авылында туа. Башлангыч белемен мәдрәсәдә ала. Камышлыда Коммунистик яшьләр мәктәбендә укый. 1921 елда Богырыслан педагогия техникумына укырга керә. Шул чорда шигырьләр яза башлый.

1933 елда Казанның педагогия институтында филология факультетында укый башлый. Институтны бетергәч, аспирантурада калдырала. Шуннан соң Арча педагогия училищесына эшкә чыкырыла. Ватан сугышы башлангач, фронтка китә. Харковь янында булганда чолганышка эләгә һәм әсирлеккә алына. Аннан АКШ гаскәриләре коткара. Туган иленә кайткач, Печора лагерена озатыла.

Әсирлектән 1949 елда гына азат ителә. Әсирлектән азат ителгәч, балалар тәрбияләү эшен дәвам итә. Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова минем туган авылым Югары Мәтәскә авылының башлангыч мәктәбендә дә балалар укытканнар. Алар минем әбием Ахунова Хөмәйрәдә квартирада яшәгәннәр. Алар турында истәлекләр сакланган. Аннары мәгариф булегендә инспектор булып эшли башлый. Арча педагогия училищесында татар теле һәм әдәбиятын укыта, бу фәннәрне укыту методикасын өйрәтә.

37 тапкыр дөнья күргән «Әлифба». Авторлар: Р. Вәлитова, С. Вагыйзов. Рәссамы – 1960-елларда беренче «Әлифба» китабын төзи башлый. 1965 елда «Әлифба» дөнья күрә.1986 елда хатыны Рәмзия Вәлитова белән берлектә 6 яшьлек балалар өчен тагын бер «Әлифба» төзи. Бу әлифба белән шәхсән үзем укырга өйрәндем. Аның «Башлангыч сыйныфта татар телен укыту методикасы» китабы «Лингводидактиканың ин зур казанышы» дигән бәя ала.

Сәләй Вәгыйзов төзегән уку китаплары, татар теле дәреслекләре, «Рәсемле әлифба», «Кызыклы грамматика» китаплары, методик кулланмалар һ. б. дистәләгән еллар дәвамында хәзерге көнгә кадәр кулланыла.

С.Г.Вагыйзов – Татарстанның атказанган укытучысы, Россия Федерациясенең Халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты. Ушинский медале белән бүләкләнгән.

Татар мәгарифе тарихында әлеге шәхеснең үз урыны бар. Сәләй аганы “татар Әлифбасы атасы” дип атау, бер яктан, бик үк дөрес тә түгелдер. Чөнки аңа хәтле татарның алты Әлифбасы булган. Беренчесе – Иман шарты. Аннан соң Сәгыйть Хәлфин, Әхмәтһади Максуди (ике Әлифба), Мөхетдин Корбангалиев, Габбас Сәйфуллиннар Әлифба китаплары язалар. Сәләй Вәгыйзов Әлифбасы иң озын гомерле булганга, мин аны Әлифба атасына тиңләдем.

1965 елдан башлап татар баласы 50 ел буе нәкъ менә Сәләй ага һәм аның тормыш иптәше Рәмзия апа язган Әлифба буенча укырга, язарга өйрәнгән. Дамир Таҗиев әйтүенчә, чит илләрдә яшәүче татар балалары әле бүген дә нәкъ менә шушы Әлифбаны кулланалар икән.

Петербургның бер галиме бөтен дөньядагы Букварь һәм Әлифбалар буенча докторлык диссертациясе язган булган һәм нәкъ менә Сәләй ага Әлифбасын иң яхшысы дип аерып куйган. Бу Әлифба 50 ел эчендә 40 мәртәбә басыла. Беренче басмасы, әйткәнемчә, 1965 елда чыга, Әлифбаның гомуми тиражы исә миллионнан артып китә. Моннан тыш Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова-Вәгыйзова татар телен өйрәнү методикасы буенча 43 китап язалар.

Сәләй Гататович туган авылына урау юллар белән генә кайта алды. Әгәр Нурания ханым Абзаловабу хакта район үзәгеннән ишетеп кайтмаса, белмим, авыл уртасында, аның нигезендә бүген музей-йорт балкып утырыр идеме икән? Бу изге җиргә сукмак бер дә өзелми хәзер. Самара өлкәсеннән, Татарстаннан, күрше төбәкләрдән, тагын әллә кайлардан килеп чыгалар. Балалар да бу бәйрәмгә җентекләп әзерләнә. Сәләй агаларына, Әлифбага багышланган шигырьләр дә күп. Язучылар, журналистлар авылларына еш килеп чыга бит. Иҗат кешесендә хисләр уятмый калмый бу җирлек. Нурания дә, апасы Гөлфия дә, Самарадагы медучилищены тәмамлап, туган авылларында фельдшер булып эшләгәннәр. Авырулар янына гел йөреп торырга туры килә бит инде. Шул уңайдан Гөлфия ханым Әлифбага кагылышлы бер кыйсса сөйләгән иде. – Бервакыт шулай бер яшьлек сабый авырып киткән. Өйләренә чакырдылар. Карыйм: бала кулына китап тотып ята. «Әлифба китабы бу, – ди әнисе. – Шуннан башка йокларга да ятмый. Башкасын биреп карыйбыз. Ничектер таный шуны. Иң кызыгы шунда: башкаларын бөгәрләргә, ертырга да мөмкин, ә Әлифбаны сыйпап кына тора. Үзебез дә аптырыйбыз инде», – ди. Тагын да гаҗәбрәге соңрак булды. Ул көнне сеңлем Нурания эш белән район үзәге Камышлыга киткән иде. Шунда очраклы гына Әлифба авторы Сәләй Вәгыйзовның авылдашыбыз икәнен белеп кайтты. «ТНВ»дан аның юбилеена багышланган тапшыру күрсәткәннәр икән. Кемдер аңа шул хакта сөйләгән. Минем йортым ни хәлдә? Әлифба музее ачылуга менә шушы бер җөмлә этәргеч булгандыр дисәм, мөгаен, ялгышмамдыр. Нурания укырга кергән елны Татар Байтуганында татар мәктәбе ябыла. Татар балалары, елый-елый, Рус Байтуганына юл тота. – Мәктәптә бер сүз дә татарча әйтергә ярамады. Укытучылар бик ачуланалар иде, – дип искә ала Нурания ханым бу көннәрне. – Ярый әле өйдә татар мохите булды. Илһам Шакиров белән Әлфия

Авзалова авылга килеп концерт куйгач, мин бик җитди кыяфәттә: «Казанга укырга барам», – дип игълан иттем. Әни: «Кая барасың? Татарча белмисең бит», – дигәч, үксеп-үксеп еладым. 1975 елда мәктәп укучылары арасында Самара өлкәсе буенча үткәрелгән «Ватан нидән башлана?» дигән иншалар бәйгесендә Нурания беренче урынны ала. Аның күз яшьләре белән язылган иншасы «Шуршат страницы Алифбы» дип атала. Монда ул шушы кадерле китаптан хәрефләрне өйрәнә, мәктәптә туган телендә сөйләшә алмавы турында йөрәгеннән чыккан сүзләрне тезә. Ул вакытта Әлифбаның авторы Сәләй Гататовичның үз авылыннан булуы башына да керми әле. Әйтүче дә булмый. Күрәсең, онытыла төшкәндер. Бу хакта белгәч, озак уйланып йөри Нурания. Ахыр чиктә Арча педагогия көллиятенә хат юллый. Сәләй ага шунда эшләп иҗат иткән бит. Авылдашы аңа үзе җавап яза. Нурания ханым күп уйлап тормый, ире һәм тагын бер укытучы белән Арчага юл тота. – Инде 30 елдан артык авылын кайтып күрмәсә дә, бер тыкрыгын да онытмаган. Туган йорты төшләренә кереп йөдәтә икән. Барысын да күреп китү теләге белән яшәгән ул. Тик, ни кызганыч, насыйп булмаган. Ул вакытта аңа 91 яшь иде инде, – дип искә ала Нурания ханым. – Сәләй ага безне: «Минем йортым ни хәлдә икән?» – дигән сорау биреп, күз яшьләре белән озатып калды. Шул мизгелдән бу сүзләр миңа тынгылык бирмәде. Аның нигезендәге соңгы чиккә җиткән ташландык йортны күргән саен, йөрәгем сыкрады. Яшен тизлегендә Ул вакытта вакыйгалар үзем өчен дә, ничектер, яшен тизлегедәй үтә торды. Бер сабакташым миннән яңа нәшер ителгән Әлифба дәреслекләре турында язуымны үтенгән иде. Кайчандыр Арча педучилищесында укуымны күздә тоткандыр инде, күрәсең. Язмам басылуга, педучилищеның элеккеге директоры Илдус абый Сәгъдиев шалтыратты. «Мәкаләңне укыгач, уйга калдым әле. Безнең Рәмзия апа белән Сәләй ага ничектер онытыла, күләгәдә калып бара сыман», – диде ул. Тиз генә җыендым да Арчага юл тоттым. Әлифба музеена кереп, укытучыларымның язмышы белән тагын бер кат таныштым. Яздым. Озак та үтми, Арча көллиятендә үткәрелгән бер конференциядә Әлифбага һәйкәл кую турында тәкъдим ясаганнар. Ачылу тантанасына Сәләй аганың авылдашлары да килде. Байтуганда музей ачарга хыялланып йөргән Нурания ханымга шунда Разил Вәлиев эшлекле тәкъдим ясый: Сәләй аганың авылдашлары исеменнән Татарстан Президентына мөрәҗәгать итәргә. Әнә шулай күмәк көч белән музей-йорт сафка баса.

Гыйләҗева А.Ф., Шаһиева Д.Г.
Арча ш., ДАҺБУ “Г.Тукай исемендәге
Арча педагогия көллияте”,
татар теле һәм әдәбияты укытучылары

## “ӘЛИФБА” – БАШЛАНГЫЧ БЕЛЕМНЕҢ НИГЕЗЕ

**Аннотация:** В статье описывается об “Әлифбе” С.Вагизова и Р.Валитовой. Раскрывается его значимость не только в обучении грамоте, но и в воспитательной работе. Букварь послужил татарскому народу более 40 лет. На

сегодняшний день учителя родного (татарского) языка признают лучшим учебником для 1-х классов.

**Ключевые слова:** Алифба, обучение, родной язык, воспитание детей, обучение грамоте.

Белем Әлифбадан башлана! Әйе, сагынып искә алырлык хатирәләр белән генә күңелләребездә сакланып кала – Әлифбалы балачак. Сабый чакның иң гүзәл мизгелләре кадерле Әлифба китабы белән бәйле. Белем генә түгел, тормышыбызның иң мөһим башлангычына да ачкыч булып тора ул. Адәм баласының киләчәге дә шушы Әлифбаны кулына алу белән хәл ителәдер. Нинди һөнәр үзләштерәчәк ул, кем булачак, үзен кем итеп күрергә тели сабый, шушындый күп сорауларга шушы китаптан җавап табыладыр да инде. Бу китап белән тормыш юлыбыз башланып китә. Шуңа күрәдер дә аның тышындагы рәсеме дә бик кадерле тоела. Зәңгәр тышлы Әлифба китабы...

Белем илен зур диңгез дип алсак, Әлифба китабы – шул диңгездәге юл күрсәтүче якты маяк, бары уңышларга гына илтүче туры юл сыман. Шул белем диңгезенә ак хыялларыбыздай ак кораблар белән без сәяхәткә чыктык һәм әле дә шушы олы катлаулы юлдан барабыз да, барабыз. Бүген дә ул якты хатирәләр белән һәркемнең исендә сакланадыр...

“Әлифба” – грамотага өйрәтү өчен төп дәреслек, баланың туган телендә беренче уку китабы. Грамоталылыкның башлангыч нигезе әлифба чорында салына. Мәктәптә укуның беренче айлары бала тормышында аеруча әһәмиятле. Ул башта укырга-язарга өйрәнеп кенә калмый, билгеле бер күләмдә белем һәм күнекмәләр дә ала. Шул рәвешле, беренче сыйныф укучысын укырга өйрәтү белән беррәттән, татар теленең (туган телнең) төп берәмлекләре турында күзаллау барлыкка китерергә, балаларның акыл сәләтләрен үстерергә мөмкинлек тудыра.

С.Вагыйзов һәм Р.Вәлитовалар төзегән “Әлифба” дәреслеге күрсәтмәлелеккә бик бай: анда сюжетлы картиналар, логик күнегүләр, уен материаллары, башваткыч, табышмак, тел шомарткычлар да бар; сүз төзү схемалары да, укыр өчен читен булган кушылмалар да күрсәтелеп бирелгән. һәр рәсем, һәр сүз, һәр текст укучы өчен нинди дә булса тәрбияви әһәмияткә ия. Ул хезмәт, дуслык, бер-береңә ярдәм итү, белем алуга омтылыш, өлкәннәрне хөрмәт итәргә һәм башка бик күп сыйфатларга өйрәтә. Әлифба кушымтасында, сүз төзү өчен, кисмә хәрефләр белән иҗекләр, шулай ук аваз һәм иҗек анализы өчен, кисмә хәрефләрдән сүз төзү һәм логик күнегүләр өчен өстәмә рәсемнәр дә бирелгән. Башка әлифбалар белән чагыштырганда, үзенең рәсемнәренең матурлыгы, эчтәлеге белән дә аерылып тора. Чөнки бала рәсемгә карауга ук, ул аны аңлый, күз алдына китерә. Рәсемнән соң иҗекләргә аерылып куелган сүзләрне дә бала, “бармагын төртеп”, үзе укый ала. Чөнки бу әлифбаны төзегәнче, С.Вагыйзов белән Р.Вәлитова егерме милләтнең әлифбасын, кулланылышта булган татар әлифбаларын өйрәнеп чыгалар. Алар төзегән “Әлифба” 1964 нче елда конкурска тәкъдим ителә. 1965 нче елда басылып чыккан зәңгәр тышлы беренче әлифба Мәскәүдә халык казанышлары

күргәзмәсенә куела. Элекке СССР Министрлар Советы рәисе Гейдар Алиев игътибар белән зәңгәр тышлы “Әлифба”ның битләрен актара һәм үзе белән килгән мәгариф хезмәткәрләренә мәктәпләргә шундый сыйфатлы дәреслекләр кирәклеген әйтә. Шушы елдан башлап, татар балалары әлеге әлифбадан гыйлем юлына атлый. Бүгенге көндә дә без аны иң яхшы дәреслек дип саныйбыз. Татар телен укыту методикасы дәресләрендә дә бу әлифбаны кулланабыз, башкалары белән чагыштырабыз, алар белән эшләү серләренә өйрәтәбез.

“Әлифба”га, уку өчен махсус төзелгән текстлардан тыш, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән һәм танып белү эшчәнлеген формалаштыруга ярдәм итә торган шигырьләр, хикәяләр, табышмаклар кертелгән. Хәрефләрне өйрәнеп бетергәннән соң, уку сыйфатын арттыру максатыннан, дәреслек ахырында татар әдәбиятының кайбер классиклары (Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил) турында мәгълүмат, аларның шигырьләре, кечкенә хикәяләре, кызыклы әкиятләре  урнаштырылган.

Тагы шунысы әһәмиятле: әлифба чорларга бүленеп өйрәтелә. Әлифбагача чорда грамотага әзерлек чоры бурычлары куела. Монда уку хезмәте өчен зарур күнекмәләрнең нигезе салына. Әлифба һәм язу дәфтәрләре белән таныштырыла. Рәсемнәргә карап, җөмләләр төзергә, җөмләләрне сүзләргә аерырга, сүзләрдән җөмләләр оештырырга, сүзләрне иҗекләргә бүләргә, иҗекләрне авазларга таркатырга, авазларны дөрес әйтә белергә өйрәтелә. Бу эшләр, сюжетлы картиналар, әйбер яки зат рәсемнәре, төрле рәсемнәр ярдәмендә күрсәтмәле һәм мавыктыргыч итеп, уен формасында оештырыла. Әлифба чоры беренче тартык аваз, Л хәрефе белән укучыларны таныштырудан, шул хәреф ярдәмендә таныш сузыклардан иҗекләр, сүзләр, шул сүзләрдән җөмләләр төзеп укытудан башлана. Һәр яңа хәреф һәм шул хәреф белдергән аваз белән таныштыру сүзләргә анализ ясау белән дәвам итә. Әлифбадан соңгы чорда укучылар ирешелгән уку һәм язу күнекмәләрен ныгыту, шомарту һәм уку дәреслекләренә әзерлек бурычлары куела. Бу чорлар һәрберсе язу күнекмәләре бирү белән берләттән алып барыла. Язу дәресе вакытында да укучыларның укуы,аларның язу күнегүләре белән чиратлашып бара.

С.Вагыйзов белән Р.Вәлитовалар “Әлифба” белән бергә “Матур язу дәресләре” серләренә өйрәтү өчен, укытучыларга методик кулланма да төзегәннәр. Әлеге кулланма кече яшьтәге мәктәп балаларын язу күнекмәләренә өйрәтүнең методик алымнары белән таныштыра. Укытучыга ярдәмгә дә язу үрнәкләре һәм аерым дәресләр бирелә.

Уку өчен әзер хәрефләрне аваз мәгънәләре буенча тану, шул хәрефләр белән белдерелгән сүз һәм җөмләләрне тел тибрәтеп әйтү һәм укыганны аңлау җитә. Әмма язу өчен, болардан тыш, хәрефләрнең сурәтен төшерә – яза белергә, ягъни балада кул хәрәкәте күнекмәләре тудырырга кирәк. Язу дәресләрендә шулай ук сөйләм үстерү күнегүләре дә бирелә. Болар һәрберсе уйлап, исәпкә алынган.

Баланы язарга өйрәтә башлау белән үк, тиз язганда кулланыла торган күнекмәләрне эшкәртергә, дөрес утырырга, ручканы дөрес тотарга, дәфтәрне дөрес куя, язу процессында кул һәм дәфтәрне дөрес шуыштыра белергә өйрәтү

дә кирәк. Беренче көннәрдә һәр язу эшен бала зур эмоциональ киеренкелек белән башкара. Беренче уңышсызлык һәм хаталарны да бик авыр кичерә, чөнки укучы матур язарга теләсә дә анынча булып чыкмый, теләгән нәтиҗәләренә ирешә алмый. Укытучысының дөрес киңәшенә һәм язып күрсәтүенә карамастан, хатасын тиз генә төзәтә алмый. Тикмәгә генә, К.Насыйри “Матур язу – ярты гыйлем” дип язмаган. С.Вагыйзов та үзенең бу методик кулланмасына эпигрф итеп нәкъ тә шушы сүзләрне алган да инде.

Әйе, бүгенге көндә без баланың фикерләү сәләтен үстерә, эстетик тәрбия бирә, информацион культура тәрбияли, укытуның сыйфатын күтәрә, предметара бәйләнеш булдыруга ярдәм итә, укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уята торган төрле белем бирү чаралары кулланып эшләргә тырышабыз. Шулай да, нәрсә генә булса да, зәңгәр тышлы әлифба китабы, беренче битен ачуга ук, шушы чараларның бөтенесен үзенә туплаган дип әйтәсе килә. Ә иң мөһиме: бу әлифба аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, логик фикерләргә, дөрес тәрбия алырга өйрәтә. Туган телебез – татар теленең сүзлек байлыгын, мәгънәви һәм кулланылыш үзенчәлекләрен камил куллана белүне һәм ана теленең аралашу эшчәнлегендә үзенчәлекләрен өйрәтүне дә күздә тота, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телебезгә карата кызыксыну уята.

Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Вагыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы. – Тулыландырылган, яңартылган басма.- Казан: Мәгариф, 1993.- 415 б.

2. Вагыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Әлифба.- Учебник для трехлетней начальной школы.-“Мәгариф” нәшрияты.-Казан: Мәгариф, 1995.- 78 б.

3. Вагыйзов С.Г. Матур язу дәресләре: Башлангыч мәктәп укучыларына каллиграфик күнекмәләр булдыру: Укытуылар өчен методик кулланма.- Казан: 1999.-63б.

Каримова Л.И.
Агрызский район, МБОУ Терсинская СОШ АМР РТ
МБУ ДДТ “Радуга талантов” АМР РТ

## ИСТОРИЯ РАЗВИТИЯ БУКВАРЯ

**Аннотация:** Статья знакомит с историей развития букваря. В статье рассматривается взаимодействие времени и азбуки. Приводятся примеры, раскрывающие изменения азбуки со временем.

**Ключевые слова:** букварь, учебник, буквы, слово, звук.

**Annotation** The article introduces the history of the development of the primer. The article discusses the interaction of time and the alphabet. Examples are given that reveal the changes of the alphabet over time.

Key words: primer, textbook, letters, word, sound.

Букварь – первая учебная книга, которая попадает в руки ребёнка. С неё начинают обучение грамоте. По ней дети учатся читать и писать. Я расскажу о том, как создавались самые известные буквари, по которым учились дети нашей страны.

В давние времена дети тоже учились в школе, но читали они не по букварю, и писали они не в тетрадях. В старину буквы вырезали на деревянных дощечках, а писали в свитках, сделанных из бересты. Потом на земле появились книги. Сначала книжные листы делали из кожи животных, а позже их стали делать из бумаги.

Принято считать, что самый первый букварь в 1574 г. напечатал во Львове Иван Федоров, основатель книгопечатания на Руси.

Букварь Василия Бурцова был выпущен Московским печатным двором в 1634 году. Составлен букварь по образцу азбуки Ивана Федорова. Это первая русская азбука с иллюстрациями.

Известный русский педагог Ушинский в 1864 году издал учебник '"Родное слово". Он состоял из двух книг: "Азбуки" и "Первой после Азбуки книги".

Через восемь лет после "Родного слова" вышла в свет "Азбука", составленная Львом Толстым. В нее он включил маленькие рассказы на темы из жизни крестьян.

Букварь Тихомировых впервые был издан в 1872 году. Он был одной из главных книг, по которой дети постигали азы грамоты и счета.

В 1945 году был издан букварь Редозубова. В нем было 98 страниц. Этот букварь был классикой СССР. Буквари тех лет учили дружбе и были очень добрыми. Автор предложил свой порядок изучения звуков и букв.

Материалы располагались по этапам обучения грамоте:

1) знакомство с предложением, словом, слогом и звуком. Понятие о буквах. Знакомство с элементами письменных букв;

2) практическое изучение звуков и их буквенных обозначений;

В 1965 году выпустился новый букварь, тоже под редакцией Редозубова. В нем новые картинки, портреты Владимира Ленина и Юрия Гагарина. В создании этого букваря впервые приняли участие Академия художеств и советские писатели. Букварь отличался художественными текстами, красочными картинками. Написание букв несколько изменилось. Они стали более красивыми. Прописей не было. Писали в обычных тетрадях с косой линией и тремя горизонтальными полосками. Большое внимание уделялось подготовке к письму. Долгое время дети писали палочки, точечки, петли и крючочки простым карандашом. И лишь у кого хорошо получалось письмо, учитель разрешал пользоваться чернильной ручкой. Чернила наливали в чернильницу-непроливайку.

Образцы написания букв, находились на страницах букваря. На одной странице размещены предложения и слова, написанные печатными и письменными буквами. Звуковые схемы отсутствуют. В 1993 году появился

букварь Горецкого и Шанько. Букварь помогает учащимся усвоить печатные и письменные буквы и их звуковые значения, научиться читать слитно простейшие слоги и слова и правильно понимать читаемое, уметь читать и понимать небольшие тексты и писать простейшие слова и предложения. На страницах букваря появились звуковые схемы, загадки, ребусы и кроссворды. Предполагалось, что часть детей уже умели читать. Поэтому авторы ставили своей целью, расширить и пополнить знания детей по русскому языку и чтению.

Прописи дают правильные образцы письма, что способствует лучшему их написанию. Учебник и тетради идут в соответствии друг другу.

Букварь учил детей любить свою Родину и быть патриотами своей страны. Тексты подобраны интересно, носят воспитательный и познавательный характер. В учебнике много яркого, занимательного материала.

В букваре уже не показывают, как нужно писать буквы. Каждый урок чтения закрепляется на уроках письма. Большой выбор разных заданий на развитие речи, мышления, расширение словарного запаса детей.

С распадом СССР в начале 1990-х годов в системе образования произошли существенные изменения. Было принято решение об отмене единой системы учебников.

Наряду с букварем Горецкого, появились и другие буквари и азбуки, которые преследовали одну и ту же цель – обучать детей грамоте. В 2014 году стали учиться по программе «2100». Обучение грамоте происходило по букварю Бунеевых, который до этого назывался «Моя любимая азбука». Учебник очень красочный, дети с удовольствием работают в нем карандашами. В первый класс приходят дети разного уровня подготовки. Это большая проблема для учителя. "Букварь" решает ее. Он предназначен для работы с детьми, имеющими разные навыки чтения. В правой части учебника размещены тексты для читающих детей, поэтому у учителя есть прекрасная возможность спланировать урок так, чтобы все дети были охвачены работой, и никто не скучал. Этот учебник развивает и совершенствует навык чтения, содержит материал вводного курса русского языка, развивает речь и творческие способности детей. Он интересен учащимся, так как есть занимательный, познавательный материал, а также возможность поработать самостоятельно.

Букварю соответствуют прописи «Мои волшебные пальчики» в 5-ти тетрадях (автор Пронина). Дети в них учатся писать и в узкую линейку, и в широкую. В прописи так же, как и в букваре, включены материалы вводного курса русского языка, задания на развитие устной и письменной речи, орфографические упражнения. Материал прописей соотносится со страницами букваря. На каждый урок в прописях отводится достаточно большое количество заданий.

В период обучения грамоте дети проходят подготовительный курс русского языка. Учатся выполнять слого-звуковой и звуко-буквенный анализ слов. Определяют место ударения в слове. Это помогает овладеть орфографией.

После завершения работы по Букварю и прописям обучение продолжается по учебникам «Русский язык» и «Литературное чтение» тех же авторов.

"Әлифба", то есть татарская азбука под авторством Рамзии Валитовой и Салея Вагизова является настоящим учебником-долгожителем. Салей Вагизов и Рамзия Валитова явились первыми авторами азбуки для детей для изучения татарского языка. Книга изменялась и дополнялась 41 раз, по ней учились 3 поколения татарстанцев. До сих пор именно по ней продолжают знакомство с татарским языком в мире.

За все это время книга сменила обложку лишь трижды и каждая из них - это отражение истории страны и республики. Авторы были удостоены многочисленных премий, в том числе они стали лауреатами премии Каюма Насыйри. Это та самая старая-добрая, самая популярная Элифба в советском и постсоветском пространстве. Третья Элифба по которой учились в 90-х годах школьники Татарстана, главным героем которого стал мальчик на обложке в национальной одежде. Именно с этим букварем в руках выступала в защиту родного языка татарская общественность. Также оберегали и сохраняли родной язык всю свою жизнь Салей Вагизов и Рамзия Валитова.

В разное время, в связи с изменениями, происходящими в обществе, требования к букварям изменялись.

Процесс познания мира многогранен. Но начало этому процессу познания заложено в букваре.

Наш современный букварь совсем не похож на своих прадедушек и прабабушек, которым от роду девяносто, сто и даже триста лет.

Пройдут годы – и букварь снова изменится.

Работа над букварём ведётся постоянно. Букварь живёт, улучшается, потому что он всегда будет необходим людям, как первая ступенька на пути в огромный мир знаний.

**Список использованных источников**

1. Букварь под редакцией С. П.Редозубова. Издательство «Просвещение», 1965 год.

2. Букварь под редакцией В. Г.Горецкого и А. Ф.Шанько. Издательство «Просвещение», 1993 год.

3. Букварь под редакцией Р.Н Бунеева, Е.В. Бунеевой, О.В. Прониной. Издательство «Баласс» 2014 год.

4. http://fp.edu.ru/forum

Низамутдинова С.Т.
Кайбицкий район,с.Ульянково,МБОУ "Ульянковская ООШ",
учитель татарского языка и литературы

## ТАРИХИ-МӘДӘНИ «ӘЛИФБА БИОГРАФИЯСЕ"

**Аннотация:** Статья посвященная изучению истории издания татарских букварей, анализу их вербальных, визуальных текстов и трансформации букваря на протяжении веков. Показывает структуру, содержание, методический аппарат, оформление татарских букварей, изданных с конца XVIII в. по настоящее время. Впервые в отечественной историографии татарский букварь

рассматривается как культурно-исторический феномен, национально-культурное наследие. Комплексный подход, примененный авторами в процессе исследования, заключающийся в анализе специфических особенностей букварей не только татар-мусульман, но и крещеных татар, помогает проанализировать национальный букварь как единый, ценный исторический источник по истории татарского народа и важный носитель национальной памяти и идентичности. Теоретический и фактический материал по теме исследования позволяет показать особенности развития и место татарского букваря в системе национального образования татарского народа. В то же время монография может способствовать введению татарского материала и в контекст международных исследований по букваристике.

**Ключевые слова:** образование, просветительство, обучение грамоте, национальный букварь, детские буквари, буквари для взрослых, национальная идентичность, диалог культур, татары, тюркские народы.

Татарларның мәктәп белеме һәм мәгърифәтчелек тарихы тирән тарихи тамырларга ия. Татар мәгарифенең үсеше турыдан-туры дәүләтчелек үсеше тарихы һәм Урта Идел буенда ислам таралуы белән бәйле. Казан татарлары борынгы заманнардан ук белемле кешеләрне кадерләгәннәр һәм балаларны ислам кануннары буенча тәрбияләүгә генә түгел, ә аларны грамотага өйрәтүгә дә зур әһәмият биргәннәр. Бала дөньяны танып белгән беренче мәктәп дәреслеге «Әлифба»булган. Татар әлифбасының 200 елдан артык тарихы бар. Ул милли хәтер һәм тәҗрибә йөртүче, милли үзенчәлекне кабатлау чараларының берсе булып тора.

Танылган Әлифба тикшеренүчесе, педагогика фәннәре докторы, Россия мәгариф академиясенең мөхбир әгъзасы В. Г. Безрогов дөрес билгеләп үткәнчә, ул " дөньяны беренче тапкыр күренергә мөмкинлек бирә, татар балаларын укырга өйрәтү өчен дәреслек, чөнки нәкъ менә татар балаларын милли традицияләрдә тәрбияләү һәм тәрбияләү процессында, шулай ук аларны дөнья мәдәнияте казанышларына җәлеп итүдә аерым урын алып торган әлифбалар кыйммәтле чыганак булып тора, анда өлкәннәр җәмгыяте әйләнә-тирә дөнья буенча юл күрсәткечен модельләштерә.

Бүгенге көнгә кадәр татар әлифбасы өйрәнелмәгән дип әйтеп булмый. Милли Әлифба күп еллар дәвамында татар филологлары һәм педагоглары тарафыннан өйрәнелә. Әмма татар әлифбасын мәдәни - тарихи феномен, милли-культура мирасы дип санаган әле булмаган. Бу Ватан тарихнамәсендә тарих буенча беренче фәнни тикшеренү татар – мөселманнар төркемнәре, гадәттәгечә, чукындырылган татарларның әлифбаларының үзенчәлекләрен дә карадылар. Мондый комплекслы алым милли әлифбаны татар халкы тарихы буенча бердәм, кыйммәтле тарихи билгеле бер үсеш стадиясенә ирешкән һәр халык диярлек үз әлифбасын үзе ясый яки башка халыклардан (миссионерлык, мәдәни-Трегер, колонизация активлыгы кысаларында) ала. Кайбер халыкларда беренче әлифбалар борынгы заманнарда ук барлыкка килгән, башкаларында соңрак, XX гасыр башыннан.бу процесс җирле аз санлы халыкларның туган телләрендә беренче әлифбалар булдыру әле дә дәвам итә. Мәсәлән, 2017 елның мартында

Хабаровскида беренче негидаль элифбасы Берелтуева Д.М., Казарова, Надеина Үеғида элифбасы (Негидаль элифбасы)тәкъдим ителгән чыганак, милли хәтер һәм шәхеснең мөһим йөртүчесе буларак анализларга ярдәм итә.

Традицион рәвештә берничә тугандаш халыкларда балаларны укыту өчен кулланылган әлифбалар билгеле. Һәм бу яктан татар әлифбаларының бай тарихы бар. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында татар авторлары әлифбалары буенча Урта Азиянең һәм казакъ далаларының күп кенә төрки халыклары вәкилләре грамотага өйрәнгәннәр. Бу халыкларның телләрендә уку әсбаплары булмаган, шулай ук аларны булдыра алырлык квалификацияле педагоглар булмаган чорда Казан татарларының әлифбалары һәм башка дәреслекләре күп кенә төрки халыкларның милли мәктәпләре өчен төп, кайвакыт бердәнбер уку әсбаплары булган. Кагыйдә буларак, Төркестан халыкларының беренче мәгърифәтчеләре Әхмәтхади Максудиның «Мөгаллим әүвәл» һәм «Мөгаллим сани яки элифба гарәби»әлифбаларын актив кулланган татар мөгаллимнәре була.

Җәдит мәктәпләрендә һәм мәдрәсәләрендә укыту татар телендә барган, бигрәк тә алар барлыкка килгән беренче дистә елларда: аларда рус телен дә, җирле халыкларның телләрен дә яхшы белгән татарлар укыткан. Аларның шәкертләре, тиешлечә, татар телен ул вакыттагы төрки халыклар арасындагы мәдәниятара коммуникация телен белгәннәр. Һәм бу эштә татар әлифбалары зур роль уйный. Рецензияләнгән монография авторлары җитәрлек өлеш керткәннәр. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында татар җәмгыятендә кискен торган тел, мәдәният, этноним проблемаларына анализ ясауга зур игътибар бирелә.

Татар әлифбалары коллекциясе, Н.И. Лобачевский исемендәге Казан федераль университеты, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе һәм Россиядә бердәнбер Әлифба музее – музее фондлары (Арча шәһәре)ендә саклаланалар.

Монография концептуаль якын килү һәм уйланылган структура белән аерылып тора, өч бүлектән тора. Кереш өлеше (авторлардан) тикшеренүнең методологик нигезләрен ача. Беренче бүлектә догалы Әлифбадан яңа типтагы Әлифбага: татар әлифбасы XIX гасыр ахыры XX гасыр башы.авторлар татар әлифбалары тарихына экскурсия ясыйлар, алар, кызганычка каршы, 1778 елдан гына сакланып калган (с. Хәлфин әлифбасы). Чыганаклар җитмәү элеккеге чорларны җентекләп анализларга мөмкинлек бирми. Болгар-татар әлифбалары Идел буе Болгары мәктәпләрендә, ә аннары Алтын Урдада һәм Казан ханлыгында кулланылган. Әмма образ системасының үзенчәлекләре турында җентекләп фикер йөртү мөмкин түгел.

Өченче бүлекнең эчтәлеге укучыга постсовет Әлифбасының үзенчәлекләрен «яңа чынбарлык» ның чагылышы буларак ача.

Бүгенге көндә тарихыбызның иң катлаулы чорларында да милли мәдәниятне, динне һәм туган телне саклаган ата-бабаларыбызны истә тоту мөһим. Бу процесста, әлбәттә, мәктәп дәреслекләре зур роль уйнады. Беренче чиратта, бурычы чикләнмәгән әлифбалар балаларны укырга һәм язарга өйрәтте. Әлифбаның функцияләре күпкә киңрәк булган. Беренче карашка гади булып күренгән текстлар һәм рәсемнәр балаларны Ватанны, үз халкын яратырга,

өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәткән. Милли мәктәпнең үсеп килүче буынны тәрбияләү һәм мәгариф өлкәсендәге ролен генә түгел, ә укытучының бу системада алган әһәмиятле урынын да күрсәтелә. Чөнки еш кына татар муллалары һәм укытучылары бик аз түләүгә эшләгәннәр, ә мәктәпләр һәм мәдрәсәләр бары тик мәхәллә акчасына, ягъни татар җәмгыяте хисабына гына тотылган. Ул вакытта дәүләт ярдәме һәм финанслау юк булган. Шуңа да карамастан, татарлар арасында грамоталылык дәрәҗәсе шактый югары була һәм XIX гасыр ахырына 60% ка җитә. Совет алифбасының тарихы турыдан-туры хөкүмәтнең татар теленә һәм аның графикасына карата сәясәте белән бәйле. Китап авторлары милли анализны җентекләп үткәрделәр совет чоры әлифбалары график революцияләр чорында татар әлифбасына кагылган үзенчәлекле үзгәрешләрне күрсәтә алды.

Китап бай эчтәлеге белән генә түгел, ә төсле бизәлеше белән дә җәлеп итә. Монографиядә кара-ак һәм төсле иллюстрацияләр рәвешендә тәкъдим ителгән визуаль рәт текстка искиткеч өстәмә генә түгел, ә кыйммәтле визуаль мәгълүмат чыганагы да булып тора. Алар арасында төрле елларда бастырылган татар әлифбаларының тышлыкларының һәм битләренең оригиналь фотокопияләре, татар мәктәбе үсешенең аерым битләренә багышланган иллюстрацияләр, авторларның берсе – Д. М. Галиуллина.

Китапның тагын бер үзенчәлеге шунда ки, ул параллель рәвештә ике телдә – рус һәм татар телләрендә басылып чыга. Ә аның ике милли мәдәният вәкилләре – рус һәм татар мәдәниятләре тарафыннан язылуы нәкъ менә диалог процессында мәдәниятләрнең үзара аңлашылуы барлыкка килүенең яхшы үрнәге булып тора. Асылда, бу безнең республикада бик кадерле булган толерантлык һәм мәдәниятара хезмәттәшлек үрнәге.

Шулай итеп, озак еллар тикшеренү эшендә тупланган тикшеренү темасы буенча теоретик һәм фактик материал авторларга татар әлифбасының үсеш үзенчәлекләрен һәм урынын күрсәтергә мөмкинлек бирә ,татар халкының милли мәгариф системасында татар материалын букваристика буенча халыкара тикшеренүләр контекстына кертә.

## Әдәбият исемлеге

Максуди, А. Н.Казан: Матбугат университеты., 1892. 142 б

Максуди, А.сана яки Гарәп әлифбасы укытучысы. Казан: Харитонов матб., 1904. 40 б.

Сальникова, А.А., Галиуллина, Д.М. татар Алифба: үткән һәм хәзерге / татар Алифба: тарих һәм хәзерге заман. Казан: Татар. китап. 2016 елгы басма. 196 б.

Рәхмәтуллина Алсу Рәис кызы,
Арча муниципаль районы “Д.Хәкимов исемендәге
Түбән Мәтәскә гомуми белем мәктәбе” филиалы
“Мөндеш башлангыч гомуми белем мәктәбе”

# С.Г.ВӘГЫЙЗОВ МЕТОДИК МИРАСЫНЫҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ИННОВАЦИЯЛӘРЕ (“ӘЛИФБА” ЭВОЛЮЦИЯСЕ)

Күңелдә тирән эз калдырган китаплар була. Аларны укып кына калмыйсың, ул синең дустыңа, киңәшчеңә, ярдәмчеңә әйләнә. Бу китап – дөньядагы барлык сорауларга да җавап табарга ачкыч бирә һәм белем иленә дөрес юлны күрсәтүче сукмак булып тора. Фәннәр иленең ишеген ачкан бу китапны кеше гомере буена онытмый, рәхмәт хисе белән искә ала. Мондый китапларның берсе – татар телендә укый һәм яза белүче һәрберебез өчен иң кадерле булган – “Әлифба” китабы. 39 хәрефне өйрәтүне үз эченә алу гына түгел, ә кешенең матур сөйләмен һәм тирә-юньгә дөрес карашын да формалаштырган дәреслектән дә әһәмиятлерәк китап була аламы! “Әлифба” кешенең гомере буена җыясы белем байлыгының нигезе булып тора.

“Әлифба” дәреслеге тарихта билгеле булган иң өлкән китапларның берсе булса да, ул эчтәлегендә һәр чор өчен актуаль булган сорауларга җавапны табарга ярдәм итә һәм шул ук вакытта һәр заман баласына кызыклы булып кала. Әлбәттә, монда дәреслекне язган авторларның хезмәте зур һәм осталыклары, алдан күрә белү сәләтләре бәхәссез. Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова авторлыгындагы “Әлифба” китабы бүген дә актуальлеген югалтмый. Ул дәреслек буенча укыган күпме кеше бу китапны тирән ихтирам хисе белән искә ала. Дәреслек бастырылмаса да, күпме гаиләдә иң кадерле, иң кирәкле китапларның берсе булып саклана.

Әлифба стабиль булса да, барыбер искерә. Бер генә дәреслек тә гомер-гомергә стабиль дәреслек булып хезмәт итә алмый. Беренчедән, тормыш алга бара, илнең икътисади-сәяси һәм мәдәни тормышында бара торган үзгәрешләр, чор алдына килеп баскан яңа бурычлар әлифбага да кагылалар, шул үзгәрешләргә, яңа бурычларга туры китереп, әлифбаның да эчке рухын һәм андагы материалларны үзгәртергә туры килә. Икенчедән, тел белеме, укыту методлары гел үсеп, камилләшеп тора. Әлифба төзүче моны шулай ук искә алырга тиеш була. Димәк, әлифба дәреслегендә билгеле бер күләмдә чорның сулышы, тел гыйлеменең үсеш дәрәҗәсе, грамотага өйрәтү методикасындагы үзгәрешләр чагыла. Димәк, бар “Әлифба” да үзгәрә, камилләшә, яңара. Ләкин әлифбаның төп калыбы сакланып кала, аның үрнәгендә яңа дәреслекләр барлыкка килә. Кайсы гына “Әлифба” китабын алсак та, С.Г.Вәгыйзов методикасы сакланып кала, аның традицияләре дәвам ителә.

Мәсәлән, 2011 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина авторлыгында яңа әлифба чыкты. Бүгенге көндә мәктәп бусагасын яңа атлап кергән балалар туган телебез хәзинәсен шушы әлифба ярдәмендә өйрәнә башладылар. Дәреслек,

билгеле бер күләмдә эволюция кичерде дисәк тә була. Уңай һәм матур традицияләр сакланып калып, яңалык өстәлгән бу дәреслек тә укучыларыбыз күңеленә хуш килде.

Әлифба, үзенең структурасы буенча кабатланмас булса да, күп кенә язучы, шагыйрь һәм рәссамнарга яңа төрдәге әсәрләр иҗат итәргә илһам һәм этәргеч тә бирә. Бу алар өчен үзенә бер эксперемент була. Мәсәлән, автор балалар өчен якын булган аерым бер теманы сайлап ала да, шуны "Әлифба" калыбына салып, яңа китап барлыкка килә. Әлбәттә, ул китап үз укучысын таба, нәни дусларны сөендерә һәм бәяләп бетергесез зур файда китерә.

Гадәттә, мондый төр әлифбалар шигъри формада язылалар. Беренчедән, рифмага салынган юлларны балалар тизрәк истә калдыралар. Икенчедән, балаларга шигырь юлларын уку күңеллерәк. Балалар өчен иҗат ителгән әсәрләрнең матур бизәлеше дә зур әһәмияткә ия. Ә без, укытучылар, мондый әсәрләрне грамотага өйрәтү чорында бик теләп файдаланабыз.

Йолдыз Шәрәпованың "Зоопарк әлифба" китабына кертелгән шигырьләрен уку хайваннар иленә читтән торып экскурсиягә баруны хәтерләтә. Әсәрләр алфавит тәртибендә урнаштырылган. Әлбәттә, татар алфавитына кертелгән хәрефләр дә онытылмаган. Һәр хәрефкә берәр хайванга багышланган шигырь язылган. Балалар, китапны укып, күп информация алалар: хәреф белән дә танышалар, терек табигать турында күзәллауны да киңәйтәләр, кече дусларыбызны саклау һәм яклау зарурлыгын да аңлыйлар.

Марзыя Фәйзуллинаның "Гаилә әлифбасы" бер максатка яраклаштырылган: әниләр һәм балалар китабы булдыру. Уңышы - халыкның рухи хәзинәсен, әхлагын, диннең әдәп кагыйдәләрен хәдисләр ярдәмендә бирү. Һәр хәрефкә аталган шигъри сүз белән бергә, шигырьләрдә Ана һәм Бала образлары, алар арасындагы якынлык берсеннән икенчесенә күчә һәм ачыла бара. Туган телгә мәдхия җырлана, йола һәм дингә хөрмәт тәрбияләнә.

Шул ук авторның "Табышмаклы әлифба" тупланмасының да әһәмияте зур. Кайбер шигырьләр теге яки бу җәнлекнең, кош-кортның аерым сыйфатларын санап бирүгә генә корылган булса да, шигъри табышмаклар безне кызыксындыра, мәгълүмат белән баета.

Автор-төзүче Талия Шакирова туплаган "Хайваннар" дидактик материаллар җыентыгында хайваннар турындагы белешмә "герой" авызыннан сөйләтелә. Һәр бит-аерым хәрефкә, аерым хайванга багышланган. Мәкаль, әйтем, табышмак һәм уеннар белән баетылган тупланманың рәсемнәрен рәссам Алсу Тимергалина бизәгән. Тырышлык бушка китмәгән. Бала халык авыз иҗаты белән дә таныша, орфоэпик күнекмә дә ала, кызыл һәм зәңгәр төсләргә буялган хәрефләрне кызыксынып күзәтеп, сузык һәм тартык авазлар турында мәгълүмат та ала.

Р.Миңнуллин язган "Хәрефләр бәйрәме" китабы балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп өчен чын мәгънәсендә хәзинә. Кечкенә шигырьләр шаян сүзләргә бай, аларның эчтәлегенә туры килгән төсле рәсемнәр белән бизәлгән булуы балаларда зур кызыксыну уята. Балалар өчен җиңел, аңлаешлы телдә

язылган бу шигырьләрне балалар кабат-кабат укырга кушалар, ятлап та өлгерәләр.

Әлифба һәрвакыт телне һәм әйләнә-тирәне өйрәтүче серле сандык булып кала. Ә андагы хәрефләр- балалар өчен иҗат итүче авторларыбыз өчен төзү материалына тиң. Алар ярдәмендә язучы һәм шагыйрьләр балаларны белем иленә чакыралар. Гомер буена ватылмас-җимерелмәс нигез төзиләр, укуга һәм китапка кызыксыну, мәхәббәт тәрбиялиләр.

ТАССРның атказанган укытучысы, педагог, галим, методист, 40 тан артык дәреслек һәм методик әсбаплар, ә иң мөһиме яраткан “Әлифба”бызның авторы булган Сәләй Гататович Вәгыйзовка рәхмәтебез чиксез. Аның 1954 нче елда туган авылым Мөндештә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшләве миндә соклану һәм горурлык хисләре тудыра. Ул эшләгән чорда башлангыч сыйныфта укыган, бүгенге көндә инде 80 яшен тутырган авылыбызның хөрмәтле кешесе Туюрова Гөлфия апа да аны җылы, матур сүзләр белән телгә ала.

Киләчәгебез балалар кулында. Аларга дип иҗат ителгән китаплар һәм әсәрләр гел язылып торсын, язучыларның, рәссам һәм галимнәрнең иҗат чишмәсе саекмасын иде. Балалар матурлыкны күрә, тормышны ярата, китапны саклый һәм кадерли белә, белемгә омтыла торган булсын өчен “Әлифба”ларыбыз бик кирәк безгә. Бәлки, шушы үсеп барган буын балалары арасында да С.Г.Вәгыйзовның традицияләен дәвам итүчеләр булыр дигән өметем зур.

Кулланылган чыганаклар исемлеге:

1. Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана: Татарча уку-язуга өйрәнү методикасы һәм татар әлифбалары тарихы. Казан, 1994;
2. https://www.metod-kopilka.ru/tatar_basma_lifbalaryna_kzt-34372.htm
3. https://www.labirint.ru/news/8102/

Хөснетдинова А.М.
БГБУ "Арча 6нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе",
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Галимова С.А.
г.Арск, МБОУ Арская средняя общеобразовательная школа №6,
учитель начальных классов

## ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРНЕҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация:** Статья посвящена важной проблеме начального образования. Дается краткий анализ «Алифбы» прошлого. В статье приведены примеры произведений включённых в «Алифбу». Обозревается жанровый состав материалов для детского чтения. В учебник включены произведения известных татарских поэтов.

**Ключевые слова:** «Әлифба», экият, фольклор, традиция.

**Abstract:** The article is devoted to the important problem of primary education. A brief analysis of “Alifba” of the past is given. The article provides examples of works included in “Alifba”. The article surveys the genre composition of materials for children's reading. The textbook includes famous Tatar poets

**Key words**: “Alifba”, akiyat, folkcore, tradition.

Һәр милләтнең рухи мирасында мөһим өлешне халык авыз иҗаты алып торуы бәхәссез. Ул - соклангыч эчтәлекле, сәнгатьлелелек ягыннан гаҗәеп бер казаныш, һәр халыкның горурлыгы һәм кабатланмас үзенчәлеге.

Сүз сәнгате буларак фольклор халыкның электән чыгарылып килгән традицион һәм хәзерге авыз - тел иҗатын иңләп ала, димәк, чәчмә - прозаик әсәрләрне дә, шулай ук шигъри текстларны да үз эченә берләштерә. Барыннан да элек, халык авыз иҗаты телдән - телгә күчеп яшәве белән аерылып тора. Халык авыз иҗаты ул - сүз сәнгате, телдән чыгарыла һәм телдән сөйләнә яки телдән башкарыла. Халык тудырган әсәрләр нәкъ менә сөйләнгәндә һәм башкарылганда гына җанлы булып, чын үз тормышы белән яши.

Фольклор бер үк вакытта - коллектив күмәк иҗат та, ягъни аны тудыруда һәм эшкәртүдә күп кенә халык вәкилләре катнаша.

Сәләй ага белән Рәмзия апалар менә шуларны аңлап, тоеп, халык авыз иҗатының, халык трацияләренең үрнәкләрен әлифбаларында аз - азлап, кертә башлыйлар. Әгәр дә әлифбаның беренче битләренә үк күз салсак, без моңа инанабыз.

Сәләй агалар халыкның аерым йола - иҗат төрләренә, әйтик, кайбер хуҗалык – календарь йолаларга (нардуган, нәүрүз, карга боткасы), ырымнарга, тел шомарткычларга да аерым әһәмият бирәләр. Чөнки бу жанрлар балаларга бик якын. Үзләренең кыскалыгы, яңгырашы белән балаларның күңеленә тиз сеңә. Авторлар менә шуның өчендә халык - авыз иҗатына урын бирәләр.

Кайбер авазларны өйрәнгәндә кыска гына мәкальләрне дә кертеп җибәргәннәр.

Әкият - халык авыз иҗатының бик борынгы жанры, шул ук вакытта әлеге жанрга караучы тылсым һәм могҗизалы уйдырмага нигезләнгән,яки маҗаралы һәм гадәттән тыш хәлләргә вакыйгаларга корылган фантастик әсәр. Әлифбаның битләрендә без белгән әкият геройлары.Ә инде авазларны өйрәнеп бетергәннән соң Әкиятнең үзе белән үк танышабыз. Чөнки әкиятләрдән башка баланың тормышын күз алдына китерү кыен.

Менә шуңа күрә дә, сүзне әкиятләрдән башлыйсы килә. Әкиятләр халык авыз иҗатының бик борынгыдан килә торган, халыкның тормыш тәҗрибәсен, акылын, зирәклеген, бай иҗатын, фантазиясен чагылдырган кыйммәтле рухи хәзинәсе. Халык авыз иҗатының башка жанрлары кебек, әкиятләр сәнгать әсәре булып торалар һәм сәнгатьчә эшкәртелгән җанлы сөйләм теленә нигезләнәләр.

Башка фольклор жанрларыннан аермалы буларак, әкиятләрнең төп үзенчәлеге шунда - алар сюжетлы хикәяләүгә корылалар. Әкиятләрнең теле, иң

беренче чиратта диалекталь сөйләмгә нигезләнгән. Шуңа күрә дә кайбер галимнәр әкиятләрнең телен диалекталь тел белән янәшә куялар.

Әкиятләрнең теле гади һәм образлы, җанлы һәм мавыктыргыч. Биредә җөмләләр арасында ачык күренеп торган чикләр юк. Сүзләр һәм җөмләләр бәйләнеше тотрыклы түгел.

Менә шуңа күрә дә Сәләй Гататович һәм Рәмзия Валитовалар әлифба дәреслекләренә хәрефләр, авазлар үтеп бетергәннән соң әкиятләрне кертеп, аерым әһәмият биргәннәр. Чыннан да, кече яшьтән үк балалар әкиятләрне тыңлап үсәләр. Укырга язарга өйрәнгәч тә, класстантыш уку дәресләрендә әкиятләргә аерым урын бирелә.

"Төлке белән каз", "Торна белән төлке" әкиятләре аерым бер әһәмияткә ия. Әле дә булса, безнең буын кешеләренең күңелләренә уелып калган. Сүрәтләү чараларына бай, теленең гадилеге, аңлаешлылыгы, сюжет сызыгының беренче сыйныф укучыларына яраклыгы белән якын бу әкиятләр.

Шушы традицияне яңа чыккан әлифбалар дәвам итә. Ә бу авторлар күбрәк язучылар язган әкиятләгә әһәмият бирә. Шәхсән без үзебез татар халык әкиятләрен уку китапларына кертү ягында. Чөнки аларның теле гади, балаларга аңлаешлы. Тыңлаучыны әкият ахырдан реаль дөньяга кайтаралар һәм аларның күңелен күтәреп, көлкеле финал тудыралар.

Әлифба уку дәреслекләренә кергән шигырьләр үзләренең кыскалыгы һәм дә җанлы сөйләм теле, сүрәтләү чараларына бай булуы белән аерылып торалар. Шигырьләр татар халкына, туган илгә, табигатькә иксез-чиксез мәхәббәт белән сугарылган. Татар халкына гына хас сабырлык, түземлек ярата һәм кичерә белү, тәрбия, шәфкатьлелек кебек хисләр белән, татар теленең иң тирән мәгънәле сүзләрен урынлы һәм вакытлы кулланып язылган шигырьләр урын алган.

Бөек шагыйрьләребез – Габдула Тукай, Муса Җәлил шигырьләрен кертеп бик дөрес эшләгәннәр.

Муса Җәлилнең "Беренче Дәрес", "Әтәч", "Бишек Җыры", ГабдуллаТукайның "Туган авыл", Гали белән кәҗә", "Җир йокысы" шигырьләре җанлы сөйләм теле белән язылса да, гади сүзнең бөеклеге сизелә. Бу шигырьләр сүздән тәм табып язылган. Менә шуңа күрә дә балалар күңеленә якын. Гомумән, шигырьләр тел матурлыгы, эмоциональ яңгырашы, нәфислеге белән аерылып торалар.

Иң мөһиме – шигырьләр үзләренең "сүздән челтәр үреп", татар сүзенең мәгънә төпкелләренә төшеп иҗат ителгән.

Сүзебезне йомгаклап, шуны әйтәсе килә, әлифбаның бу традицияләре югалмасын иде. Хәзерге вакытта бигрәк тә. Чөнки балалар телефонга кереп киткән чорда яши. Һич югы әлифбалардагы халык авыз иҗаты үрнәкләре, халыкның гореф-гадәтләре белән балалар кече яштән үк танышып үссеннәр иде. Беренче сыйныф баласының хәтере яхшы, кызыксына, истә калдыра. Сәләй ага белән Рәмзия апа шушы гади генә төшенчәне ачык аңлап, әлифба иҗат иткәннәр.

Список использованной литературы:

1. Вагыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Әлифба .- Учебник для трехлетней начальной школы.-“Мәгариф”нәшрияты.-Казан: Мәгариф, 1995.- 78 б.2.
2. http://www.millattashlar.ru/index.php/%D3%98%D0%9B%D0%98%D0%A4%D0%91%D0%90_(%D0%91%D1%83%D0%BA%D0%B2%D0%B0%D1%80%D1%8C) - ӘЛИФБА (Букварь)

# СЕКЦИЯ 3. СУДЬБА «АЛИФБЫ» ВАГИЗОВА С.Г. И ВАЛИТОВОЙ Р.Г.: ПРОШЛОЕ И НАСТОЯЩЕЕ
# 3 НЧЕ СЕКЦИЯ С.Г. ВАГЫЙЗОВ ҺӘМ Р.Г. ВӘЛИТОВАЛАР «ӘЛИФБА» СЫ ЯЗМЫШЫ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕСЕ

Вәлиева Ләйсән Фоат кызы,
Арча районы Иске Чүриле урта гомуми белем мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## ӘЛИФБАГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕРЛӘР...

*Бөек бәхет-калсаң кешеләрнең*
*Күңеленә кунган нур булып.*
*Р.Фәйзуллин*

Хезмәтемне “Арча Әлифбаның Ватаны булсын...” дип атавым һич тә очраклы түгел. Ничә дистә еллар укучыларга хәреф танытып, аларны белем иленә алып кергән әлифба авторлары безнең Арчадан, минем якташларым бит! "Әлифба" музееның төп нигезен дә Вагыйзов Сәләй Гата улы һәм Вәлитова Рәмзия Гыйлаҗ кызының педагогик һәм иҗат эшләре тәшкил итә. Алар 1965 елдан башлап бөтен татар мәктәпләре өчен булган әлифбаның авторлары, моннан тыш алар 43 төрле дәреслекләр һәм методик китапларның авторлары да. Ә менә буыннан-буынга шушындый байлык бүләк итүчеләр турында ни генә беләбез икән?

Арчада Сәләй ага белән Рәмзия апаның язмышын Тукайныкы белән чагыштырырга яраталар. Икесе дә ятимлекнең бөтен ачысын-төчесен татыган кеше алар. Сәләй (Сөләйман) Самара өлкәсенең хәзерге Камышлы районы, Татар Байтуганы авылында дөньяга аваз сала. Алты айлык чагында әтисе вафат була. Әнисе туган ягына кайтып китә. Сабый бала әбисе тәрбиясендә кала. Әмма, хәле начарайгач, Сәләйне авылдашлары Гататдин абый белән Гайшә апага тәрбиягә бирергә мәҗбүр була. Рәмзия апа исә Башкортстаннан. Җиде яшьтән ятим калган кыз Эстәрлетамак балалар йортында тәрбияләнә. Егет белән кызны Казан педагогия институты кавыштыра. Мөгаен, авырлыклар кешегә яшәргә көч бирә, дигәннәре дөрестер ул. Арча педагогия училищесына кайтып эшли башлагач та, бәхеткә тиенгән көннәргә сугыш чик куя. Завуч булып эшләгән Сәләй ага фронтка киткәч, аның урынын Рәмзиясе алыштыра. Көн дә хәбәр көтеп, исән кайтуын өмет итеп яши ул. Әмма... өмете тиз генә акланмый. Сәләй ага Харьков янында немецларга әсирлеккә эләгә. Аннан котылгач, аны Печора лагерена сөрәләр. Рәмзия апа ике нарасыен җитәкләп, ике мәртәбә ире янына бара. Мондый сәяхәтләрнең ахыры бик аянычлы була: аны эшеннән куалар. Ә ире, сабыйларны саклап калу ниятеннән, аңа үзеннән баш тартырга киңәш итә. Әле аннан соң да бары тик кайчандыр бергә укыган, ул вакытта зур урыннарда эшләгән дуслары ярдәмендә генә яңадан эшкә урнаша ала. Рәмзия апа шул көннәрдән алып 1969 елга кадәр Арча педагогия училищесында татар теле, әдәбияты һәм методикасы укыта. СССР халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы

дигән мактаулы исемнәргә лаек була. Сәләй абый да исән-сау әйләнеп кайткач, гомерен балалар укытуга багышлый: башта мәктәптә укытучы, Роно инспекторы, аннан педучилищеда татар теле, әдәбияты һәм методикасы укытучысы. Ул – Татарстанның атказанган укытучысы, Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы, К.Д. Ушинский медале иясе. Болары – ике галимнең катлаулы тормыш юлыннан өзекләр генә...

Көчле рухлы булган Сәләй ага белән Рәмзия апа. Авырлыклар, гаделсезлекләр бу икәүнең бер булып типкән йөрәкләрен ташка әйләндерә алмаган, күңелләре тупасланмаган аларның. Шулай булмаса, җиң сызганып нәкъ менә сабыйлар өчен булган дәреслеккә – әлифбага тотына алырлар идеме икән алар?! 1960 елда төзелә башлаган дәреслек балалар кулына 1965 елда барып ирешә. Башкалардан эчтәлеге белән дә, матур төсле рәсемнәре (аны рәссам Язынин бизәгән) белән дә аерылып торган зәңгәр тышлы әлифба ул. Татарстан Мәгариф министрлыгы уздырган конкурста бу дәреслек икенче урынны алган. Шуннан соң әлифбаларга “юл ачыла” да инде: 6 яшьлекләр өчен, өч сыйныфлы башлангыч мәктәп өчен, “Рәсемле әлифба”... Сәләй ага белән Рәмзия апа хәтта әлифбаны латин графикасы белән дә төзергә өлгерәләр. Хәер, аларның хезмәтләрен санап кына бетерерлек түгел. Шулар арасында укытучыларның өстәл китабына әверелгән уку китаплары, татар теле дәреслекләре, “Кызыклы грамматика”, “Язу һәм матур язу” дәфтәрләре, методик кулланмалар... Аларның барысы да әле бүген дә хезмәттә, бүген дә укытучылар кулында. Ә бит заманында Сәләй аганы “фән кандидаты булмаган башың белән бу тирәдә буталып йөрмә дә” дип әлифбасы-ние белән борып та чыгаралар. Ярый әле түрәләр арасында аңлый белгәннәре дә табыла. Шулай итеп, ничә дистә еллар татар халкы әлифба белән хәреф таныта, ана теле белән таныштыра. Арча педагогия көллияте мөгалимнәре С. Вәгыйзов белән Р. Вәлитовалар татар әлифбасын төзүгә бөтен гомерләрен багышладылар дисәк тә хакыйкатьтән тайпылмабыздыр.

Татар мәгарифе тарихында әлеге шәхеснең урыны бар. Сәләй аганы “татар Әлифбасы атасы” дип атау, бер яктан, бик үк дөрес тә түгелдер. Чөнки аңа хәтле татарның алты Әлифбасы булган. Беренчесе – Иман шарты. Аннан соң Сәгыйть Хәлфин, Әхмәтһади Максуди (ике Әлифба), Мөхетдин Корбангалиев, Габбас Сәйфуллиннар Әлифба китаплары язалар. Сәләй Вәгыйзов Әлифбасы иң озын гомерле булганга, мин аны Әлифба атасына тиңләр идем.

1965 елдан башлап татар баласы 50 ел буе нәкъ менә Сәләй ага һәм аның тормыш иптәше Рәмзия апа язган Әлифба буенча укырга, язарга өйрәнгән. Дамир Таҗиев әйтүенчә, чит илләрдә яшәүче татар балалары әле бүген дә нәкъ менә шушы Әлифбаны кулланалар икән.

Петербургның бер галиме бөтен дөньядагы Букварь һәм Әлифбалар буенча докторлык диссертациясе язган булган һәм нәкъ менә Сәләй ага Әлифбасын иң яхшысы дип аерып куйган. Бу Әлифба 50 ел эчендә 40 мәртәбә басыла. Беренче басмасы, әйткәнемчә, 1965 елда чыга, Әлифбаның гомуми тиражы исә миллионнан артып китә. Моннан тыш Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова-Вәгыйзова татар телен өйрәнү методикасы буенча 43 китап язалар. Мин үзем дә,

татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, зәңгәр тышлы әлифбаны сагынам. Аның һәр хәрефе әле дә истә.

Ә чынлыкта әлифба язу ничек була икән ул? Җиңелләрдән түгелдер. Моның өчен бит бөек укытучы да, күпкырлы галим дә, шул ук вакытта сабыйларча фикерли белү дә кирәк.

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов заманында болай дип язып калдырган: "Балачагымның якты көннәрен кабат исемә төшергәннәре өчен "Әлифба" авторларына мең-мең рәхмәт. Шушы "Әлифба"ны укып күзләре ачылган ун меңләгән бала, еллар узгач, зиһеннәре арта төшкәч, Рәмзия апа белән Сәләй агага, минем кебек үк, рәхмәт әйтерләр дип ышанам". Мондый рәхмәтләр чиксез булыр әле зәңгәр тышлы, матур рәсемле әлифба хуҗаларына!

Әйе, Арчабызда Татарстан һәм Россиядә генә түгел, ә дөньяда беренче "Әлифба" музее ачылу да әлеге мөхтәрәм шәхесләребезгә хөрмәт һәм рәхмәт билгесе. 1998 елның октябрь аенда Арча педагогика көллиятендә Сәләй Гататович Вагыйзовның 90 яшьлек юбилее уңаеннан кичә үткәрелә. Ул вакыттагы мәгариф һәм фән министры Фарис Харисов үз чыгышында «Әлифба» китабы авторлары Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вагыйзовның иҗат мирасына багышлап музей оештырырга тәкъдим итә. Әлбәттә, бу тәкъдим бик хуплана һәм көллиятнең ул вакыттагы директоры Илдус Сәгъдиев бу эш белән җитәкчелек итү бурычын үз өстенә ала. Кыска гына вакыт эчендә Хөсәен Фатыйхович Хәйруллин тарафыннан байтак материал, экспонат туплана. Музейны 1999 елның 6 октябрендә ачалар. Әле дә "Әлифба" музее бөтен көченә эшләвен дәвам итә, байый.

Ирексездән, Рифә Рахманның "Әлифба" шигыре искә төшә:

Язган әдип китап, язган галим китап,
Хәтта патшаларның калган китаплары!
Изге Коръән сүзен укыр өчен дә бит,
Таный белү кирәк "әлиф" белән "ба"ны.

Бәйрәмнәрнең бүген бәйрәмнәредер бу,-
Дөньялыкның ашы, ахирәтнең башы.
Әлифбаны язу- җәннәтләргә лаек,
Ул бит – белемнәрнең тәүге бисмилласы.

Хезмәтемне Сәләй аганың үз сүзләре тәгәллисем килә: "Арчадан чыкмасын Әлифбалар. Аларны язуны сез дәвам итегез. Арча – Әлифбаның Ватаны булсын!" Амин, шулай булсын!

Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Мәшһүр галимне хөрмәтләү// Мәгърифәт газетасы, №43 (355), 1998 нче ел.
2. Р.Саттарова. Арча Әлифбаның Ватаны булсын//Арча хәбәрләре газетасы, 3 октябрь, 1998 нче ел.
3. Филиппов А.. Бердәнбер "Әлифба" музее// Ватаным Татарстан газетасы, 16 октябрь, 1999 нче ел.
4. Әлифба язу җиңелме?// Мәгърифәт газетасы, 31 октябрь, 1998 нче ел.
5.Роза Камалетдинова. Бәрәкәтле гомер//Сөембикә журналы, №9, 2009 нчы ел.

Гарипова Л.И., Ахметзянова Д.А.
МБОУ “Мемдельская СОШ имени Хай Вахита”
Высокогорского муниципального района,
учителя начальных классов.

# ӘЛИФБАНЫҢ ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

**Аннотация:** В данной статье рассматривается судьба “Алифбы” С.Г.Вагизова и Р.Г. Валитовой. Особое внимание уделено на её прошлое и настоящее. Описываются история алифбы и её характерные особенности. В конце статьи авторы делятся соим опытом работы с данным учебником.

**Ключевые слова:** алифба, С.Г. Вагизов, Р.Г. Валитова, история, прошлое, настоящее, опыт.

**Abstract:** This article examines the fate of “Alifba” by S.G.Vagizov and R.G. Valitova. Special attention is paid to her past and present. The history of alifba and its characteristic features are described. At the end of the article, the authors share their experience with this textbook.

**Key words:** alifba, S.G. Vagizov, R.G. Valitova, history, past, present, experience.

"Әлифба, әлифба, беренче битеңне
Ачкан көн хәтердә, зур бәйрәм шикелле..."

1нче сентябрь– Белем иленә ишекләр ачыла торган иң матур көн! Бу көнне һәркем – олымы-кечеме – беренче тапкыр мәктәпкә укырга барган минутларын искә төшерә: дулкынланудан йөрәк күкрәк читлегеннән бәреп чыгар төсле тибә, өстә – матур мәктәп формасы, кулда – гөлләмә, ә букчада – китап. Ул – Әлифба!

Дуслар, Әлифбаны кочаклап, беренче тапкыр мәктәпкә баруыгызга ничә ел тулды? Мин 30 ел элек укырга кергәнмен! Кулымда иң якын сердәшем – Әлифбам!

Әлифба... Тышлыгына кулына чәчәк букеты белән букча тоткан кыз мәктәпкә бара торган зәңгәр тышлы китапны кем генә хәтерләми дә, кем генә аның буенча хәреф танырга өйрәнмәде икән?!

Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вәгыйзов төзегән “Әлифба” китабы – һәр татар баласын белем иленә алып керүче, дөньяны ачарга булышучы беренче дәреслек булган. Грамоталыкның башлангыч нигезе әлифба чорында салына. Мәктәптә укуның беренче айлары бала тормышында аеруча әһәмиятле. Бала баштагы 3-4 ай эчендә укырга – язарга өйрәнеп кенә калмый, билгеле бер күләмдә белем һәм күнекмәләр дә ала.

Әлифба сүзе асылда ул татар сүзе түгел. Ул гарәп әлифбасының беренче ике хәрефе: әлиф һәм бә. Каян килеп кергән ул безгә? Татарларда иске имлә язу стиле булган. Татарлар гарәп хәрефләре белән язганнар. Бу революциягә кадәрле булган вакытлар. Рус азбукасыннан аерып торыр өчен татар алфавитына “әлифба” дигәннәр.

Татар әлифбасы тарихына кайтсак, Татар республикасында 60 нчы елларда мәгариф өлкәсендә шактый зур үзгәрешләр башлана. Заман таләбенә туры килгән дәреслекләр бастыру сорала. Мәгариф министрлыгы «Әлифба» дәреслегенә бәйге игълан иткән була. *Ирле-хатынлы Сәли Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова – беренче татар әлифбасы авторлары* да бу эшкә алыналар. Алар татар халкы мәгарифе тарихында булган барлык әлифбаларны, шулай ук тугандаш халык әлифбаларын барлап, өйрәнеп чыгалар. Күп көч, зур тырышлык куеп, яңа «Әлифба» туа. Типографиядә басылганчы алар әле кулдан языла.

1965 елда әлеге «Әлифба» сабыйлар кулына килеп ирешә. Татарстанда гына түгел, бөтен татар дөньясы шул зәңгәр «Әлифба»дан укырга өйрәнә. Бу «Әлифба» Татарстан Мәгариф министрлыгы уздырган дәреслекләр бәйгесендә II урынга лаек була, ә иң яхшы китапка уздырылган Бөтенроссия бәйгесендә «Әлифба» авторлары диплом белән бүләкләнә.

Дистәләгән еллар дәверендә әлеге әлифба буенча татар укучыларының берничә буыны укып чыга, ә 1990 нчы елларда рус балалары әлифба ярдәме белән татар телен өйрәнә.

1986 елда Татар китап нәшрияте Р.Г. Вәлитова һәм С.Г. Вәгыйзов «Әлифба»сын дүрт еллык татар мәктәбенең беренче сыйныфы өчен чыгара башлый. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрылыгының рәсми документларында гадәттәгечә басма тышлык төсе буенча «кызыл» дип языла.

«Кызыл» дәреслекне буяулы һәм экияттәгечә матур дип әйтсәк ялгышмабыз. Әлеге тышлыкны без барыбыз да беләбез. Мәктәп формасында укучы малай тырышып уң кулын күтәргән. Әлифбаның төп герое гади, милли киемгә киенгән малай. Китапта әкренләп татар экиятләреннән геройлар сурәтләнә башлый. Ул да булса Шүрәле, Су анасы һ.б. Шулай ук китапта матур төсләрдә ясалган Казан шәһәре күренешләре дә була. Мәсәлән, Опера һәм балет театры, Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәм Мулланур Вахитов һәйкәлләре күрсәтелә. Әлбәттә, «кызыл» басманың кайбер «кимчелек»ләрен бетереп күп тапкырлар кабат бастыралар. Элек милли киемдәге татар малае күрсәткеч белән СССР картасына күрсәтсә, Союз таркалгач аны Татарстан картасына алмаштыралар.

Рәмзия апа һәм Сәләй аганың хезмәтләрен санап бетерерлек кенә түгел. Алар тарафыннан 40тан артык фәнни хезмәт языла. Әлеге хезмәтләр арасында башлангыч сыйныф укытучыларының өстәл китабына әверелгән туган тел һәм татар теле дәреслекләре, аларга методик кулланмалар, дидактик материаллар, “Матур язу” дәфтәрләре бар. Аларның барысы да бүген дә хезмәттә, бүген дә укытучылар кулында.

Соңгы елларда төрле авторлар тарафыннан Әлифба дәреслекләре шактый иҗат ителде. Сүз дә юк, анализлый башласаң, аларның уңай яклары да,

тискәре яклары да бардыр. Әмма иң соңгыларының берсе булган Әлифба дәреслеге Сәләй ага белән Рәмзия апа методикасына нигезләнеп төзелгән. Белгечләр әйтүенчә, озак вакыт төрле алымнар кулланып эшләп караганнан соң, нәкъ менә берничә буынны белемле иткән зәңгәр тышлы Әлифба иң уңайлысы дип табылган. Чит илләрдә яшәүче татар балалары әле бүген дә нәкъ менә шушы Әлифбаны куллана икән.

18 ноябрь көнне Сәләй ага Вәгыйзовның кече ватаны Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Татар Байтуганы авылында мөгаллимнең истәлегенә музей-комплекс ачылды. Музейда татар сыйныфлары өчен меңләгән тираж белән басылып чыккан Әлифба дәреслекләре дә, Сәләй ага белән Рәмзия апаның башка эшләре дә урын алган.

«Казан арты» тарихи-этнография музее филиалы булган әлеге «Әлифба» музее Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитованың фидакарь эшчәнлегенә һәйкәл булып тора.

Тормыш бер урында тормый, алга бара, аның белән бергә мәгариф системасы да яңарыш кичерә. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары кергәннән соң Әлифбаны да әлеге стандартларга туры китерү таләбе килеп туа. Авторлык хокукларын да саклау, заманча таләпләрне дә истә тоту бурычы куела.

Сәләй аганың улыннан рөхсәт алып, “Әлифба”га бераз гына үзгәреш кертелә, дөресрәге, бүгенге дәүләт стандартларына туры китererлек итеп үзгәртелә. Китапның эчтәлеге саклана.

Вәгыйзовлар Әлифбасы – ул чын татар Әлифбасы. Укытучыларның да күбесе шушы фикерне яклый. Анда татар колориты бар. Аннан җылылык бөркелеп тора. Башына ак яулыгын япкан әби, түбәтәен кигән бабай – менә ул чын татар мохите.

Бу дәреслек балалар күңеленә патриотик хисләрнең беренче орлыкларын салырга ярдәм итә. Дәреслектә балаларның чынбарлыгы тасвирлана. Бигрәк тә авыл тормышы игътибар үзәгендә тора. Балаларны эшкә өйрәтү, чисталык, пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар үз урыннарын алып торалар.

Балаларга белем бирүдә заманадан артта калмаска, бигрәк тә укучыларның белем алуга кызыксынуларын киметмәскә кирәк. Беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән укучылар яңалык көтә, алар мәктәпкә “укыйбыз” дип килә. Менә шушы омтылышларын сүндермичә, белем алуга булган теләкләрен киметмичә укыту укытучыдан бик күп тырышлык һәм осталык сорый. Баланың башында уй, кулында эш, гамәле төрләнеп торганда гына моңа ирешеп була. Шуны күздә тотып, без укытучылар балаларны укырга һәм язарга өйрәткәндә биремнәрне уйлап, яшь үзенчәлекләрен, аларның кызыксынуларын күздә тотып эшлибез. Дәресләрдә логик күнегүләр, уен, башваткыч, ребус, табышмак, кроссвордлар кебек биремнәр кулланабыз. Алар укучыларның фикерләү сәләтен, хәтерен үстерүгә, мөстәкыйльлеген арттыруга юнәлдерелә.

Безгә дә бу галимнәрнең дәреслекләре белән эшләргә туры килде. Тәҗрибәдән чыгып шуны әйтә алабыз: бу дәреслек чын фидакарь татар балалары үстерүдә бик кирәкле һәм файдалы дәреслек булып тора. Чөнки ничә буын татар балалары шушы дәреслек белән белем дөньясына беренче адымнарын атладылар

һәм аларда татар теленә карата мәхәббәт, ярату хисләре югалмады. Бүген мәгариф җитәкчеләренә дә бу дәреслекне уку программасына кире кайтарырга киңәш итәр идек. Чөнки уңайлы, аңлаешлы дәреслек булмый торып чын татар балалары тәрбияләү мөмкин түгел.

Кулланылган әдәбият исемлеге


5. Мәшһүр галимне хөрмәтләү// Мәгърифәт газетасы, №43 (355), 1998 нче ел.
6. Р.Саттарова. Арча Әлифбаның Ватаны булсын//Арча хәбәрләре газетасы, 3 октябрь, 1998.
7. Александр Филиппов. Бердәнбер “Әлифба” музее// Ватаным Татарстан газетасы, 16 октябрь, 1999.
8. Әлифба язу җиңелме?// Мәгърифәт газетасы, 31 октябрь, 1998.
9. Роза Камалетдинова. Бәрәкәтле гомер//Сөембикә журналы, №9, 2009.



Гаряпова Г.Н.
ТР Спас муниципаль районы
“Никольское урта гомуми белем бирү мәктәбе”МГББУ
туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы


## ТАТАР “ӘЛИФБА”СЫ – МИЛЛИ МӘГАРИФ КҮРСӘТКЕЧЕ


**Аннотация:** В статье рассматривается краткая история развития Азбуки татарского народа – “Алифбы”, прослеживается мысль, что “Алифба” является выразителем духа своего времени, носителем ценнейшей информации о прошлом и настоящем татарского народа, является показателем развития его системы образования. Рассказывается о появлении “синей” “Алифбы” С.Г.Вагизова и Р.Г.Валитовой (1965), как по ней училось не одно поколение татарских детей, а в 1990-е г.г.- и русские дети, что “синяя” “Алифба” стала, по существу, “главным” татарским букварем на протяжении последнего полувека, и не было в XX столетии другого такого татарского букваря-“долгожителя”



**Ключевые слова**: Әлифба, милли мәгариф,халык тарихы, тарихи чыганак


Һәр кеше, үзен укырга өйрәткән китабын, Әлифбасын, хәтерлидер.

“Иртәгә Сара /Мәктәпкә бара./Кара, син аның,/Сумкасын кара. ” (Б.Рәхмәт сүзләре, А.Ключарев музыкасы). Бу җырның беренче юлларыннан ук күз алдыбызга С.Г.Вәгыйзов һәм Р.Г.Вәлитова төзегән “Әлифба”ның тышлыгы килеп баса. Битендә үк үрнәк булырлык идеаль чынбарлык образы сурәтләнгән: кыз бала кара күлмәк, ак алъяпкыч киеп, кулына портфелен, чәчәк бәйләмен тотып, шатланып, горур атлап, белем алырга мәктәпкә бара. Әлифба безне укырга гына түгел, Туган илебезне, үз халкыбызны яратырга да өйрәтә торган дәреслек итеп төзелгән.

Татар халкының 200 еллык тарихы булган “Әлифба” китабы Казан губернасы, Совет Татарстаны, советлардан соңгы чор Татарстаны, бөтен Идел-

Урал регионында һәм аннан читтә дә киң таралган, мәдәниятара элемтәләрдә зур роль уйнаган.

Татар әлифбасы – милли мәгариф, милли хәтер һәм милли тәҗрибә күрсәткече.

Идел Болгары чорында барлыкка килеп, XVIII гасырның соңгы чирегендә тагы да үсеш алган татар милли әлифбасы татар халкы белән бергә катлаулы юл үткән.

XIX-XX гасырларның чикләре татарның “милли яңарышы”, җәдитчелек идеологиясенең таралган чоры, милли мәгариф һәм милли мәдәният өлкәсендәге казанышларны барлау, татар җәмгыятендә балачакка һәм балаларга яңача мөнәсәбәт туу, дөньяви уку әсбаплары, шул исәптән әлифбалар барлыкка килү чоры буларак характерлана. Милләтебез зыялылары яңарышны нәкъ менә балалардан башларга кирәклекне аңлый башлыйлар. Татар балаларын милли традицияләр нигезендә тәрбияләү һәм укыту, шулай ук аларны дөнья мәдәнияте казанышлары белән таныштыру процессында әлифба зур роль уйнаган.

Татарларда мәктәптә белем бирү системасының шактый зур тарихы бар. Ул гасырлар дәвамында формалашкан, ә туган телдә укыту үсеп килүче буынга әхлакый тәрбия бирүнең төп нигезе дип саналган. Татар әлифбасының да озын һәм катлаулы тарихы бар.

Тарихчылар һәм телчеләрнең татар язуына, китап басу эшенә, халык мәгарифенә кагылышлы күп кенә тикшеренүләрендә болгар-татар әлифбаларының Идел Болгары мәктәпләрендә, аннан соң Алтын Урда һәм Казан ханлыгында да кулланылулары турында ачык әйтәләр. Кызганыч, Урта гасырлар татар әлифбалары сакланмаган.

Мәктәп һәм мәдрәсәләр Алтын Урда һәм Казан ханлыгында да булган. Казанның үзәк мәхәлләсе каршында Кол Шәриф җитәкчелегендәге шактый зур мәдрәсә эшләве мәгълүм. Укыту дини төстә алып барылган һәм башка мөселман илләрендәге укытудан аерылмаган диярлек. Монда гарәп графикасында язарга һәм укырга өйрәнгәннәр. Бу уку йортларында булачак дин әһелләре генә түгел, ә бәлки дәүләт хезмәткәрләре, сәүдәгәрләр, галимнәр дә укыган. Монда дөньяви фәннәрдән математика, астрономия, тарих, география, медицина укытылган. Гарәп теле белән беррәттән, XI гасырдан башлап, Шәрык әдипләре һәм шагыйрьләре теле – фарсы теле өйрәтелгән.

Татар дәүләтчелеге бетү белән, фән, мәдәният һәм милли мәгариф традицияләренең дә юкка чыгу куркынычы арта. Мәктәп системасына шактый зыян килә. Казандагы татар уку йортларының эшчәнлеге турында 1551 елгы вакыйгалардан алып XVIII гасырның соңгы чирегенә кадәр вакыт аралыгын чагылдырган мәгълүмат юк диярлек.Мәчетләр төзү туктатыла. Әмма Казан татарлары белем бирүдә милли традицияләрен саклап кала алганнар. Бу юнәлештә мөселман дин башлыклары зур көч куйганнар.

Татар халкында белем бирү, уку-укыту традицияләренең яңаруы XVII-XVIII гасырлар чигендә башлана. Казан губернасында уңай үзгәрешләр 1767 елда Казанга Екатерина II килеп киткәч башлана. 1769 елда Казанда Беренче ирләр гимназиясендә махсус татар сыйныфы ачыла. Татар телен белү, башка

Көнчыгыш телләрен тиз һәм уңышлы үзләштерү өчен, бик әһәмиятле дип танылa.

Рус гимназияләрендә татар телен өйрәтү нәкъ менә "Әлифба"дан башланган. 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә татар телен укыту өчен беренче әлифба басыла.Ул болай исемләнә: "Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочинённая казанских гимназий учителем и адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфиным, и татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях рассмотренная и одобренная». Исеменнән күренгәнчә, "Азбука"ның авторы Казанның Беренче ирләр гимназиясе укытучысы Сәгыйть Хәлфин (1732-1785) була. Ул төзегән икенче дәреслек "Әлифбаи татар" 1787 елда дөнья күрә.

1804 елда, дәреслекләргә ихтыяҗны истә тотып, С.Хәлфиннең оныгы Ибраһим Хәлфин (1778-1829) төрек, гарәп һәм фарсы язуы белән танышу мөмкинлеген ачкан "Азбука и этимология татарского языка" хезмәтен, ә 1809 елда "Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в императорской Казанской гимназиии" дип аталган дәреслек бастырып чыгара.

Соңрак рус телле укучылар өчен Г.Ваһаповның "Мөгаллим әүвәл фи тәгълим лисан әл-гарәп вә әл-фарси әт-татари (1825) һәм М.Бикчуринның "Татарларга русча, урысларга татарча сөйләшергә һәм үзлегеннән укырга өйрәткеч" (1887) дәреслекләре дөнья күрә.

Татар әлифбасын өйрәнүгә күренекле рус педагогы, мәгърифәтчесе Н.И.Ильминский (1822-1891) зур өлеш кертә. Ул керәшен татарлары өчен беренче дәреслек - кириллицада язылган беренче әлифба (1862) төзеп чыгара.

XVIII гасыр урталарыннан Мортаза бине Котлыгыш һәм Ишнияз бине Ширниязның кулъязма әлифбалары киң таралган була. Казанда 1802 елда 11 мең данә тираҗ белән басылган татар әлифбасы "Әттәһәҗи" (дога китабы) сакланып калган басма китапларның берсе. Соңрак ул "Әлифба Иман шарты белән" яисә "Иман шарты" дигән исем астында чыга башлый. Татарлар аны гади генә "Әлифба"(яки "Әлеп би", "Әлпи") дип йөрткәннәр. 125 ел дәвамында китап үзгәрешсез диярлек чыгып тора (аның соңгы басмасы 1928 елда чыга).

Татарларда белемгә омтылу һәм китап басу эше XIX-XX гасырларда милли үзаңның үсеш кичергән чорында аеруча активлашып китә. Яңа ысуллы мәктәпләр баштарак бик аз булса да, 1905 елдан соң Идел буе һәм Урал алды зур шәһәрләренең күпкенә милли мәктәпләрендә укытуда аваз ысулы кулланыла башлый. Яңа ысул белән укыту дөньяви предметлар һәм рус телен укыту белән чикләнми, сыйныфлап дәрес бирүне дә, махсус җиһазландыруны (парта, сыйныф тактасы һ.б.) күздә тоткан. Мәдрәсәдә хәзер мулла түгел, ә укытучы укыткан.

XIX гасыр ахырында татар теле һәм татар грамматикасы проблемаларын мәгърифәтче-галим К.Насыйри кузгата, төрек теле йогынтысыннан азат, мөстәкыйль әдәби татар телен булдыруның кирәклеген нигезли, кулланышка "татар теле" терминын кертә.

Җәдитчелек, таралыш алып, яңа мәктәпләр ачылу, яңа дәреслекләр һәм уку әсбаплары төзелүгә зур йогынты ясый. Тел нормаларын булдыруда 1883 елда

Бакчасарайда нәшер ителүче “Тәрҗеман” газетасы зур көч куя. Аның беренче мөхәррире һәм нашире И.Гаспралы (1851-1914) төрки – татар телен нигез итеп алып, аерым бер стиль эшли.

Чирек гасыр дәвамында – 1890 елларның башы -1917 елларга кадәр – Казанда гына да, төрле мәгълүматлар буенча, 20 дән 60 ка хәтле татар әлифбасы чыга.

1915 елның 2027 июнҗ көннәрендәУфада татар башлангыч мәктәпләре өчендәреслекләр карау һәм сайлап алу буенча киңәшмә үтә. Аның эшендә Г.Ибраһимов, М.Гафури, М.Корбангалиев,х.Бәдигый һ.б. күренекле татар педагоглары һәм җәмәгать эшлеклеләре катнаша. Киңәшмәдә шул вакытка гамәлдә булган 60 әлифбадан 9 ы иң яхшысы дип сайлап алына, 8 көн сөйләшеп-киңәшкәннән соң, 9ыннан да ике генә әлифба сайлана. Болар М.Корбангалиевнең “Татар әлифбасы” һәм Х.Галинең “Тел ачкычы” китаплары була.

Революциягә кадәрге әлифбаларда татар җәмгыяте ниндидер ябык,автоном, “чит берәүләр” булмаган дөнья итеп тасвирланган. Әлифбаларда олы һәм кече Ватан темалары, патриотик тәрбия мәсьәләләре яктыртылмаган. Татр әлифбалары битләрендә тасвирланган дөньяда балалар мәктәптә укый, әти-әниләр авыл хуҗалыгында эшлиләр яисә сәүдә итә, әмма олылар да, кечеләр дә сәясәттән, илдә бара торган әһәмиятле иҗтимагый-сәяси процесстан ерак торалар.

XX гасыр башы татар әлифбалары арасында И.Н.Харитоновның “Бүләк” китабы (1912) аерылып торган.Аның төсле, матур тышлыгында ук, ул чор әлифбаларына хас булмаганча, “Балалар өчен беренче әлифба. Харитон бабай” дип язылган. “Бүләк” физик мөмкинлекләре чикле балалар да куллана алырдай беренче татар әлифбасы була.Китап ахырында чукрак-телсез балалар өчен дактиль әлифба китерелә.

Совет чорында татар милли әлифбасы балалар тәрбияләүнең мөһим чарасына әверелә, аерымчорларда ул олылыарны да Совет властена тугрылык һәм “пролетариаот интернационализмы» рухында тәрбияләү, советча яшәү рәвешен пропагандалау чарасы да булып тора.

“Зурлар өчен әлифба” (1921)-М.Файзулла, “Кызыл юл” (1925) – авторлары М.Фазлуллин һәм Г.Нугайбәк, “Кызылармеең әлифбасы” (1925) – Ш.Саттаров, “Совет мәктәбе” (1927)- Т.Тимербулатов һ.б. 1920 елларында дөнья күргән татар совет әлифбалары төрлелекләре белән аерылып торалар.

М.Х.Корбангалиевнең 1939 елда басылган әлифбасы кириллицада чыккан беренче татар әлифбасы була.Ул, 1946 елда Г.Г.Сәйфуллин “Әлифбасы” чыкканчыга кадәр Совет Татарстаны мәктәпләрендә гамәлдә йөри. Идеаль совет көнкүреше турындагы хыяллар әлифба рәсемнәрендә тормышка ашыра ала. 1942 елдан әлифбаның эчтәлегендә сугыш темасы арта.Дәреслек битләрендә төп дошман – һичшиксез тар-мар ителәчәк фашист образы урын ала.

1946-1964 елларда Г.Г.Сәйфуллинның “Әлифба”сы һәр ел саен – барлыгы 19 мәртәбә басыла. Бу әлифбада этнокомпонет ачык күренә. Күп кенә геройлар, аеруча авыл кешеләре, милли киемннән. “Олы кеше” булып, әни урынына әти

образы чыга. Г.Сәйфуллин “Әлифба”сы балалар уенчыклары рәсемнәре һәм атамаларының күплеге белән дә аерылып тора.

XX гасырның 50 нче елларында ТАССРда милли мәгарифтә дә үзгәрешләр күзәтелә.Республикада татар мәктәпләре бетерелеп, рус телендә укытуга күчү башлана. 1960 елларның урталарында Казанда нибары 5 татар мәктәбе кала. Милли мәктәпләр өчен дәреслекләр, шул исәптән әлифбалар да бастырып чыгару тукталып тора.

Татар әлифбасы үсешенең чираттагы этабы 1960 елларга туры килә. 1962 елда республиканың Мәгариф министрлыгы татар телендәге иң яхшы әлифбага конкурс игълан итә. Шул ук елны конкурска Арча педагогия училиәесы укытучылары С.Г.Вагыйзов һәм Р.Г.Вәлитова үз вариантларын тәкъдим итәләр. Бу “Әлифба” иң яхшы дип табыла һәм 1965 елда басылып чыга. Аны төзүчеләр дәреслектә милли педагогиканың иң уңышлы казанышларын кулланганнар. Китапны бизәү Казан шәһәренең танылган графигы И.Л.Язынинга тапшырыла. 1966 елда бу “Әлифба” бизәлеше буенча Россиядә беренче урынга чыга һәм махсус дипломга лаек була. Р.Г.Вәлитова һәм С.Г.Вагыйзов “Әлифба”сыннан ничәмә-ничә буын татар балалары белем алды.Гаҗәп хәл, әмма факт: мәктәпкә баручы укучы кыз сурәтләнгән “зәңгәр тышлы “Әлифба” соңгы ярты гасыр дәвамында “төп татар әлифбасына әверелә. XX гасырда аныңшикелле “озын гомерле” татар әлифбасы бүтән булмый. Ул бүген дә басылып чыга тора, күп кенә укытучылар аны иң яхшы әлифба дип атыйлар. “Әлифба”да татар балалары һәм аларның әти-әниләре, сыйныфташлары һәм укытучылары, дуслары һәм күршеләре “яши”.

Р.Г.Вәлитова һәм С.Г.Вагыйзовның 1986 елдан безнең көннәргә кадәр татар мәктәбе өчен төзелгән “кызыл” тышлы “Әлифба” берничә басмасы дөнья күрде. “Әлифба” авторлары төп игътибарны татар халкының мәдәни үзенчәлекләренә юнәлткәннәр.

Татар әлифбасы күпмилләтле Россия мәдәниятенең өлеше һәм татар халкы тарихының тарихи чыганагы.

Кулланылган әдәбият исемлеге

1.Галиуллина Д.М., Сальникова А.А. Татар “Әлифбасы”: үткәне һәм бүгенгесе /[русчадан Х.Г.Фәйрахманова тәрҗ.]: монография.-Казан: Татар.кит.нәшр., 2016.-196 б.

2.Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Татар китабы-Татарская книга:альбом/[рәссам Насыйров Ш.К.]-Казан: Татар.кит.нәшр., 2013.-504 б.:рәс.б-н.

3. Марданов Р.Ф., Хадиев И.Г. Татарская книга. -Казан: Татар.кн.изд-во, 2019.-104 с..: с ил.

Гыйбадуллина И.Г.,
Арча муниципаль районы “Д.Хәкимов исемендәге
Түбән Мәтәскә урта гомуми белем мәктәбе”

# ВАГЫЙЗОВ СӘЛӘЙ ҺӘМ ВӘЛИТОВА РӘМЗИЯ “ӘЛИФБА”СЫНЫҢ ЯЗМЫШЫ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

**Аннотация:** “Әлифба” китабы барлык фәннәрнең башлангычы, төп мәгънәсендә олы тормышның башы дип юкка гына әйтмиләр. “Әлифба” һәрберебезне дә укырга, алай гына да түгел, Туган илебезне, үз халкыбызны яратырга өйрәтүче, үзебезне шәхес итеп тоя белүче сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итүче дәреслек. Ул балаларның, янәшә гомер итүче башка милләт балаларының да дөньяны танып-белүдәге әһәмиятле чарасы булып тора. “Әлифба” дәреслеге һәрбер баланың күңелендә могҗиза булып саклансын иде.

**Ачкыч сүзләр:** “Әлифба”, дәреслек, Вагыйзов Сәләй, Вәлитова Рәмзия.

1 нче сентябрь. Иң матур көн – Белем иленә ишекләр ачыла! Бу көнне һәркем – олымы-кечеме – беренче тапкыр мәктәпкә укырга барган минутларын искә төшерә: дулкынланудан йөрәк күкрәк читлегеннән бәреп чыгар төсле тибә, өстә – матур мәктәп формасы, кулда – гөлләмә, ә букчада – китап. Ул – Әлифба! “Әлифба” китабы барлык фәннәрнең башлангычы, төп мәгънәсендә олы тормышның башы дип юкка гына әйтмиләр. Шушы урында якташ язучыбыз, драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Гариф Ахуновның да “Тормышта ике могҗиза бар:берсе-чишмә, икенчесе-әлифба “дигән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр. “Әлифба” һәрберебезне дә укырга, алай гына да түгел, Туган илебезне, үз халкыбызны яратырга өйрәтүче, үзебезне шәхес итеп тоя белүче сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итүче дәреслек. Текстлары бик гади, беркатлы, рәсемнәре дә сабыйлар өчен ясалган кебек тоелса да, аларда тирән мәгънә ята. Һәр халыкның элек тә хәзер дә үз “Әлифбасы” булган һәм бар. Ул балаларның, янәшә гомер итүче башка милләт балаларының да дөньяны танып-белүдәге әһәмиятле чарасы булып тора.

Татар әлифбасы балаларның көндәлек тормышның “үрнәк” моделен булдырырга тырышкан. Һәр баланың да мәктәпкә йөрү мөмкинлеге булмаган, әлифбада язылганча, һәр бала да иртән, шикәр кабып, күмәч белән чәй эчә алмаган.”Әлифба” балаларны укырга һәм язарга гына түгел, математиканы да, әйләнә-тирә дөньяны танып белергә дә, дин нигезләрен дә өйрәткән.

Ничә дистә еллар укучыларга хәреф танытып, аларны белем иленә алып кергән әлифба авторлары да безнең Арчадан бит. "Әлифба" музееның төп нигезен дә Вагыйзов Сәләй Гата улы һәм Вәлитова Рәмзия Гыйлаҗ кызының педагогик һәм иҗат эшләре тәшкил итә. Алар 1965 елдан башлап бөтен татар мәктәпләре өчен булган әлифбаның авторлары, моннан тыш алар 43 төрле дәреслекләр һәм методик китапларның авторлары да. Ә менә буыннан-буынга

шушындый байлык бүләк итүчеләр турында ни генә беләбез икән? Сәләй (Сөләйман) Самара өлкәсенең хәзерге Камышлы районы, Татар Байтуганы авылында дөньяга аваз сала. Алты айлык чагында әтисе вафат була. Әнисе туган ягына кайтып китә. Сабый бала әбисе тәрбиясендә кала. Әмма, хәле начарайгач, Сәләйне авылдашлары Гататдин абый белән Гайшә апага тәрбиягә бирергә мәҗбүр була. Рәмзия апа исә Башкортстаннан. Җиде яшьтән ятим калган кыз Эстәрлетамак балалар йортында тәрбияләнә. Егет белән кызны Казан педагогия институты кавыштыра. Мөгаен, авырлыклар кешегә яшәргә көч бирә, дигәннәре дөрестер ул. Арча педагогия училищесына кайтып эшли башлагач та, бәхеткә тиенгән көннәргә сугыш чик куя. Завуч булып эшләгән Сәләй ага фронтка киткәч, аның урынын Рәмзиясе алыштыра. Көн дә хәбәр көтеп, исән кайтуын өмет итеп яши ул. Әмма... өмете тиз генә акланмый. Сәләй ага Харьков янында немецларга әсирлеккә эләгә. Аннан котылгач, аны Печора лагерена сөрәләр. Рәмзия апа ике нарасыен җитәкләп, ике мәртәбә ире янына бара. Мондый сәяхәтләрнең ахыры бик аянычлы була: аны эшеннән куалар. Ә ире, сабыйларны саклап калу ниятеннән, аңа үзеннән баш тартырга киңәш итә. Әле аннан соң да бары тик кайчандыр бергә укыган, ул вакытта зур урыннарда эшләгән дуслары ярдәмендә генә яңадан эшкә урнаша ала. Рәмзия апа шул көннәрдән алып 1969 елга кадәр Арча педагогия училищесында татар теле, әдәбияты һәм методикасы укыта. СССР халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исемнәргә лаек була. Сәләй абый да исән-сау әйләнеп кайткач, гомерен балалар укытуга багышлый: башта мәктәптә укытучы, Роно инспекторы, аннан педучилищеда татар теле, әдәбияты һәм методикасы укытучысы. Ул – Татарстанның атказанган укытучысы, Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы, К.Д. Ушинский медале иясе. Болары – ике галимнең катлаулы тормыш юлыннан өзекләр генә...

Көчле рухлы булган Сәләй ага белән Рәмзия апа. Авырлыклар, гаделсезлекләр бу икәүнең бер булып типкән йөрәкләрен ташка әйләндерә алмаган, күңелләре тупасланмаган аларның. Шулай булмаса, җиң сызганып нәкъ менә сабыйлар өчен булган дәреслеккә – әлифбага тотына алырлар идеме икән алар?!

1962 нче елда республиканың Мәгариф министрлыгы татар телендәге иң яхшы әлифбага конкурс игълан итә. Шул ук елны конкурска Арча педагогия училищесы укытучылары С. Г. Вагыйзов һәм Р.Г. Вәлитова үз вариантларын тәкъдим итәләр. Бу “Әлифба” иң яхшы дип табыла һәм 1965 нче елда басылып чыга. 1965 елдан башлап һәр татар баласы нәкъ менә шул – Сәләй Вәгыйзов (Сөләйман Хәлиуллин) һәм аның тормыш иптәше Рәмзия Вәлитова-Вәгыйзова язган Әлифба буенча укырга, язарга өйрәнгән. Галимнәр әйтүенчә, чит илләрдә яшәүче татар балалары әле бүген дә нәкъ менә шушы Әлифбаны куллана икән. Китапны бизәү эше Казан шәһәренең танылган графигы И.Л.Язынинга тапшырыла. 1966 нчы елда “Әлифба” бизәлеше буенча Россиядә беренче урынга чыга һәм махсус дипломга лаек була. С. Г. Вагыйзов һәм Р.Г. Вәлитованың өчьеллык башлангыч мәктәп өчен зәңгәр тышлы, ә дүртьеллык татар мәктәбе өчен кызыл тышлы булып чыгарыла. “Кызыл” “Әлифба”да, “зәңгәр”енә

караганда, балаларга күбрәк һәм алар үз шөгыльләрендә бик актив. Алар елга буенда чәчәкле болында йөриләр, комлыкта уйныйлар, көймәдә йөзәләр. Дәрес әзерләү, уку, санау, мәктәп остаханәсендә эшләү, йорт эшләрендә катнашу кебек җитди эшләрне дә алар чын күңелдән башкаралар."Әлифба"дагы кыз балалар милли күлмәкле курчаклар белән уйныйлар, өчпочмак, бәлеш кебек милли ризыклар белән сыйланалар. Агач атка атланган малайның кулында суверен Татарстан флагы җилферди. "Әлифба" авторлары төп игътибарны татар халкының мәдәни үзенчәлекләренә юнәлткәннәр. Ә чынлыкта элифба язу ничек була икән ул? Җиңелләрдән түгелдер. Моның өчен бит бөек укытучы да, күпкырлы галим дә, шул ук вакытта сабыйларча фикерли белү дә кирәк. Ирексездән, Рифә Рахманның "Әлифба" шигыре искә төшә:

Язган әдип китап, язган галим китап,
Хәтта патшаларның калган китаплары!
Изге Коръән сүзен укыр өчен дә бит,
Таный белү кирәк "әлиф" белән "ба"ны.
Бәйрәмнәрнең бүген бәйрәмнәредер бу,-
Дөньялыкның ашы, ахирәтнең башы.
Әлифбаны язу- җәннәтләргә лаек,
Ул бит – белемнәрнең тәүге бисмилласы.

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов та заманында болай дип язып калдырган: "Балачагымның якты көннәрен кабат исемә төшергәннәре өчен "Әлифба" авторларына мең-мең рәхмәт. Шушы "Әлифба"ны укып күзләре ачылган ун меңләгән бала, еллар узгач, зиһеннәре арта төшкәч, Рәмзия апа белән Сәләй агага, минем кебек үк, рәхмәт әйтерләр дип ышанам". Мондый рәхмәтләр чиксез булыр әле зәңгәр тышлы, матур рәсемле әлифба хуҗаларына!

Заманалар узу белән белем дөньясының ачкычы булып хезмәт иткән бу китап та үзгәрешләр кичерде. Тел белеме, укыту методлары заман агында туктаусыз үсеп, камилләшеп тора. 2012 нче елда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән Федераль дәүләт стандартларына һәм "Переспектив башлангыч мәктәп" концепциясенә нигезләнгән татар мәктәбендә укучы балалар өчен И.Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина авторлыгында "Әлифба" китабы чыгарды. Укыту комплектына "Әлифба" дәреслеге, 2 язу дәфтәре һәм методик кулланма керә. Дәреслек балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп төзелгән. Төсле рәсемнәр аша бирелгәнгә күрә, ул һәр баланы үзенә җәлеп итә. Рәсемнәр сөйләм телен үстерергә ярдәм итә, балалар тормышына якын сюжетлы һәм предметлы. Үстерелешле укыту принциплары белем бирүнең традицион принциплары белән тыгыз бәйләнештә бара. Әлифба дәресләре аша баланың тәҗрибәсеннән чыгып, киләчәктә фән буларак татар телен өйрәнүгә нигез салына. И. Х.. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина авторлыгында чыгарылган "Әлифба" китабы яңа стандартлар таләбенә туры китерелеп төзелгән һәм бүгенге көндә укытуда бик уңышлы дәреслек булып тора. "Әлифба" дәреслеге һәрбер баланың күңелендә могҗиза булып саклансын иде.

Кулланылган әдәбият исемлеге:

1. Алла Сальникова, Диләрә Гаиуллина “Татар “Әлифба”сы:үткәне һәм бүгенгесе”, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2016.-31-40 б.
2.Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана: Татарча уку-язуга өйрәнү методикасы һәм татар әлифбалары тарихы. Казан, 1994.-66 б.

Гыйләҗиева Чулпан Хәйдәр кызы,
ТР Арча МР МБГБУ «Г.Курсави исемендәге күппрофильле лицей
башлангыч сыйныфлар укытучысы

## ӘЛИФБА – БЕЛЕМГӘ ЮЛ КҮРСӘТҮЧЕ МАЯК

Һәркемнең дә белем дөньясына тәүге адымы әлифбадан башлана. Шуңа да әлифба белемгә юл күрсәтүче маяк булып тора. Ә бу сүзне ишетүгә күпләребез бала чагыбызга әйләнеп кайтабыз һәм кулына портфель тоткан, ак алъяпкычлы кыз сурәте төшкән китабыбызны күз алдына китерәбез. Әйе, белем алуга этәргән бу мөлаем кызга һәрберебез сокланып карый идек, аңа ошарга тырыша идек. Белем дәрьясына капка булып хезмәт иткән бу китап, мөгаен, һәрбер укучының иң беренче, иң якын дусты булгандыр. Р.Вәлитова, С.Вагыйзов иҗат иткән “Әлифба” дәреслеге ничә буын мәктәп укучысын белем дөньясына алып керде. Шуңа да бүгенге көндә дә аларның хезмәтен зур горурлык белән искә алабыз.

Заманалар узу белән белем дөньясына ачкыч булып хезмәт иткән бу китап та үзгәрешләр кичерде. Тел белеме, укыту методлары заман агышында туктаусыз үсеп, камилләшеп тора. 2012 нче елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән Федераль дәүләт стандартларына һәм “Переспектив башлангыч мәктәп” концепциясенә нигезләнгән рус мәктәбендә укучы татар балалары өчен И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина авторлыгында “Әлифба” китабы чыгарылды. Укыту комплектына “Әлифба” дәреслеге, 2 язу дәфтәре һәм методик кулланма керә. Дәреслек балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп төзелгән. Төсле рәсемнәр аша бирелгәнгә күрә, ул һәр баланы үзенә җәлеп итә. Рәсемнәр сөйләм телен үстерүгә ярдәм итә, балалар тормышына якын сюжетлы һәм предметлы. Анда үстерелешле укыту принциплары белем бирүнең традицион принциплары белән тыгыз бәйләнештә бара.

“Әлифба” – грамотага өйрәтү өчен төп дәреслек, чөнки грамоталыкның башлангыч нигезе нәкъ шушы чорда башлана. Балаларда бу чорда тел системасының төп берәмлекләре булган аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст турында күзаллау барлыкка килә. Авазны әйтү һәм ишетү күнекмәләре формалаша. Аваз шартлы модель (түгәрәк – сузык, квадрат – тартык) билгеләре ярдәмендә аңлатыла. Сүзнең аваз һәм хәреф моделе аша балаларда уку күнекмәләре формалаша. Әлифбагача чорда дәресләр сөйләм үстерүгә корылган. Бу чорда бала текст тыңлый, иллюстрацияләр аша җөмлә төзү күнекмәләренә ия була. Әлифба чоры балаларны сузык авазлар һәм аларга билге булып килгән

хәрефләр белән таныштырудан башлана. Сузык авазлар иҗек төзиләр һәм бу уку технологиясен өйрәтүдә мөһим чор булып тора. Сузык авазлардан соң, парсыз яңгырау тартыклар өйрәнелә һәм иҗек төзү күнекмәләре бирелә. [ й ] авызын өйрәнгәннән соң, ике аваз кушылмалары белән танышу башлана. Бу авазларның [ й ] һәм тиешле сузыкка билге булып килүе өйрәтелә. Алга таба тартыкларның яңгырау һәм саңгырау парлары белән таныштыру башлана. Аннан соң, парсыз саңгырау тартыклар һәм ь, ъ билгеләре өйрәнелә. Әлифба чорының ахырында балалар сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын, иҗекләргә бүленүен, һәр иҗекнең көчлерәк, озынрак әйтелүен, сүзләрнең предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүен, ярдәмче сүзләрнең сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын, схема буенча бирелгән сүзләрне иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укый ала белергә тиеш, ягъни хәрефләрне авазларга күчерергә өйрәнә. Шулай итеп, беренче сыйныф укучысы кыска гына вакыт эчендә авазларны өйрәнү аша сүзләр, җөмләләр һәм текстларны укый башлый. Дәреслектәге авазларны өйрәтү аерым бер системага нигезләнеп башкарыла һәм балалар уку күнекмәләрен тиз үзләштерәләр.Текстлар да балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килеп сайланган. Иң уңайлысы, халык авыз иҗаты әсәрләренең: табышмак, мәкаль, әйтем, тизәйткеч, санамышларның бирелүе укучыларда укуга кызыксыну уята. ”Әлифба” буенча грамотага ирешү дәресләрендә балаларның фонематик ишетеп аңлау һәм аваз культурасы үсешенә сүзләрне үстерү һәм аларны үзгәртеп төзү алымы аша ирешергә мөмкин. Сүзләрне үстеү ул – алардагы авазларны арттырудан гыйбарәт. (Ал – ала – алан – аланлы – аланлык, сан – сана – санак – санаклы). Мондый алымнар куллану укучыларда күзәтүчәнлекне арттыра һәм сүзнең мәгънәсен аңлау аша, уку техникасы үсешенә дә ярдәм итә. Сүзләрне үзгәтеп төзү алымы (сүзгә бер аваз өстәү яки бер авазын үзгәртү) алымы да укчыда укуга кызыксыну тудыра һәм логик фикерләү сәләтен үстерүгә дә ярдәм итә. Мәсәлән, акча – бакча, бүре – бүрек. Грамотага ирешү чорында бала басма һәм язма хәреф билгеләренең формаларын үзләштерә. Язарга өйрәнү дәфтәрендә бирелгән хәефләрнең өлге элементлары аша укучы хәреф формасын үз куллары белән төзи. Бу алым укучының хәтерен яхшырта, укуга булган омтылышын арттыра.

Уку белән беррәттән балалар язарга да өйрәнәләр. Язу барышында бала авазның язма хәрефен күңелендә тудыра, шул авазның нинди хәреф билгесе белән белдерелүен искә төшерә һәм хәрефне дөрес язарга өйрәнә. Язуга өйрәтү уку кебек өч этаптан: әзерлек, төп һәм йомгаклау этабыннан тора. Әзерлек этабында татар алфавитының язма хәреф элементлары белән танышалар. Төп өлештә балалар барлык язма хәрефләрне иҗекләрдә, сүзләрдә, җөмләләрдә, кушып язу күнекмәләре алалар. Йомгаклау этабында балаларның язуларындагы график һәм каллиграфик хаталар төзәтелә, график күнекмәләр ныгытыла.

Шулай итеп, грамотага өйрәтүнең йомгаклау чорында укучы туган телнең сөйләм төзелешен аңлый, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы итеп күзаллый, татар алфавитының басма һәм язма хәрефләренең график системасын, һәр хәрефнең элемент формаларын, дөрес

утыру һәм язу әсбапларын куллану кагыйдәләрен белә, һәр укучы үзенә генә хас темпта, басма һәм язма текстларны орфоэпик нормаларга туры китереп укый, текстның аерым бер өлешләренең эчтәлеген сөйли һәм бирелгән сорауларга җавап бирә. Шулай итеп, әлифба дәресләре аша, баланың яшь үзенчәлекләреннән һәм тәҗрибәсеннән чыгып, киләчәктә фән буларак татар телен өйрәнүгә нигез салына. И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина авторлыгында чыгарылган "Әлифба" китабы яңа стандартлар таләбенә туры китереп төзелгән һәм бүгенге көндә укытуда бик уңышлы дәреслек булып тора.

Әлифба – туган телне предмет буларак өйрәнүдә беренче дәреслек. Шуңа да укучы бала белем дөньясының могҗизалы серләренә шушы китап аша төшенә. Моның чыннан да могҗиза булуын якташ язучыбыз Гариф Ахунов сүзләре тагын бер кат раслап куя. "Минем өчен тормышта ике нәрсә гомер буе могҗиза булып сакланып килде: берсе - Чишмә, икенчесе - Әлифба". Әлифба һәрбер баланың күңелендә гомер буе могҗиза булып саклансын иде.

1. "Әлифба" дәреслеге, "Мәгариф-Вакыт" нәшрияты, 2012.
2. Методик кулланма, "Мәгариф-Вакыт" нәшрияты, 2012.

Гибаева Х.Ф.
"МБОУ "Старочурилинская СОШ" Арского района РТ,
учитель начальных классов

# ӘЛИФБАНЫҢ ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

**Аннотация**: История школьного образования и просветительства у татар имеет глубокие исторические корни. Развитие татарского образования напрямую связано с историей развития государственности и распространением ислама в Среднем Поволжье. История советской алифбы напрямую связана с политикой правительства в отношении татарского языка и его графики. Татарская азбука под авторством Рамзии Валитовой и Салея Вагизова является настоящим учебником-долгожителем. Салей Вагизов и Рамзия Валитова являются первыми авторами азбуки для детей для изучения татарского языка. Книга изменялась и дополнялась 41 раз, по ней учились 3 поколения татарстанцев.

**Ключевые слова:** Әлифба, тарих, С.Г.Вәгыйзов һәм Р.Г.Вәлитова, методика.

Күренекле әдип Гариф Ахуновның мондый сүзләре бар: "Минем өчен тормышта ике генә нәрсә могҗиза булып сакланып килде: берсе – Чишмә, икенчесе – Әлифба". Белем иле ишекләрен "Әлифба" дигән тылсымлы ачкыч ярдәмендә ачып керәбез. Әлифбаның үткәненә күз салсак, аның тарихы еракларга барып тоташканлыгына төшенәбез. Ул "ачкыч"ны ясаган "осталар" моңа кадәр булганнарын да җентекләп өйрәнгәннәр, алардагы кайбер үзенчәлекләрне кабатларга, кайберләрен онытырга кирәк дип тапканнар. Беләбез бит: халкыбыз гомер - гомергә укымышлы булган. Уку- язу графикасы еллар дәвамында үзгәреп, алышынып торган чакта да, тиз арада яңача укытуга

яраклашкан. Димәк, тарихи әлифбаларыбыз да төрле-төрле графикаларда дөнья күргән.

1950 нче елда елларда татар мәктәпләрен әкренләп бетерү һәм аларда рус телле укытуга күчү эше башлап җибәрелә. 1950 нче елларда милли мәктәпләр өчен яңа дәреслекләр, шул исәптән әлифбалар эшләү һәм бастыру эше туктатыла. 1958 нче елгы Закон бу хәлне тагын да катлауландыра, чөнки ата-аналарга мәктәп сайлау хокукы бирелә, татар мәктәпләре рус телле укытуга күчерелә һәм татар теле өстәмә предмет буларак кына өйрәнелә башлый. 1960 нчы еллар уртасында Казанда бары тик биш татар мәктәбе генә кала, шуларның икесе – сигезьеллык.

1960 нчы еллар башында ТАССРда милли мәктәпләр өчен яңа Әлифба булдыру буенча эше башлана. Республика мәгариф министрлыгы татар телендәге иң яхшы Әлифбага бәйге игълан итә. 1962 нче елда Арча педагогия училищесы укытучылары С.Г. Вәгыйзов һәм Р. Г. Вәлитова үз вариантларын эшләп тәкъдим итәләр.

1960 нчы елда төзелә башлаган Әлифба, шулай итеп, балалар кулына бары тик 1965 нче елда гына барып ирешә. Сәләй Вәгыйзов һәм аның хатыны Рәмзия Вәлитова дәреслек өстендә биш ел эшлиләр, аны булдыруда татар мәгариф тарихында булган барлык туган халыкларның эшләнмәләре һәм тәҗрибәсе кулланылган. Баштарак Сәләй аганы «фән кандидаты булмаган башың белән монда буталып йөрмә» дип, Әлифбасы-ние белән борып җибәрәләр. Шулай да Татарстан Мәгариф министрлыгы оештырган бәйгедә бу дәреслек икенче урынны ала. Беренче урын бөтенләй бирелми. Шуннан соң Рәмзия апа белән

Сәләй ага иҗат иткән дәреслекләргә юл ачыла да инде. Китапның сәнгатьчә бизәлеше Казанның танылган графигы
И.Л.Язынинга йөкләнә. Аның Г.Сәйфуллин әлифбасы өстендә эшләгәндә алган билгеле бер эш тәҗрибәсе була. Бу әлифба өчен әзерләгән кайбер рәсемнәр, стилистик һәм тематик яктан С. Вәгыйзов һәм Р. Вәлитова “Әлифба”сында кабатлана. 1966 нчы елда бу әлифба сәнгатьчә бизәлеш буенча Россиядә беренче урынга һәм махсус дипломга лаек була.

Әлифбага өстәмә кулланма буларак авторлар "Рәсемле әлифба” (рәсемнәрдәге Әлифба) да эшләп чыгаралар. Аның өчен үрнәк булып А.И.Воскресенскаяның “Әлифба рәсемнәрдә” (1960 ел) китабы хезмәт итә. А 4 форматындагы 35 рәсемнән торган һәм папкага урнаштырылган бу ярдәмлек иң элек укытучылар өчен эшләнелгән булган. Бу ачык һәм матур рәсемнәрнең һәрберсе - татар әлифбасындагы хәрефләр һәм шул хәрефләргә башланган предметлар. Авторлар кереш сүздә балаларның хәрефләрне еш бутаулары һәм онытулары турында язалар, шуңа күрә мондый күрсәтмә ярдәмлекнең кирәк икәнлеген искәртәләр. Иллюстрацияләрдә балаларга таныш үсемлек һәм хайваннар дөньясы, шулай ук заманча техника, мәсәлән, вертолет (“в”) рәсемнәре тәкъдим ителә. Рәссамнар төбәкнең милли үзенчәлеге турында да онытмаганнар. Мәсәлән: “Һ” хәрефенә иллюстрация буларак Казандагы Г. Тукай һәйкәленең рәсеме ясалган. Китапның сәнгать мөхәррире - Г. Сәйфуллинның әлифбасы өстендә эшләгән Э. Я. Дьячкова. Әлифбаны бизәүгә П. Н. Григорьев, Р. А. Сабитова, Л. П. Анисимов кебек башка рәссам-графиклар да җәлеп ителә.

Сәләй ага Вәгыйзов һәм Рәмзия апа Вәлитова иҗат иткән татар “Әлифба”сы 1965 – 2006 нчы елларда 42 тапкыр басылып чыга. Моннан тыш педагоглар башлангыч сыйныфлар өчен туган тел һәм татар теле дәреслекләре, аларга методик кулланмалар, дидактик материаллар әзерлиләр һәм аларны яңартып торалар. С.Вәгыйзов һәм Р.Вәлитова хезмәтләре татар мәктәбенең башлангыч сыйныфларында татар теле укыту методикасына, аны камилләштерүгә юнәлтелгән. Алар Әлифбаны латин хәрефләре белән төзергә өлгерәләр. Тагын укытучыларның өстәл китабына әверелгән уку китаплары, татар теле дәреслекләре, «Кызыклы грамматика», «Матур язу» дәфтәрләре... Аларның барысы да бүген укытучылар һәм укучылар кулында.

“Сәләй Гататович ул зур шәхес, киңкырлы эрудит, авызына каратып тота торган лектор, кызыклы әңгәмәдәш, киң күңелле кеше булды”, - дип искә алалар аның замандашлары.

Кеше борын заманнан ук балаларны ана теленә өйрәткән, аның телен шомартуга, сүзлек хәзинәсен арттыруга, сөйләгәндә һәм язганда, аннан оста файдалануга бик нык игътибар иткән.

Ана, баласына “тел ачкычы” бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уеннар оештырган: үсә төшкәч, такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән, бәетләр әйткән, әкиятләр сөйләгән.

Әлифба авторы Сәләй Вәгыйзов әлифбадан тыш яңадан кырыктан артык китап һәм дәреслек язган. Күбесен Рәмзия Вәлитова белән берлектә. “Кызыклы грамматика” дигән китабы үз авторлыгында басылган. Сәләй Вәгыйзов балага

белем һәм тәрбиянең аеруча үтемле итеп уен аркылы бирелгәнлегеn яхшы аңлаган. Уйнаган вакытта бала күп нәрсә таный, күнекмәләр ала.

Мәсәлән, сыйныф өч төркемгә бүленә, өч бирем бирелә. Ук-уч-ут, ат-эт-ит, шәл-шәм-шәп, бал-тал-мал, таш-теш-түш, чана-тана-сана, туп-тап-төп. Бу сүзләрне төзегәндә нинди эзлеклелек күрәсез? Бер-берсеннән бер сузык яки бер тартык аваз хәрефе белән генә аерыла торган сүзләр, шулай бит. Дәвам итәбез.

Аш-таш, ат-хат, ай-тай, иләк-җиләк, азык-казык, аяк-таяк, порт-спорт, кран-экран, ун-тун. Я, бу сүзләр нәрсәсе белән аерыла? Сүзнең башына бер аваз өстәү принцибы белән ясалган сүзләр, әйеме?

Чын-лачын, мәк-икмәк, шәм-түшәм, су-алсу, тән-иртән, тап-китап, ай-бодай... Монда ничек? Үзегез күрәсез, алдыбызда иҗек өстәү юлы белән ясалган сүзләр.

Таба-бата, каба-бака, Куба-Баку, кесә-сәке, чабак-бакча, бая-яба, дару-руда, акбаш-башак... Бу сүзләрдә иҗек урыннары алышынган.

Бара-бәрә, булу-бүлү, бора-бөрә, тора-төрә, тотын-төтен,туза-түзә,кыса-кесә... – калынлы-нечкәле парлы сүзләр.

Чәчә, Ләлә, ләкләк, чәкчәк, былбыл, мәрмәр, зәмзәм, биби, тартар – бертөрле иҗекләрдән торган сүзләр.

Чәч, тот, апа, уку, ата, ипи, кадак, кабак, надан – кайсы башыннан укысаң да, бер үк сүз килеп чыга.

Балалар белән сүз төзү уеннарын бик күп кулланырга була. Сәләй Вәгыйзовның “Кызыклы грамматика” китабында алар бихисап.

Татар балаларының берничә буыны Р.Г. Вәлитова һәм С. Г. Вәгыйзов әлифбасы нигезендә укырга һәм язарга өйрәнгән. Гади һәм истә калдыру өчен җиңел текстлар, шигырьләр, ачык рәсемнәр уку процессын мавыктыргыч һәм кызыклы иткән.

Сәләй Гататович Вәгыйзов һәм аның хатыны Рәмзия Гыйләҗевна Вәлитова Арчада озак еллар яшәгәннәр, балалар үстергәннәр һәм үзара ярдәмләшеп иҗат иткәннәр. Бик тә эшчән, пөхтә, төгәл кешеләр, гаять тирәнтен, күпкырлы гыйлем ияләре булганнар. Икесе дә — педагогика галиме, Россиянең халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты исемнәренә лаек булган шәхесләр.

Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Әхмәтҗанова Ф. Әлифбага юл өзелми. **100tatarstan.ru**›news/tarikhta-bu-knne/lifbaga-yul… (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.10.2023)

2. Галиуллина Д.М, Сальникова А.А. 1940-50 нче елларда татар әлифбасы. **kpfu.ru**›staff_files/F1212642458/Bukvar_Galiullina… (мөрәҗәгать итү вакыты: 12.10.2023)

3. Таҗиев Д. С.Вәгыйзовның “Кызыклы грамматика”сы турында. **arskmedia.ru**›news/sezne-khatlar/sly-vagyyzovny-… (мөрәҗәгать итү вакыты: 14.10.2023)

# СЕКЦИЯ 4. РОЛЬ СОВРЕМЕННЫХ БУКВАРЕЙ В ФОРМИРОВАНИИ ФУНКЦИОНАЛЬНОЙ ГРАМОТНОСТИ

# 4 НЧЕ СЕКЦИЯ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫК ФОРМАЛАШТЫРУДА ЗАМАНЧА ӘЛИФБАЛАРНЫҢ РОЛЕ

Ахметзянова Л.А.
г. Елабуга, ОШ «Университетская» ЕИ КФУ,
учитель начальных классов

## РОЛЬ АЗБУКИ В ФОРМИРОВАНИИ ФУНКЦИОНАЛЬНОЙ ГРАМОТНОСТИ УЧАЩИХСЯ

**Аннотация.** В статье рассмотрен вопрос формирования функциональной грамотности учащихся начальной школы. Представлено описание методических приемов работы на уроках по формированию читательской грамотности на этапе изучения Азбуки. Сделан вывод о том, что осознанности чтения необходимо уделять особое внимание, особенно в начальной школе.

**Ключевые слова:** функциональная грамотность, читательская грамотность, азбука, метод, приём.

В последние несколько лет в нашей стране наблюдается снижение уровня читательской культуры населения, и интерес детей к чтению не исключение. Чаще всего в настоящее время чтение книг заменяется просмотром телепередач, компьютерными играми, общениями в социальных сетях. Поэтому одна из важнейших задач современной школы – формирование функционально грамотных людей.

Что такое «функциональная грамотность»?

Функциональная грамотность – способность человека вступать в отношения с внешней средой, быстро адаптироваться и функционировать в ней.

Современные требования времени таковы, что каждый день наши дети сталкиваются с огромным количеством задач, которые необходимо не только решить, но и найти рациональное и неординарное решение. Перед учителем ставятся новые задачи: научить не только грамотно решать эти задачи, но и делать выводы, уметь самостоятельно добывать необходимую информацию. Функциональная грамотность – это, прежде всего, умение работать с информацией. Таким образом, основная цель учителя - развить ребёнка, т.е. научить работать с информацией. А основы функциональной грамотности мы должны закладывать уже в начальной школе!

Одной из главных составляющих функциональной грамотности является читательская грамотность. Формирование читательской грамотности у младших школьников начинается на уроках литературного чтения, где как раз идет

интенсивное обучение различным видам речевой деятельности – письму и чтению, говорению и слушанию.

С давних пор первой книгой для обучения грамоте является азбука. Азбука – самая первая книжка, которая открывает малышу дорогу в мир знаний. Для того чтобы этот путь был интересным, увлекательным, современная азбука для детей, созданная заботливыми разработчиками, не просто учебник, а самый настоящий наставник для ребят, который учит дружить, любить свою семью, свою родину, думать, размышлять, делать выводы, анализировать.

Азбука в начальный период обучения является одним из главных средств познания мира. В этот период обучения чтение становится мощным средством

о

б Ни для кого не является секретом, то, что многие дети приходят в школу уже умеющими читать, но есть и дети, те которые совсем не умеют читать. Это создает некоторые трудности в обучении. Но современный учебник азбуки построен так, что в нем есть материал для детей, которые хорошо читают и для тех, кто только учится читать. В азбуке представлены задания для работы в паре и в группе, работа со словарем, задания повышенной сложности.

н При изучении азбуки учащиеся знакомятся с самыми простыми грамматическими понятиями на известных им литературных произведениях, на сюжетных картинках. Дети вспоминают сказки, задают вопросы друг другу, составляют предложения, описывают иллюстрации со сказочными героями. Большое внимание уделяется осмыслению значений пословиц: «Азбука — к мудрости ступенька», «Ученье — путь к уменью» и т. д. При чтении и работе с текстами школьники готовят совместно выступления на заданную тему, вспоминают стихотворения, рассказывают о своих наблюдениях, слушают товарищей, задают собственные вопросы. Многообразие упражнений по каждой теме помогает легче и быстрее запомнить изучаемый материал. В букварный (основной) период обучения грамоте в учебнике даны упражнения такие как: составление предложений по заданным словам, определение значений слов, различие одинаковых по написанию и звучанию, но разных по значению слов, озаглавливание текстов, продолжений рассказов, игры с превращением слов. Очень много заданий в «Азбуке» на развитие связной речи. Ведется работа по развитию устной речи учащихся. Это составление предложений на определенную тему: о маме, о школе, о детях («Расскажи о своем дне рождении», «Кого ты пригласил?); небольших устных рассказов по сюжетным картинкам, по личным наблюдениям детей (по вопросам учителей). На каждый урок в азбуке отводится две страницы, которые содержат текстовой материал: столбики слов, предложения и тексты для чтения. Текстовой материал дополняется иллюстративным - предметными и сюжетными картинками. Кроме текстового материала и иллюстраций, «Азбука» содержит разнообразные внетекстовые элементы, такие как схемы слов и предложений, слоговые таблицы, лента букв, которые способствуют выработке техники чтения и развитию речи и мышления.

о

п

ы

т

а

В учебнике широко представлен разнообразный занимательный материал: ребусы, «рассыпанные» слова, «цепочки» слов, скороговорки. Главное назначение игрового материала — воспитывать у детей любовь и интерес к родному языку, способствовать развитию их речи и мышления.

Таким образом, весь материал учебника помогает развивать мотивацию к обучению, учить учащихся самостоятельно добывать знания, развивает интерес к предмету, учит работать с книгой и текстом, развивает познавательную активность, формирует и развивает читательскую грамотность учащихся.

В добукварный период, который является промежуточным звеном между игровой и учебной деятельностью, авторы учебника особое внимание уделяют сказкам.

А как показывает практика, многие дети очень плохо знают народные сказки. Поэтому по сказкам провожу различные виды работы. В учебнике изображены сюжетные картинки, к ним даются задания, такие как:

- вспомни сказку, составь предложение по схеме;
-какой эпизод изображен на рисунке;
-назови героев сказки;
-рассмотри рисунки, перескажи сказку;
- вспомни сказку, восстанови последовательность событий;
-придумай с другом другой конец сказки.

Так же особый интерес у детей вызывает инсценирование сказок. Дети стараются изобразить характерные движения героев. После проигрывания сказок обязательно оцениваем героев, обмениваемся мнениями.

При работе со сказками провожу устный информационный диктант «Я знаю названия сказок или имена героев…»

Например: Лиса и …. ; Волк и ….; Курочка …..; Кот в …. .

Можно использовать прием «Определи соответствие».

Класс делится на группы, в каждой группе есть читающие и не читающие дети. Каждой группе выдаются сюжетные картинки и карточки с названием сказок, дети определяют соответствие.

Использую «Лексические диктанты» - включаю слова и выражения, которые надо растолковать. Такая работа обогащает словарный запас детей.

Часто использую методический прием «Тонкие и толстые вопросы». «Тонкие вопросы», такие как, «кто», «что», «когда», «как звать», «согласны ли вы» требуют лишь знание текста. «Толстые вопросы», такие как, «объясните, почему», «что будет, если», «в чем различие» требуют размышления, привлечения дополнительной информации. Приём «Тонкие и толстые вопросы» обучает ребёнка на практике применять новые знания и соотносить их с уже полученными знаниями; отрабатывает умение формулировать вопросы; воспитывает уважение к различным мнениям и взглядам на одну и ту же проблему.

Сочетание рассмотренных методических приёмов, используя коммуникативно - деятельностный подход, позволяет эффективно построить работу на уроке по формированию читательских умений.

Содержание современного учебника «Азбука» имеет большое значение для дальнейшего развития и успешного обучения выпускника начальной школы. Важно научить младшего школьника учиться полноценно воспринимать художественную литературу, эмоционально отзываться на прочитанное, высказывать свою точку зрения и уважать мнение собеседника.

Важно помнить, что эффективность работы, прежде всего, зависит от учителя, задача учителя, выступать организатором учебной деятельности, стать заинтересованным и интересным соучастником этого процесса. Тогда с уверенностью можно будет сказать словами И.Г.Песталоцци: «Мои ученики будут узнавать новое не только от меня; они будут открывать это новое сами».

Список использованных источников

1. Критическое мышление: технология развития: Пособие для учителя / И. О. Загашев, С. И. Заир-Бек. – СПб: Альянс «Дельта», 2003.
2. Формирование читательской грамотности у младших школьников (Из опыта работы педагогов Липецкой области) / под редакцией Е.Е.Пановой. - Липецк: ГАУДПО ЛО «ИРО», 2020. - 116 с.
3. Доскарина Г.М. Исследование в действии: Способы и приемы повышения уровня читательской грамотности учащихся / Г.М.Доскарина, А.С.Сабитова // Молодой ученый. – 2016. – №10.4. – С. 19-21.

Бариева Р.Г.
Теләче районы, Орымширмә башлангыч мәктәбе укытучысы

## ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫКНЫ ФОРМАЛАШТЫРУДА ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ӘЛИФБАСЫНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

**Аннотация.** На этом докладе хочу рассказать о методах формирования функциональной грамотности в начальной школе, об особенностях современного букваря. Читательская грамотность является базовым навыком функциональной грамотности. Современный букварь – неотъемлемый компонент обучения элементарному чтению, который основывается на принципах разнообразия упражнений, визуальной привлекательности и активного вовлечения ученика, обеспечивая преимущества в усвоении материала и формировании навыков чтения.

Без яңача фикерләүгә игътибар бирелгән, әледән-әле яңа ачышлар ясала торган заманда яшибез. Мәгариф өлкәсендә моңа кадәр билгеле булмаган ысуллар һәм эш алымнары кулланыла, алар тагын да камилләшә бара.

Укучыларның белем сыйфатын күтәрүдә заманыбыз мөгаллимнәр алдында яңа бурычлар куя. Гомуми белем бирү системасында функциональ грамоталылыкны формалаштыру өстенлекле максатларның берсе булып тора.

Шул исәптән, функциональ грамоталылыкны формалаштыруның төп ысулы буларак, белем бирүдә инновацион карашларны үзләштерүгә игътибар бирелә. *Функциональ грамоталылык* терминына килгәндә, совет һәм Россия лингвисты, психолог А.А. Леонтьев түбәндәге билгеләмәне бирә: «Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул».

Ә нинди була соң ул функциональ грамоталы шәхес? Функциональ грамоталы шәхес — гомере буе алган белем, күнекмәне тормышта төрле өлкәләрдә килеп чыккан проблемаларны, мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген киң кулланып, социаль мөнәсәсбәтләр урнаштыра һәм аралаша алучы.

Функциональ грамоталы шәхес тышкы дөнья белән аралашырга әзер, ул үзенең ныклы белеменә таянып, мәктәптән тыш мөнәсәбәтләр кора, иркен итеп шул даирәдә үз эшчәнлеген алып бара, тормышта килеп чыккан ситуациядән чыгып эш итә белергә өйрәнә. Гади итеп әйтсәк, укучыны әйләнә-тирә үзе тәрбияли, үзе каршылыгын куя, төрле юллар тәкъдим итә, укыучы булган белемнәрен кулланып, кирәкле юлга чыга. Ә укучыга белем кирәклекне төшендерү иң авыры. Шуңа күрә укытучы иң элек теоретик белемнәрне үзләштерә, аннан аны гамәлдә уңышлы куллану ысулларын өйрәнә, сынап карый. Теоретик белем уңышның нигезе булып тора.

Белгәнебезчә, функциональ грамоталылык күпкырлы төшенчә. Ул уку грамоталылыгын, математик грамоталылыкны, табигый-фәнни грамоталылыкны, финанс грамоталылыгын, глобаль компетенцияләр, креатив фикерләүне үз эченә ала.

Шуларның берсенә – уку грамоталылыгына тирәнрәк тукталып китәм. Бүгенге цифрлаштыру гасырында укучыларда уку грамоталылыгын үстерү аеруча әһәмияткә ия дип уйлыйм. Белем бирүнең нинди генә предмет өлкәсен алсак та, беренче чиратта, аңлап уку, укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аера белү сәләте кирәк. Боларны исәпкә алып, без – башлангыч сыйныф укытучылары алдында да яңа бурычлар килеп туа. Иң беренче чиратта, укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру әһәмиятле. Уку грамоталылыгы — язма текстларны аңлау һәм аларның эчтәлеген үз максатларына ирешү, белем һәм мөмкинлекләр үстерү, җәмгыять тормышында актив катнашу сәләте. Уку грамоталылыгы -функциональ грамоталылыкның төп компоненты.

Хәзерге заман мәктәбе укучыга белем бирү генә түгел, ә укучының мөһим 4 сәләтен дә ачарга тиеш:

- Яңа белем бирү;
- Алган белемнәрне практикада куллану;
- Үзеңнең белү-белмәвеңне ачыклау;
- Тагын да югарырак үрләргә омтылу.

Функциональ грамоталылыкны үстерүдә түбәндәге метод һәм алымнар ярдәм итә:
-группада эш;
-Уеннар;
-иҗади эшләр
-практик эшләр
-рольле һәм эшлекле уеннар;
- тикшеренү эшчәнлеге.

Әлифба кеше тормышында әһәмиятле урын алып тора. Әлифба ярдәмендә бала хәреф танып , укырга, язарга өйрәнә.Ул бала үзлегеннән укый торган иң беренче уку китабы. Әлифба шулай ук балаларны уку, язу кагыйдәләре белән таныштыра, авазларны белеп, сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтә, укучыларның сүз запасларын баета, иҗади һәм танып-белү сәләтләрен үстерә.

Хәзерге заман әлифбасы һәр бала аңлый ала торган гади, аңлаешлы телдә язылган. Дәреслектә бирелгән рәсемнәр, иллюстрациялщр укучыларга материалны җиңелрәк аңларга ярдәм итә. Әлифбада катлаулы булган бирем һәм күнегүләрне әкренләп арттыра бара. Анда җиңелрәк аваз һәм хәрефләр башта бирелеп җиңелдән катлаулыга күчә. Мондый күчү авыр материал белән балага авырлык китермичә, балада уку һәм язу күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә.

Хәзерге заман әлифбасы белем бирү стандартлары һәм таләпләренә җавап бирерлек итеп төзелгән. Анда актуаль материаллар һәм биремнәр урын алган, бу балада уку һәм язу күнекмәләрен үстерергә, әйләнә-тирә дөньяны танырга ярдәм итә. Хәзерге заман әлифбасында балалар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч булган биремнәр, башваткычлар, табышмаклар урын алган.

“Монда нинди сүз яшерелгән?” биреме. Укучылар “Сания”, Алмаз” һәм башка сүзләрдән яңа сүзләр ясыйлар.Бу балада уйлау, фикерли белү эшчәнлеген тагын да арттыра.

“Сорау -җавап”. Текстны укыганнан соң балага сораулар биреп, тулы, төгәл җавап бирергә өйрәтү.

“Баш миенә штурм”. Фикерләүне формалаштырырга , проблеманы чишәргә, балаларны тагын да активлаштырырга ярдәм итә.

“Почмаклар” уены геройларга характеристика биргәндә кулланыла. Сыйныфтагы укучылар икегә бүленәләр. 1 төркем геройның яхшы сыйфатларын, 2 нче төркем начар сыйфатларны атый.

“Иҗади эшләр” . Рәсем буенча җөмләләр, хикәяләр төзетү. Шулай ук бирелгән хикәяне үзең уйлап дәвам итү. Бу эшчәнлек төре укучыларның сәләтләренә карап үткәрелә.

“Сүзләр ясa”. Хәрефләрдән сүзләр , җөмләләр төзү. Әлеге уен төре дөрес язарга ярдәм итә.

“Логик чылбыр”. Текст укыганнан соң вакыйгаларны эзлекле тәртиптә урнаштыру. Әлеге уен төре зуррак текстларны эзлекле рәвештә сөйләргә өйрәнергә ярдәм итә.

Укучыларның сүз байлыгын,фикерләү сәләтен үстерү, әсәрне аңлап укуын тикшерү максатыннан “Уйлап тап!” уены бик үзенчәлекле.Иң элек тактага бирелгән хәрефләр җыелмасы языла. Мәсәлән: **Ура (**ул дәрестә узылачак тема белән дә бәйле була ала)

Укучыларга сораулар тәкдим ителә,алар шул сораулар аша тиешле сүзне уйлап табарга тиешләр.

Гомумән алганда, укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру максатында кулланыла торган алымнар бихисап. Шулай итеп, текст яки мәгълумат белән эшләү, уку процессы структурасында мөһим урын тора тора. Дәрестә генә түгел, дәрестән тыш чараларда да текст белән эшләүнең мөмкинлекләре күп. Алардан уңышлы файдалану – һәр заман укытучысының изге бурычы.

Креатив фикер йөртергә,уйларга өйрәнгән бала күбрәк иҗатка тартыла,андый баланың башына күбрәк матур фикер килә башлый.Әгәр балага бер генә китапның, бер генә әсәрнең матурлыгын,фикер тирәнлеген күрсәтә алсаң, аны мәңгегә китап укуны яратырлык, китап дөньясында йөзәрлек итеп тәрбияләргә мөмкин.Китап укыган баланың язу һәм сөйләм теле дә камил,эзлекле,тирән була.

Без, укытучылар, барыбыз да иҗат итәбез. Баланың ак кәгазьдәй саф күңеленә ак нур белән эзләр салабыз. Шул эзләрнең якты, мәгънәле булуы өчен гомеребез буена тырышырга, эзләнергә тиешбез. .

Варина Т.Р.
МБОУ «Татарско -Ямалинская основная общеобразовательная школа»
Актанышского муниципального района РТ,
учитель начальных классов

## ӘЛИФБА. ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫК

**Аннотация.** Алифба... Самая священная книга, которую многие из нас, переступив порог школы, одними из первых взяли в руки.
Одной из важнейших задач современной школы является создание в системе образования условий, способствующих развитию ребенка, раскрытию его творческого потенциала.
Сегодня функциональная грамотность является важным индикатором общественного благосостояния, а функциональная грамотность учащихся – важным показателем качества образования.
Одно из направлений функциональной грамотности – читательская грамотность.

**Ключевые слова:** Алифба. Функциональная грамотность. Читательская грамотность.

Әлифба... Күпләребезнең, мәктәп бусагасын атлап кергәч, иң беренчеләрдән булып кулларына алган иң изге китабы. Еллар дәвамында әле күпләребез бу дәреслекне хаман да саклый торгандыр әле. Андыйлар рәтендә мин үзем дә бар. Беренче сыйныфны тәмамлаганыма 36 ел булуга карамастан “Әлифба”м эле миндә саклана. Ул ничектер, минем иң кадерле китабым. Ул күпләрне укырга, сөйләргә өйрәткән, әле алай гына түгел, Туган илебезне, телебезне яратырга, үзебездә матур сыйфатлар тәрбияләргә өйрәткән дәреслек. Аның текстлары да бик гади, беркатлы, рәсемнәре дә сабыйлар өчен ясалган кебек тоелса да,аларда тирән мәгънә, чынбарлык ята. Юкка гына бит “Әлифба”ны барлык фәннәрнең башлангычы димәгәннәр.

Һәр халыкның элек тә, хәзер дә үз “Әлифба”сы булган һәм бар. “Әлифба” ул һәр сабыйның дөньяга булган карашын үзгәрткән, үзгәртүче, дөньяны танып белүдәге әһәмиятле чарасы булып тора. Алай гына да түгел, “Әлифба” милли бердәйлеккә ирешү чарасы, ягъни милләтләр арасындагы дуслыкны ныгытуны барлыкка китерүдә зур роль уйнаган дәреслек ул.

Татар халкының 200 еллык тарихы булган “Әлифба” китабы бар. Әйе, тышлыгы, форматы, авторлары үзгә булса да, бүгенгесе көнне дә “Әлифба” үзен югалтмаган зур басма дәреслек. Бүгенгесе көнне дә, безнең сабыйларыбыз, укырга кергәндә шушы дәреслек белән “белем иле” нә аяк басалар. Кулларына алган шушы дәреслек аларны, әле укый да белмәгән сабыйларны, хәрефләр, сүзләр, җөмләләр, рәсемнәр,шигырьләр, текстлар, хикәяләр дөньясына алып керә.

Татарларда мәктәпләрдә белем бирү системасының шактый зур тарихы бар. Ул гасырлар буе формалашкан. Ә инде үз туган телебездә белем бирү үсеп килүче буынга әхлакый тәрбия бирүнең төп нигезе дип саналган, һәм санала да. Татар “Әлифба” сының да озын һәм катлаулы тарихы бар. Бугенге “Әлифба” барлыкка килгәнчегә кадәр ул бик катлаулы, кытыршы юллар уза. Әмма дә ләкин, безнең кулыбызда бүгенгесе көнне дә “Әлифба”. Ул нинди генә юллар кичермәсен, безнең балаларыбыз белем иленә беренче баскычын “Әлифба”дан башлыйлар.

Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова төзегән “Әлифба” инде бик күп еллар дәвамында гел нәшер ителеп килә. Өч буын татарстанлы алар төзегән “Әлифба” дәреслегеннән башлангыч белем алдылар.”Әлифба” ның тышлыгы гына да өч тапкыр үзгәртелә. Әмма тормыш алга бара, дөньябыз зур үзгәрешләр кичерә. “Әлифба” быз да үз чиратында бер урында гына таптанып торган басма түгел хәзер. Кайсы гына басманы алмыйк ул үзгәреш кичерә, заманга иярә, заманча дәреслек булып басыла башлый. Дәреслекләрнең авторы гына түгел, аның эчтәлекләре дә, эчтәлектәге рәсемнәр, текстлар, хикәяләр башкача хәзер.

Яңа “Әлифба”да “укучы берничә дәрестән соң ук мөмкин кадәр күбрәк текстларны укый алсын” дигән принциптан чыгып эшләнелә. Күп бала, мәктәпкә укырга кергәнче, инде укый - яза белә. Бу максаттан чыгып яңа “Әлифба”да хәрефләр башка билгеле бер эзлеклелектә тәкъдим ителәләр.

Яңа «Әлифба» дәреслегендә [к] һәм [қ], [г] һәм [ғ], [в] һәм [w] авазларының дөрес әйтелешенә игътибар бирелә. Сузыкларның калын/нечкә, тартыкларның

яңгырау/саңгырау икәнлеге өйрәтелә. Бу үзенчәлекләр төсләр һәм шартлы тамгалар белән аерып күрсәтелә. Һәр дәрес тыңлап аңлау күнекмәсен булдырудан башлана. Укытучы үзе тәкъдим ителгән текстны укый яисә электрон дәреслектәге аудиоязмадан тыңлата. Текст белән бәйле этәргеч сораулар бирү укучыларны игътибар белән тыңларга, тыңлаган материалны истә калдырырга өйрәтә. Шул текстка таянып, укучылар теге яки бу авазның дөрес әйтелешенә ирешергә тиеш. Аннан шул авазның язудагы тамгасына – хәрефкә игътибар иттерелә. Алга таба хәрефләрдән иҗекләр, сүзләр төзү, җөмләләр һәм текстлар уку кебек эш төрләре тәкъдим ителә. Һәр дәрестә көчле укучылар өчен тоташ текстлар да урын алган. Күргәнебезчә,
уку – укыту системасы да елдан – ел яңа үзгәрешләр кичереп тора.

”Минем укучыларым яңаны миннән белмәячәк. Алар бу яңаны үзләре ачачаклар. Минем бурычым - аларга үз идеяларын ачарга һәм үстерергә ярдәм итү”.( И.Г.Песталоци). Әйе, бу сүзләрдә хаклык бар. Бүгенге заман укытучысының бурычы балаларга юнәлеш бирү һәм аларның үз идеяларын ачарга һәм үстерергә ярдәм итү.

Хәзерге мәктәпнең мөһим бурычларының берсе - укыту системасында баланың үсешенә, аның иҗади потенциалын ачуга ярдәм итә торган шартлар булдыру. Без укучыларга әзер белем бирү белән шөгыльләнмичә, белемне укучыларның үзләреннән таптырту алымнарын күздә тотып эшләргә, алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтергә тиеш. Шул очракта гына безнең укучылар яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган һәм җәмгыятькә файдалы шәхесләр булып үсәчәкләр.*“Кешегә бетмәс –төкәмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, ирекkә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк “,*- дип язган моннан күп еллар элек Л.Н.Толстой. Бүгенгесе көндә дә бу фикерләр белән килешми мөмкин түгел. Яңача укыту технологиясенең нигезендә укучы һәм укытучы арасында яңача мөнәсәбәт тора. Дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә, шатлык – бәхет алып килергә, дәрестән бала ниндидер ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш. Ә иң мөһиме – укучылар дәреснең һәр этабында логик яки иҗади фикер йөртсен өчен шартлар тудырырга кирәк.

Бу бурычларны башлангыч сыйныф укытучысы нинди юллар белән тормышка ашыра ала соң? Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерүгә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын кулланып эшләү, укучыларга алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтү.

Заманча мәктәпнең иң мөһим бурычларыннан берсе - функциональ белемле шәхес формалаштыру. Стандарт таләпләре шундый: традицион «грамоталылык» төшенчәсе белән беррәттән «функциональ грамоталылык» төшенчәсе барлыкка килә. Бүгенге көндә гомуми белем алган укучылар аралашу һәм социаль мөнәсәбәтләрнең киң диапазонын хәл итү өчен кирәкле белем күнекмәләргә ия

булырга тиеш. Бу максатка ирешү өчен без балаларда функциональ грамоталылык формалаштырырга тиешбез.

Нәрсә ул "Функциональ грамоталылык"?

*Функциональ грамоталылык* терминына килгәндә, совет һәм Россия лингвисты, психолог А.А. Леонтьев түбәндәге билгеләмәне бирә: *«Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул».*

Кешегә нинди осталык һәм сыйфатлар кирәк соң?

Функциональ грамоталылык - социаль мөнәсәбәтләр системасында шәхеснең нормаль эшләвен тәэмин итүче белем, күнекмәләр һәм күнекмәләрнең билгеле бер дәрәҗәсе, ягъни аның мәгънәсе белем бирү эшчәнлеген тормышка якынайтудан гыйбарәт.Функциональ грамоталылыкның асылы шәхеснең уку эшчәнлеген мөстәкыйль алып бару һәм Кеше эшчәнлегенең, аралашуның һәм социаль мөнәсәбәтләрнең төрле өлкәләрендә тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен алган белемнәрен, күнекмәләрен куллану сәләтеннән гыйбарәт.

Функциональ грамоталылык үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) уку грамоталылыгы;
2) табигый - фәнни грамоталылык;
3) математик грамоталылык;
4) финанс грамоталылыгы;
5) глобаль компетенцияләр,
6) креатив фикерләү грамоталылыгы;

Функциональ яктан белемле шәхес - ул: – дөньяда ориентлашкан һәм иҗтимагый кыйммәтләргә һәм мәнфәгатьләргә туры китереп эшли торган, аерым алганда, үз гамәлләрен башка кешеләрнең гамәлләре белән яраштыра һәм координацияли белүче кеше; – сайлау һәм карарлар кабул итү ситуациясендә мөстәкыйль булырга сәләтле кеше.

Функциональ грамоталылык нигезләре башлангыч мәктәптә салына, анда сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә – язуга, укуга, сөйләшүгә һәм тыңлауга интенсив өйрәтү бара.

Функциональ грамоталылыкның бер юнәлеше - уку грамоталылыгы.

Бу кешенең язма текстларны аңлау һәм куллану, алар турында уйлану һәм уку белән шөгыльләнү, үз максатларына ирешү, белемнәрен һәм мөмкинлекләрен киңәйтү , социаль тормышта катнашу сәләте.

Укытучы уку техникасын һәм текстны турыдан-туры аңлауны түгел, ә текстны аңлауны һәм рефлексияне, укыган материалны тормыш максатларын тормышка ашыру өчен куллана белүне бәяләргә тиеш, чөнки уку социаль тәҗрибәнең колоссаль мәдәни ресурсын тәшкил итә, укучының үз тәҗрибәсен формалаштыруның нәтиҗәле ысулы булып тора. Сухомлинский башлангыч сыйныфларда яхшы куелган уку балаларның фикерләүләрен, күзаллауларын, сөйләмен үстерүче иҗади эшләрен башкару өчен ныклы нигез булдыра, балаларны тиз, рациональ һәм аңлы рәвештә укырга өйрәтә дип саный.

Уку – коммуникатив танып белү эшчәнлегенең иң мөһим төрләренең берсе, аның нигезендә фикерләү эшчәнлеге ята. Уку күнекмәләре бик мөһим, чөнки көндәлек тормышта без еш кына язу үрнәкләре белән хәл итәбез: китаплар, матбугат басмалары укыйбыз, интернет челтәрләрендә төрле мәгълүмат эзлибез. Уку кешенең культурасын үстерә, аны шәхес буларак тәрбияли.

Текст өстендә эш вакытында укучыларда универсаль уку гамәлләре формалаша: танып белү, коммуникатив, регулятив, шәхси. Текст өстендә эшнең 3 этабы бар: 1. укуга кадәр, 2. уку вакыты, 3. укудан соң.

Бүгенге көндә функциональ белемлелек иҗтимагый иминлекнең мөһим индикаторы булып тора, ә укучыларның функциональ грамоталылыгы – белем бирү сыйфатының мөһим күрсәткече.

Беренче сыйныфтан ук уку дәресләре балаларда китапка кызыксыну, укуга мәхәббәт уятсын, аларга яшәү һәм алга таба уку өчен файдалы күнекмәләр сеңдерсен өчен, әлифба чорында да, әлифбадан соңгы чорда да дәресләрдә күнегүләр һәм иҗади характердагы биремнәр кулланырга кирәк. Бу күнегүләр һәм иҗади характердагы биремнәр һәр балада сүзне үзләштерү, сүзне аңлау, аны төрле яклардан (фонетик, морфема, сүз төзелеше) карау,
тел закончалыкларын практик аңлау сәләтен үстерә, балага интеллектуаль эзләнүне һәм интеллектуаль хезмәтне яратырга мөмкинлек бирә. Иҗади характердагы биремнәр системасы укуга кызыксынуны арттыруга, мөстәкыйль эш күнекмәләрен формалаштыруга, сүзлек запасын баетуга, иҗади фикерләүне һәм күзаллауны үстерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

Шулай итеп, беренче сыйныф укучыларының функциональ грамоталылыгын формалаштыру процессында, минемчә, иң мөһиме - балаларны кечкенә булса да, үз ачышларын ясарга өйрәтү, үз-үзләрен табу һәм ачышлар аша белемнән белемгә кадәр бару. Чөнки функциональ грамоталылыкны формалаштыру өчен әзер нәтиҗә генә түгел, ә аның гипотезалары, хаталары, төрле идеяләрне чагыштырулары, бәяләмәләре һәм ачышлары белән чишү процессы үзе файдалы. Яңа "Әлифба" да бирелгән хәрефләрдән иҗекләр, сүзләр төзү, җөмләләр һәм текстлар уку кебек эш төрләренең күп булуы, һәм дәреслектә көчле укучылар өчен тоташ текстларның да урын алуы, бүгенгесе көнне заман укучысына беренче чиратта функциональ грамоталылыкны үстерүгә ярдәм итәләр, фикерләүне, игътибарны, хәтерне, уку нәтиҗәсе белән кызыксынуны активлаштыралар, сүзлек запасын баеталар, балаларның танып белү активлыгын үстерәләр, орфографик уткенлекне үстерүгә юнәлдереләләр, укуда мөстәкыйльлекне һәм инициативаны үстерәләр, укуга һәм туган телгә аңлы кызыксыну формалаштыралар.

Галлямова Г.М.
учитель начальных классов, МБОУ “Бугадинская ООШ”
Актанышского муниципального района Республики Татарстан

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ УКУ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ӨЧЕН БИРЕМНӘР

**Аннотация**. Читательская грамотность сегодня рассматривается как один из самых важных параметров готовности к жизни в современном обществе. Особое место среди метапредметных универсальных учебных действий занимает чтение и работа с информацией. Успешное обучение в общеобразовательной школе невозможно без сформированности у обучающихся читательской грамотности. Задача развития читательской грамотности является новой областью для современной школы, решающей задачи реализации требований федерального государственного стандарта.

**Ключевые слова:** читательская грамотность, задача, школа, задания.

Abstract in English. Reading literacy is considered today as one of the most important parameters of readiness for life in modern society. A special place among metasubject universal educational activities is occupied by reading and working with information. Successful education in a comprehensive school is impossible without the formation of students' reading literacy. The task of developing reading literacy is a new area for a modern school that solves the tasks of implementing the requirements of the federal state standard.
Key words: reader's literacy, task, school, tasks.

Уку грамоталылыгын формалаштыру- хәзерге заман мәгарифенең актуаль проблемаларының берсе. Безнең гасырда телевидение, компьютерлар, видеоуеннар өстенлек итә, балалар укуга кызыксынуларын югалталар. Балаларны дөрес, аңлаешлы укырга өйрәтү, ә иң мөһиме китап укуга мәхәббәт уяту – башлангыч белем бирүнең төп бурычларының берсе.

Башлангыч мәктәптә эшләүче укытучылар түбәндәге проблемалар белән очрашалар:

- балаларның уку тизлеге түбән;
- еш кына сүзләрне дөрес укымаганлыктан, укыганның мәгънәсен аңламыйлар;
-китап укымаганлыктан укучыларның сөйләме ярлы һәм примитив;
- кыскача эчәлекне авырлык белән сөйлиләр;
- тәкъдим ителгән тексттан кирәкле мәгълүматны ала алмыйлар.

Җитди каршылык барлыкка килә: бер яктан, хәзерге дөнья безгә бик күп мәгълүмат яудыра, икенче яктан, безнең балалар аз укый һәм уку грамоталылыгына ия түгел. Ә ничек баланы укырга, кирәкле мәгълүматны табарга, текст белән эшләргә өйрәтергә? Ничек укуга уңай караш булдырырга?

Хәзерге заман мәктәбенең төп бурычларының берсе- функциональ грамоталы шәхес тәрбияләү. Функциональ грамоталылык- мәктәптә алган белемнәрне дөрес итеп куллана белү. Аның берничә компоненты бар. Уку грамоталылыгы- функциональ грамоталылыкның төп компоненты. Уку грамоталылыгын формалаштыруда текст белән эшли белүгә игътибар итәргә кирәк, чөнки текст уку ул – белем бирү генә түгел, тәрбияви бурычлар үтәүне дә үз эченә ала. Шәхеснең рухи-әхлакый сыйфатларын формалаштыруда текст белән эшләүнең роле зур. Дәрестә текст белән эшләүне укучыларга кызыклы да, аңлаешлы да булырлык итеп оештырырга кирәк.

Укучыларда уку грамоталылыгын формалаштыру, балада белем алуга кызыксыну уяту, фикерләү сәләтен үстерү өчен дәрестә төрле грамматик уеннар, мавыктыргыч күнегүләр, башваткычлар, иҗади биремнәр кулланырга мөмкин. Без, башлангыч сыйныф укытучылары, үзебезнең эшчәнлегебездә С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова хезмәтләренә таянып эшлибез. Шундый хезмәтләрнең берсе- “Кызыклы грамматика китабы”. Әлеге китапта грамматик уеннар, мавыктыргыч күнегүләр, табышмак, башваткыч, әкият һәм мәзәкләрне, дәресләрдә, дәрестән тыш эшчәнлектә бик теләп файдаланабыз. Бередәге биремнәр дәресләрне җанлы , кызыклы итә, балаларның дөрес сөйләм һәм язу күнекмәләрен җиңел үзләштерергә булыша, туган телебезгә кызыксыну уята. Башлангыч сыйныф укучылары өчен уку грамоталылыгын үстерүгә юнәлтелгән биремнәр туплаганда мин әлеге хезмәткә таяндым.

1 нче сыйныф укучылары белән түбәндәге эш төрләрен файдаланырга мөмкин

1. А хәрефенә башланган 6 сүзне табып укыгыз.

Алмалкабагарбарпагач

2. К хәрефенә башланган 7 сүзне табып укыгыз.

Кадакабакалакакараказыкүк

3. Тизәйткечләрне тыныч, кычкырып, пышылдап, тавышсыз (эчтән) уку.

А)Абагага бага-бага,
башым бәрдем баганага.

Б)Чыпчык, чыпчык, чык, чыпчык,
Чык-чык, кошчык, очып чык!

4. Хәрефләрдән сүзләр төзибез.

| | |
|---|---|
| агмачла | мукас |
| абйаб | набага |
| кәтпәм | анач |
| актип | үлбмә |

5. Ә хәрефен өстәп сүзләрне укы:

снк мктп ччк
тб кҗ бр
ткй нкй тч
җй чй бй зй

6. А хәрефен өстәп сүзләрне укы:

кбк тдк крк клк нрт

лм рб рк лк

тб кр рм бл дг

7.“Адашкан хәрефләр” . Хәрефләрнең урыннарын алыштырып яңа сүзләр яса**.** Табынга нәрсәләр куелган ?

Уйлап яз.

Вынка_______________

Ләчиквек_____________

Ләнпип______________

Камйок______________

8. “Менә сезгә сүзләр”

-Менә сезгә сүзләр: ага, яга, ачык, кара, кура, атна. Аларның уртасына ба яки ла иҗекләрен куеп, яңа сүзләр китереп чыгарырга кирәк.- Хәзер эшлибез аны,- диде Муса.

- Менә шундый яңа сүзләр килеп чыга... ___________________________

- Нинди сүзләр килеп чыккан?

9.Һәрбер юлдан 6 сүзне табып укы:

кәниәтирсәбирбабайңюапаҗабый

мәктәпдоручкайюядәфтәръёакбуриитактачщсумка

агачалмачәчәккабакүлән

10.Текстны игътибар белән укы һәм сорауларга җавап бир:

**Куян.**

Көз көне куян соры йонын коя. Ул ак тун кия. Аның туны бик җылы. Тун куянны салкыннан һәм аучыдан саклый. Кар да, куян да ак. Куян агач ботакларын, ачы кайрыларны кимерә. Ул җылы җәйне ярата. Җәй көне рәхәт, азык күп була.

Бу текст нәрсә турында?

Куян кайчан соры йонын коя?

Ак тун куянны нәрсәләрдән саклый?

Куян нәрсәләр белән туклана?

Ни өчен куянга җәй көне рәхәт?

Икенче сыйныф укучылар өчен биремнәрне яшь үзенчәлекләренә һәм теманы үзләштерү дәрәҗәсенә карап бераз катлауландырырга мөмкин.

2 нче сыйныф укучылары өчен түбәндәге биремнәрне файдаланырга мөмкин.

1. Җөмләләрне киресенчә уңнан сулга укы:

:наглубечәтәекиңенибәреб

Аракесечнекиәкаесреб

2. Мәкальләрне дөрес итеп укы:

Агач эше белән, кеше җимеше белән матур.

Кем ашамый, шул эшләми.

Җиде тапкыр кис, бер тапкыр үлчә.

Аз эшлә дә күп сөйлә.

Беләге юан меңне егар, белеме булган берне егар.

3. Бер хәреф мәкальнең эчтәлеген үзгәрткән, хатаны табып дөрес итеп укы:

Батыр якасыз булмас.

Эше барның аты бар.

Теш ташны эретә.

4. Җөмләләрне капма каршы мәгънәле сүзләр белән тәмамла һәм мәгънәсен аңлат.

Яхшылыкны истә тот, ә .........оныт.

Тырышлык зурлык, ........хурлык.

Аз сөйлә,..... эшлә.

Яхшы сүз көн кебек, ... сүз ....кебек.

Батыр бер үләр,.... мең үләр.

Эшләгән үлмәс,.... көн күрмәс.

Тырышлык – зур бәхет, .......хурлык.

5. “Мин башлыйм, син тәмамла”. Мәкальләрнең икенче өлешен әйтеп бетер.

1)Эш үткәч,(. .......).

2) Азрак сөйләсәң, (......... ).

3) Кешенең үзенә карама, (....... ).

4) Телең белән узма, (. ......).

5) Кыңгыр эш (....... ).

6) Бер яхшы эш (....... ).

7) Яхшы гадәт адәм итәр, (....... ).

8) Ачуның даруы- (........)

9) Эше барның- (....... ).

10) Белмәү гаеп түгел, (. ........).

6. Төшеп калган сыйфатларны куеп шигырьне укы.

Песи, песи, пескәем,<br>
....... синең төскәең.<br>
...... синең йоннарың,<br>
..... синең туннарың.<br>
«Мияу, мияу!» бар сүзең,<br>
..... да әле үзең.<br>
Белмим инде, ни өчен<br>
Бернигә китми исең? (Р.Миңнуллин)

7. Төшеп калган сүзләрне куеп, шигырьне укы. Рифмага иътибар ит.

Агач ботагы ашый<br>
Олы мөгезле .... .<br>
Кыш көне кар өстендә<br>
Ял итү аңа ..... .

8. Текстны дөрес итеп укы.
МенәкыштаүтепкиттеСалкынкөннәр,ачыбураннаркүптәнбеттеиндеКояшешракк арыйКөннәрҗылытаЯңгырларявабашладыКүмәкхуҗалыкэшчәннәреязгыэшләр небашлапҗибәрделәрАлармулуңышалуөченкөрәшә.

9. Текстны укы.

Без бөтен гаиләбез белән паркта йөри идек. Кинәт кенә юл өстенә җирән төстәге җәнлек сикереп чыкты.

Бу кулга өйрәтелгән тиен иде.Без аңа чикләвек һәм печенье бирдек. Ул печеньены тиз генә эләктереп алды да имән куышына алып менеп китте. Аннары чикләвекне алды һәм нарат төбенә күмеп куйды.

Менә шулай итеп тиен үзенә кышка запас әзерли.

-Бу җирән җәнлек нинди җәнлек ? ____________________________________

-Тектска исем куй___________________________________________________

-Бу хикәяләү текстымы , әллә тасвирлау текстымы? Исбатла.

-Төп өлешне күчереп яз.

Дәрестә уку грамоталылыгн үстерү өчен төрле алымнар, биремнәр кулланганда, түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин:

- укучылар бер-берсен тыңларга өйрәнәләр;
- укучыларның интеллектуаль потенциалы арта, аларның сүзлек запасы киңәя;
- бергәләп мәгълүмат белән тулы текстны яхшырак аңларга ярдәм итә;
- кызыксынучанлык, күзәтүчәнлек көчәя;
- актив тыңлауны үстерә;
- үз-үзеңне бәяләү арта.

Болар барысы да укучыларның белем дәрәҗәсен күтәрүгә һәм башлангыч сыйныф укучыларының уку грамоталылыгын формалаштыруга ярдәм итә.

Кулланылган әдәбият исемлеге


1. С.Г.Вагыйзов. Кызыклы грамматика: Укытучылар өчен кулланма.- Тулыл. 3 нче басма.- Казан: Мәгариф, 2002.-207б.
2. М.Ф.Буряк, С.А.Шайкина. Функциональная грамотность . Тренажер для школьников. – Издательство “Планета”, 2021.
3. Русский язык и читательская грамотность.– Ташкент: Республиканский центр образования, 2021. – С 120



Гарафиева Г.М.,<br>
МБОУ «Куркачинская СОШ»<br>
Высокогорского муниципального района РТ<br>
учитель начальных классов


## БУКВАРЬ - ОСНОВНОЙ ИНСТРУМЕНТ ФОРМИРОВАНИЯ ФУНКЦИОНАЛЬНОЙ ГРАМОТНОСТИ.


**Аннотация:** В статье освещается значимость формирования функциональной грамотности учащихся первого класса. Подчеркивается важность одного из его компонентов - читательской грамотности. Характеризуются группы, используемые в процессе обучения грамоте. Приводятся примеры упражнений, представленных в букварях.

**Ключевые слова:** функциональная грамотность, букварь, зрительное восприятие, слуховое восприятие, понимание прочитанного.

В современном образовательном процессе особое внимание уделяется развитию функциональной грамотности. Одним из важных инструментов для первоклассников в этом процессе является современный букварь. В данной статье мы рассмотрим суть и роль современного букваря в развитии функциональной грамотности, а также основные группы упражнений ля развития читательской грамотности.

Букварь имеет чрезвычайно важное значение в жизни человека. Часто он является первой книгой, которую маленький ребенок начинает самостоятельно изучать. Ребенок с помощью букваря учится читать и писать, тем самым, поднимаясь в своем знании родного языка на новую, более высокую ступень. Именно занятия с букварем позволяют ребенку ясно и окончательно осознать свою принадлежность к родному языку и родной культуре. Букварь развивает логическое мышление ребенка, что существенно повышает уровень его интеллекта и является значительным шагом в формировании его индивидуальности, способствует развитию эстетических взглядов ребенка, помогает ему правильно воспринимать окружающий мир во всей его многообразной красоте. В этом букварь находить отклик с функциональной грамотностью, который включает в себя овладение определенным уровнем знаний, умений и навыков, обеспечивающих нормальное функционирование личности в системе социальных отношений**,** то есть ее смысл состоит в приближении образовательной деятельности к жизни.

Одним из компонентов функциональной грамотности является читательская грамотность. Это способность человека понимать и использовать письменные тексты, размышлять о них и заниматься чтением для того, чтобы достигать своих целей, расширять свои знания и возможности, участвовать в социальной жизни.

Чтобы уроки чтения с первого класса развивали у детей интерес к книге, любовь к чтению, прививали им полезные для жизни и дальнейшей учебы умения и навыки , можно упражнения, используемые на уроках, разделить на три вида. В статье хочу отметить творческие упражнения, включенные в «Азбуку» по серии «школа России» под авторством В.Г. Горецкого, В.А. Кирюшкина, Л.А. Виноградской, М.В. Бойкиной. Эти задания помогают практически осмысливать закономерности языка, дают ребёнку возможность полюбить интеллектуальный поиск и интеллектуальный труд. В первую очередь они способствуют развитию функциональной грамотности, активизируют мышление, внимание, память, интерес к результату обучения, обогащают словарный запас, развивают познавательную активность детей, направлены на развитие орфографической зоркости, развивают самостоятельность и инициативу в обучении, формируют сознательный интерес к чтению и русскому языку.

Хочется выделить первую группу упражнений, связанных со зрительным восприятием, направленных на выработку правильности чтения, на воспитание внимания к зрительному образу слова, на совершенствование способа и темпа чтения.

Для воспитания у учащихся зоркости к буквенной стороне используются следующие материалы:

- при изучении «ы», в стихотворениях Е. Благининой и С. Маршака выделена данная буква и привлекает внимание учащихся (1.стр.32)
- при изучении буквы «Кк»,после приобретения детьми навыка быстрого «схватывания» одного-двух слогов, выделяются слова ко-ни, ки-но, обращается внимание на гласные (1стр.49)
- при изучении буквы «Сс», проводится сравнение слов «сук-сын-сон», делается упор не только на зрительный образ слов, но лексическое значение (1 стр.51)
- при изучении буквы «Лл», привлекает внимание игра – превращение слов, основанное на порядок букв в слове (1.стр.61)
- При изучении буквы «Тт», наблюдение ведется над омонимами (1.стр.55)

Вторая группа упражнений направлена на совершенствование произношения и восприятия звуков на слух. Здесь проводится работа над дикцией и постановкой дыхания. Упражнения над дикцией включают в себя тренировку артикуляционного аппарата, отработку гласных и согласных звуков, упражнения на сочетание тренируемого звука с гласным; чтение чистоговорок, скороговорок; упражнения на узнавание звука по артикуляции (угадай, какой звук я произношу). При знакомстве со звуками, используется соотнесение звуков речи со звуками окружающего мира. У - гудит паровоз, А - плачет Аленка, Р - рычит собака и т. д. Для формирования звукобуквенной связи, для усвоения зрительного образа букв используются занимательные стихотворные тексты, которые помогают соотнести звук или букву с предметами окружающего мира.

Третья группа направлена на понимание прочитанного. В статье хочется направить внимание на отбор и построение содержания материала букваря. В букваре заложен значительный воспитательный потенциал, направленный на формирование основ российской гражданской идентичности младшего школьника, усвоение базовых национальных ценностей, получение детьми родиноведческих и краеведческих знаний, а также поликультурность, отражающая единство и многообразие культур народов России:

- патриотизм – любовь к России, к своему народу, к своей малой родине, служение Отечеству: изучение тем «Край родной, навек любимый» (1. с. 14-15)
- социальная солидарность – доверие к людям, институтам государства и гражданского общества, справедливость, милосердие, честь, достоинство: «Не делай другим того, чего себе не пожелаешь» (1.с. 118).

- гражданственность – служение Отечеству, правовое государство, гражданское общество, закон и правопорядок, поликультурный мир: изучение тем «Жить – Родине служить» (1. ч. II, с. 34),
- семья – любовь и верность, здоровье, достаток, уважение к родителям, забота о старших и младших: изучение темы «Не нужен и клад, когда в семье лад» (ч. I, с. 10)
- труд и творчество – уважение к труду, творчество и созидание, целеустремленность и настойчивость: изучение тем «Кто любит трудиться, тому без дела не сидится» (1. с. 6-7
- природа – родная земля, заповедная природа, планета Земля, экологическое сознание: изучение тем «О братьях наших меньших» (ч. I, с. 90-95).

исследования отражают современное представление об умении "грамотно читать". Согласно этому представлению, выпускник школы должен понимать тексты, размышлять над их содержанием, оценивать их смысл и значение и излагать свои мысли о прочитанном. Основное внимание уделяется проверке умения"грамотно читать вразличных ситуациях. Обучающимся предлагаются тексты разных жанров: отрывки из художественных произведений, биографии, тексты различного характера, личные письма, документы статьи из газет и журналов инструкции, рекламные объявления, географические карты и др. В них используются разные формы представления информации: диаграммы, рисунки, карты, таблицы и графики.

Оценка грамотности чтения должна учитывать следующие его пять аспектов, овладение которыми свидетельствует о полном понимании текста: общая ориентация в содержании текста и понимание его целостного смысла; выявление информации; интерпретация текста; рефлексия на содержание текста; рефлексия на форму текста.

Полное понимание текста предполагает определенный уровень компетентности обучающегося по каждому из аспектов. Уровень этот выявляется с помощью вопросов и указаний к выполнению заданий. Также предусмотрены грамматические задания, которые можно видоизменять, в зависимости от темы урока.

В «Оценке по модели PISA», как и в оригинальном исследовании PISA, выделяют шесть уровней для каждого вида грамотности, где пятый и шестой уровни – самые высокие, их достижение указывает на высокие компетенции; второй уровень – пороговый, его недостижение свидетельствует о недостаточно развитых базовых умениях об учебной неуспешности.

Согласно концепции PISA, грамотное чтение в современном мире требует сложных стратегий обработки информации, умения работать одновременно с несколькими источниками информации и интерпретировать полученную информацию. Другими словами, читательская грамотность подразумевает три умения: находить информацию (как нужную информацию в рамках одного текста, так и умение находить и выбирать релевантный текст); понимать значение написанного и делать выводы; оценивать качество и достоверность информации, разделять форму и содержание, выявлять противоречия.

В исследовании PISA задания читательской грамотности построены таким образом, чтобы выявлять качественный уровень, на котором обучающийся может работатьс информацией.

И сейчас в нашей школе продолжается работа по формированию уровня функциональной грамотности обучающихся с использованием инструментария PISA с введением в уроки, внеурочную деятельность разбора заданий на сайтах: РЭШ, ФИОКО, ФИПИ.

Список использованных источников:

1. Сайт ФГБУ «ФИОКО» https://fioco.ru

2. Результаты общероссийской оценки по модели PISA-2022
3. Сайт ИСРО: http://skiv.instrao.ru/
4. Платформа Российской электронной школы: https://fg.resh.edu.ru/
5. Сайт ФИПИ; https://fipi.ru/otkrytyy-bank-zadaniy-dlya-otsenki-yestestvennonauchnoy-gramotnosti.

А.С. Шигаева,
г. Елабуга, ОШ «Университетская» ЕИ КФУ

# РОЛЬ СОВРЕМЕННЫХ БУКВАРЕЙ В ФОРМИРОВАНИИ ФУНКЦИОНАЛЬНОЙ ГРАМОТНОСТИ

**Аннотация:** Наличие функциональной грамотности, важное качество для современного человека, поэтому мы начинаем говорить о ее развитии с первого класса. Для начала нужно разобраться в понятии функциональная грамотность. Сможем ли мы сказать, что наличие современных учебников в том числе «Азбуки» позволяет нам построить процесс обучения эффективно? Как учебники влияют на развитие функциональной грамотности?

**Ключевые слова:** функциональная грамотность, азбука, ФГОС, ученики.

Abstract: Having functional literacy is an important quality for a modern person, so we begin to talk about its development from the first grade. First you need to understand the concept of functional literacy. Can we say that the availability of modern textbooks, including ABC, allows us to build the learning process effectively? How do textbooks influence the development of functional literacy?

Key words: functional literacy, alphabet, Federal State Educational Standard, students.

С внедрением федерального образовательного стандарта нового поколения, в образовательной системе появляются новые понятия, которые на сегодняшний день уже у всех на слуху. Одно из них это понятие о функциональной грамотности.

Функциональная грамотность — это умение эффективно действовать в нестандартных жизненных ситуациях. Ее можно определить, как «повседневную мудрость», способность решать задачи за пределами парты, грамотно строить свою жизнь и не теряться в ней. Функциональная грамотность сформирована через формат международного исследования PISA.

На сегодняшний день, каждый учитель использует данный термин и простыми словами, это означает ни просто дать ребенку знания, а научить их пользоваться полученными в школе знаниями в обычной жизни. Одной из основных задач современного учителя, является воспитать функционально развитую личность- это личность свободно ориентирующаяся в окружающем мире, действующая в соответствии с ценностями , интересами, ожиданиями общества. Такой человек должен быть инициативным, решительным, способен

принимать нестандартные решения, готов постоянно учиться и развиваться. Именно эти качества должен воспитывать педагог, начиная с 1 класса. Функциональная грамотность состоит из нескольких аспектов: развитие читательской, естественнонаучной, математической, компьютерной, финансовой, юридической грамотности, а так же грамотность в вопросах здоровья, в семейно-бытовых вопросах, творческое мышление. Все перечисленные грани мы развиваем на протяжении всей своей жизни, но как функциональная грамотность связана с периодом начала чтения, а именно с современным учебником азбуки. Базовым качеством в начальной школе является читательская грамотность - это умение человека понимать и использовать письменные тексты, анализировать, изучать их для решения своих жизненных задач. Те сведения, которые читатель получает из текста, должны расширять его знания и возможности в жизни.

Рассмотрим этапы работы с текстом в начальной школе:

1 класс. Учитель обучает детей читать и понимать смысл прочитанного текста.

2 класс. Учитель обучает детей работать с текстом - пересказывать, делить на части, составлять план, выделять опорные слова, определять героев, давать характеристику их личностям и поступкам.

3-4 классы. Учитель обучает детей находить информацию, давать собственную оценку прочитанному, выделять главную и второстепенную мысль в тексте, сопоставлять свои убеждения с жизненными позициями персонажей, прогнозировать содержание, самостоятельно формулировать вопросы, сравнивать тексты разных жанров с похожим содержанием.

Первый класс любого школьника начинается с изучения букв. Затем чтения слогов, и только потом чтения текста и его осмысление. Можем ли мы развивать функциональную грамотность в это время? Ответ очевиден. Для этого нам нужно рассмотреть современные учебники русского языка «Азбука».

В перечне разрешенных учебников в рамках ФГОС на 2023-2024 учебный год, для первых классов имеются следующие учебные пособия:

1. Русский язык. Азбука: 1-й класс: учебник: в 2 частях авторы; Горецкий В.Г., Кирюшкин В.А., Виноградская Л.А., Бойкина М.В, «Издательство «Просвещение».
2. Азбука: 1-й класс: учебник для общеобразовательных организаций, реализующих адаптированные основные общеобразовательные программы : в 2 частях (для слабослышащих обучающихся) авторы: Головчиц Л.А., Красильникова О.А., Андреева Е.Л. и др. «Издательство «Просвещение».

Проанализируем содержательную часть учебных пособий для выявления содержательных заданий, направленных на развитие функциональной грамотности.

Первые части учебников с первых страниц имеют большое количество красочных иллюстраций, которые не покидают до последней страницы учебника. Они содержат вопросы, на которые ученик отвечает. Работая с

иллюстрационным материалом, мы учим ребенка рассуждать, рассказывать, понимать смысл увиденного на страницах учебника. На страницах «Букваря», мы замечаем пословицы и поговорки, которые нужно понять и запомнить, что расширяет кругозор современного первоклассника. Не стоит забывать и о текстах читаемых учителем во время урока, который нужно не просто прослушать, а предлагается ответить на поставленный вопрос, высказать свою точку зрения по смыслу текста, с которым он познакомился. Также он должен выбрать одну из пословиц, раскрывающих смысл рассказа, и доказать, почему подходит именно она. Еще одно интересное задание - палитра чувств. С помощью этого метода ребенок сможет проанализировать, как изменялось состояние героя, в какой последовательности и почему одно чувство сменялось другим. Рассказ ученика на основе одного предложения из ранее изученного произведения, нужно либо продолжить рассказ, либо восстановить события, которые были до. Здесь мы видим как работу с текстом, поскольку ребенку необходимо вспомнить, о чем шла речь в рассказе, так и развитие читательского воображения. Работая со второй частью учебников, ребята уже умеют читать, и добавляется новый вид работы. Работа с новыми (неизвестными ранее) словами Ребенку необходимо прочитать устаревшие словосочетания, определить их значение и закрасить смысловые пары соответствующим цветом. Что позволяет развивать читательскую, естественнонаучную грамотность, а так же творческое мышление уже с первых дней нахождения в школе.

Исходя из выше сказанного, мы видим, что развитие функциональной грамотности начинается уже с первых дней обучения в школе. И не имеет значение, в какой школе обучается ученик, для своей работы мы рассмотрели учебники для общеобразовательной школы, а так же адаптированные варианты. Большую роль в начале формирования функциональной грамотности сыграли учебники «Азбуки-Букваря». Современные учебники построены таким образом, что бы развитие ребенка не прерывалось ни на шаг. С каждым уроком мы развиваем потенциал наших учеников и на выходе из школы получаем функционально развитую личность.

Список использованных источников

1. Федеральный перечень учебников. URL: https://fpu.edu.ru/ ( Дата обращения: 11.10.2023)

2. Русский язык. Азбука: 1-й класс: учебник: в 2 частях авторы; Горецкий В.Г., Кирюшкин В.А., Виноградская Л.А., Бойкина М.В, «Издательство «Просвещение».
3. Азбука: 1-й класс: учебник для общеобразовательных организаций, реализующих адаптированные основные общеобразовательные программы : в 2 частях (для слабослышащих обучающихся) авторы: Головчиц Л.А., Красильникова О.А., Андреева Е.Л. и др. «Издательство «Просвещение».

# СЕКЦИЯ 5. ЦЕННОСТИ ВЕЛИКИХ МЕТОДИСТОВ (ВАГИЗОВА С.Г. И ВАЛИТОВОЙ Р.Г.) В СОВРЕМЕННОЙ НАЦИОНАЛЬНОЙ СИСТЕМЕ ОБРАЗОВАНИЯ

# 5 НЧЕ СЕКЦИЯ ХӘЗЕРГЕ МИЛЛИ МӘГАРИФ СИСТЕМАСЫНДА ТАНЫЛГАН МЕТОДИСТЛАРНЫҢ (ВАГЫЙЗОВА С.Г. ҺӘМ ВАЛИТОВА Р. Г.) РОЛЕ

Ахмадиева Г.Н., Ахметова Г.М.,
Гимадеева Р.Р., Калимуллина А.И.
МБОУ «Иске – Казанская ООШ
Высокогорского муниципального района РТ»,
учителя начальных классов

## ЦЕННОСТИ ВЕЛИКИХ МЕТОДИСТОВ С.Г.ВАГИЗОВА И Р.Г.ВАЛИТОВОЙ В СОВРЕМЕННОЙ НАЦИОНАЛЬНОЙ СИСТЕМЕ ОБРАЗОВАНИЯ

**Аннотация:** Вы помните свой букварь? Если увидите – непременно узнаете его и волна тёплых детских воспоминаний вернёт вас в первый класс. Сейчас у первоклашек буквари другие. Потому что этот вид учебника, оказывается, в зависимости от перемен в общественной и политической жизни страны менялся каждые 20–30 лет. А вот появившийся в 1965 году татарский букварь – алифба – живёт более 50 лет. Его разработали супруги-педагоги Салей Вагизов и Рамзия Валитова. Судьба этой семьи настолько трагична, что поневоле удивляешься, как после всех потрясений, выпавших на её долю, появился такой светлый, понятный и ставший родным для детей разных поколений учебник.

**Ключевые слова:** С.Г.Вагизов, Р.Г.Валитова, “Әлифба”, учебник, родной язык.

Человек с незапамятных времен обучал детей родному языку, уделяя особое внимание совершенствованию языка, пополнению словарного запаса, умелому использованию его при разговоре и письме.

"Әлифба", то есть татарская азбука под авторством Рамзии Валитовой и Салея Вагизова является настоящим учебником-долгожителем.

Салей Вагизов и Рамзия Валитова - первые авторы азбуки для детей для изучения татарского языка. Книга изменялась и дополнялась 42 раза, по ней учились 3 поколения татарстанцев. До сих пор именно по ней продолжают знакомство с татарским языком в мире.

За все это время книга сменила обложку лишь трижды и каждая из них - это отражение истории страны и республики. Авторы были удостоены многочисленных премий, в том числе они стали лауреатами премии Каюма Насыйри.

Это та самая старая-добрая, самая популярная “Әлифба” в советское и постсоветское время, которая была напечатана 1965 году.

Салей Вагизов и его жена Рамзия Валитова работали над учебником пять лет, в его создании использовали все имеющиеся в истории татарского образования наработки и опыт родственных народов. В деревне Татарский Байтуган в 2016 году – спустя 11 лет после смерти ученого – открыли его музей, в Арске, где Салей Вагизов проработал всю жизнь, создан музей «Әлифбы».

Успех первого учебника вдохновил ученых к созданию новых работ: в 1986 году выходит еще одна татарская азбука «Алифба» для детей-шестилеток, а в 1997 году Рамзия Гилязовна и Саляй Гататович создают «Алифбу» на латинском шрифте. Далее выходит методическое пособие для учителей «Преподавание татарского языка в начальных классах», которое получает высокую оценку – было удостоено номинацией «Крупное достижение лингводидактики», этот капитальный труд получил высокую оценку именитых ученых-филологов и педагогов. Творческий дуэт ученых в целом создал более 40 учебных и методических пособий, и все они стали признанными в методической науке страны. Многочисленные статьи на страницах журнала «Магариф», «Совет мәктәбе», лекции для учителей в Институте развития образования позволили Валитовой Р.Г. и Вагизову С.Г. поднять преподавание татарского языка на высокий уровень. Учебники и учебные пособия «Татарский язык» для 1 класса, «Письмо и чтение», «Алифба в картинках», «Интересная грамматика» до сих пор являются главным методическим подспорьем учителей для преподавания татарского языка.

Удивительно, но факт: «синяя» Әлифба стала, по существу, «главным татарским букварем на протяжении последнего полувека, и не было в XX столетии другого такого татарского букваря – долгожителя.» Она продолжает издаваться и сегодня, и многие учителя татарского языка считают её лучшим татарским букварем.

В учебнике использованы методические приемы, которые и сейчас актуальны при преподавании татарского языка.

Классические принципы преподавания такие, как

-доступность;

-последовательность;

-системность;

-дифференцированный подход;

-актуальность.

Иллюстрации учебника дает возможность учителю провести воспитательную беседу, расширяет кругозор, Воспитывает уважение к сельской жизни, учит труду, учит любить Родину, родной язык.

Без прошлого не может быть будущего. Поэтому сохранить имена знаменитых авторов, память о былых событиях и передать их своим потомкам – наш долг.

Список использованных источников

Сальникова А.А. Татарская «Алифба»: история и современность. 2016. - 253 с.

Ибраева Рәсимә, Арча 2 нче урта мәктәбенең
"Яшь журналист" түгәрәге җитәкчесе,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Сәләй Гататдин улы Вагыйзов хөрмәтенә
акрошигырь*

**С** амар өлкәсендә туган егет
**Ә** лифбалы итте дөньяны.
**Л** ектор иде, Сәләй ага,
**Ә** ңгәмәдәш иде кызыклы.
**Й** өрәгендә булган гыйлемне,
**Г** раммтиканы кызыклы итеп,
**А** ңардан да оста җиткерүче
**Т** уган телне, татар телен
**А** на телен йөрәкләргә
**Т** агын бармы күчерүче?
**Д** аны китте еракларга "Әлифба"ның,
**И** лне яклап озак көрәште.
**Н** амус белән яшәп гомер итте,
**У** ку китапларын өләште.
**Л** аек иде бөек исемнәргә,
**Ы** шанычлы ныклы дус иде.
**В** өҗданына тугры калмаганнар
**А** ның өчен бер дә юк иде.
**Г** аделлекне өлге итеп,
**Ы** к – мык итми генә
**Й** өген тартты җиңел итеп.
**З** урлый аны бүген АРЧА,
**О** лылап хөрмәт итә
**В** арислары туган халкымның!

Мукимова Н.А.
г. Стерлитамак, ФГБОУ ВО Уфимский университет науки и технологий,
доцент кафедры татарской и чувашской филологии

# УКЫТУЧЫ ҺӘМ ГАЛИМӘ РӘМЗИЯ ВӘЛИТОВАНЫҢ НӘСЕЛ ТАМЫРЛАРЫ ТУРЫНДА ЯҢА ФАКТЛАР

**Аннотация:** В научно-методической литературе, в энциклопедиях и справочниках имеется очень небольшой объем информации относительно биографии Рамзии Валитовой – соавтора легендарного букваря по татарскому языку. Данная статья посвящена анализу и сопоставлению, дополнению имеющейся информации, а также описанию новых фактов на основе архивных

документов по родословной педагога. Рамзия Валитова – является уроженкой города Стерлитамака, дочерью рода татарских купцов третьей гильдии.
**Ключевые слова:** Рамзия Валитова, биография, Стерлитамак, купцы.

**Abstract:** In the scientific and methodological literature, in encyclopedias and reference books, there is a very small amount of information regarding the biography of Ramzia Valitova, the author of the legendary primer on the Tatar language. This article is devoted to the analysis and comparison, addition of available information, as well as the description of new facts based on archival documents on the pedigree of the teacher. Ramzia Valitova is a native of the city of Sterlitamak, the daughter of a Tatar family of merchants of the third guild.
**Key words:** Ramzia Valitova, biography, Sterlitamak, merchants.

Фәнни-методик әдәбиятта, матбугатта якташыбыз, укытучы һәм галимә Рәмзия Вәлитованың тормыш юлы турында кыска гына фактологик һәм сентименталь мәгълүмат, педагогик эшчәнлегенә карата гомуми күзаллау характерында материалларның барлыгын билгеләргә була. Мәсәлән, “Татар педагогик фикере антологиясе”ндә Рәмзия Вәлитова турында бары 9 юлга гына сыйдырышлы белешмә бирелгән [7: 190]. Бу инде, әлбәттә, әлеге хезмәтнең үзенчәлеге белән дә бәйле.

Якташыбызның тормыш юлына, нәсел-ыруына кагылышлы булган материаллар да сораулар тудырды. Беренчедән, Рәмзия апаның әнисе турында мәгълүматларга тукталыйк. Язучы Айдар Хәлимнең “Минем түгәрәк имәнем” публицистик китабында биографик фактлар эмоционль-экспрессив характерда тасвирлана. Әйтергә кирәк, вакытлы матбугатта һәм интернет сәхифәләрендә әлеге чыганакка таянып тәкъдим ителгән язмалар шактый. Автор Рәхимколовлар нәселенә караган мөгаллимә һәм галимә Мәдинә Фәтхетдин кызы Рәхимкуловадан “Әлифба” авторы Рәмзия Вәлитованың аларга кардәш булулары турында белүен әйтеп үтә. Без, бу нәселнең Миякә районы Олы Кәркәле авылыннан икәнен белгәч, элекке тарих укытучысы Вафин Илфак Газиз улына мөрәҗәгать иттек, һәм ул Мәдинә ханымның русча язылган истәлекләре кулъязмасы белән уртаклашты. Әлеге чыганакларда сорау тударган фактлар булса да, Мәдинә, Рәмзия апаларның һәм Айдар абыйның кардәшлеге турында түбәндәгеләрне билгеләргә мөмкин:

1) Рәмзия Вәлитованың әнисе – Зөһрә, Галләметдин кызы, икенче хатыныннан. “К пожилому возрасту, уже имея многих взрослых детей и даже внуков, он решил вторично жениться, хотя бабушка “Гаффа” была жива. Мотвировал он свое желание жениться тем, что бабушка “Гаффа” не любила разъезжать в гости, она была очень домовитая. Так, от второй жены дедушки у него было две дочери, Зухра (она жила в Стерлитамаке) и Рахима (она жила в дер. Зильдар ныне Миякинский район)”. Һәм этисенең энесе турында язганда “Накануне свадьбы Камали абый по дороге в Бурзян остановился ночеватьу неродной сестры (дочери нашего дедушки от 2 жены Зухры апай) в Стерлитамаке, – дип яза Мәдинә Рәхмкулова. Айдар Хәлим Зөһрәнең әнисе

тумышы белән Мулла-Гөлем авылыннан, ә Рәхимәне Шатман авылында яшәгән дип күрсәтә [11: 424].

2) Мәдинәнең әтисе Фәттәхетдин Галләметдиннең беренче хатыны Гафифәдән, ягъни Рәмзиянең әнисе Зөһрә белән Мәдинәнең әтисе Фәттәхетдин – аталары бер (Галләметдин балалары), аналары башка бертуганнар.

3) Айдар аганың карт әнисе Гайнекамал – Фәррәхетдиннең кызы. Шәҗәрә рәсемендә Фәррәхетдин Галләметдиннең улы дип күрсәтелә [11: 431], ә Мәдинә Рәхимкулова Галләметдиннең балалары исемлегендә бер дә аны күрсәтми. Галләметдин белән Фәррәхетдин бертуган булырга тиешле дип фаразлыйбыз. Моны яшәү елларының тәңгәллеге белән расларга мөмкин.

4) Мәдинә, Рәмзия, Нәҗметдин (Айдар Хәлимнең әтисе) – өчтуганнар.

5) Аларның туганлыгын түбәндәге тәртиптә билгеләргә була:

Галләметдин: Фәтхетдин (1870–1937): Мәдинә (1916–2004): Динә, Диләрә, Рәшит

Галләметдин: Зөһрә (1877 – 1920): Рәмзия (1914 – 2002): Римма, Камил: Луиза, Адилә, Аида

Фәррәхетдин: Гайнекамал: Нәҗметдин (1909 – 1945): Айдар (1942)

Инде Рәмзия апаның әтисе турында мәгълүматларны барлыйк. “1910 елда Олы Кәркәледә туй ясап, Зөһрәне Рәмиевләргә туган кеше, Стәрлетамак укытучылар училещесын тәмамлаган мөгаллим Гыйләҗ Баязитовка кияүгә бирәләр”, дип яза Айдар Хәлим [11: 424]. Мәдинә Рәхимкулова истәлекләренә караганда, “После смерти Галляметдина молодая жена со своими двумя дочерями (Зухрой и Рахимой) уехали из Каркали в соседнюю деревню Гулюм”. Туйның урыны да, елы да сорау тудыра, чөнки, беренчедән, 1910 ел булса, Зөһрәгә 33 яшь була. Бу инде ул заман өчен бик соң, икенчедән, Рәмзиягә кадәр ике ир бала булган, Рәмзия апа 1914 елда туган, димәк 4 ел эчендә 3 бала табу мөмкин түгелдер.

Айдар абый язганча, Рәмзиягә 4 яшь булганда энесе, шуннан әтисе, 6 яшь тулганда әнисе үлеп китә һәм “Стәрлетамак комсомол канткомының беренче секретаре булып эшләгәндә Казанга Татар Коммунистик университетта укырга җибәрелгән олы абыйсы Кадыйр, әниләренең җиназасына кайтып, сеңлесе Рәмзия белән энесе Кәримне балалар йортына урнаштырып китә. “Сыйнфый” саклыктан чыгып, “байлар нәселе” дигән ләкаптән качып, абыйлары әле Стәрлетамак комсомолында эшләгән чорында ук фамилияләрен Баязитовтан Вәлитовка күчергән була” [11: 424].

Безнең тарафтан архив материалларын өйрәнү барышында Гыйләҗетдин һәм Зөһрә, Рәмзия һәм Кадыйр Баязитовлар дигән исем-фамилияләр белән эзләү нәтиҗә бирмәде. Ниһаять, 1917 елда уздырылган Бөтенроссия шәһәр халкының санын алу документында 2 нче милиция участогына караган, 56 кварталда, Большая Татарская урамында Гилязтдин Мазитович Валитов 45 яшь, Зугира хатыны 40 яшь, уллары Абдулкадыр 13 яшь, Абдулкарим 10 яшь, Мостафа 6 айлык, кызлары Рәмзия 4 яшь дип теркәлгән [10]. Әйе, Рәмзия апаның туган елы 1914 булса, аңа 3 яшь дип күрсәтелгән булырга тиеш, шулай да калган фактлар хак дип уйлыйбыз. Димәк, аларның фамилиясе үзгәртелмәгән, фамилияләре

Вәлитов булган, ә Гыйләҗетдин якынча 1872 елгы, Зөһрә 1877 елгы, Әбделкадыйр 1904, Әбделкәрим 1907, Мостафа 1916/17) елгы булганнар.

1914 елда Уфа губерниясе Стәрлетамак шәһәренең йорт хуҗаларының исемлеге төзелгән документта да Большая Татарская урамында “Валитовъ Гилязитдинъ” теркәлгән (№ 23) [8].

Рәмзия апаның туган йорты Стәрлетамак шәһәренең кайсы урынында булырга мөмкин дигән сорауга җавапны карталардан эзләдек. 1858, 1890 нчы еллардагы карталарда күрсәтелгән 56 квартал Большая Татарская урамына карамый, ике картада ике җирдә, димәк, кварталларның нумерациясе үзгәреп торган. 1917 ел тирәсендәге карталарны әлегә тапмадык. Әлеге урам бүгенге көндә 7 ноябрь урамы исемендә, анда бүгенге көндә дә иске йортлар бар. Бәлкем, алдагы көндә ачыклап та булыр. Шулай ук Рәмзия апа тәрбияләнгән балалар йорты, ул укыган татар мәктәбенә кагылышлы тарихи материалларны әле эзләргә кирәк. Ә менә ул укыган Стәрлетамак педтехникумы бүгенге көндә Ходайбирдин урамындагы (картада Мечетная дип аталган) ташландык хәлдәге 15 нче йорт [3]. Әйткәндәй, ул 1926 елда ачылган, димәк Гыйләҗетдиннең анда укуы турында әйтелү дөреслеккә тап килмидер. Архив документлар нигезендә Вәлитовлар нәселенең тагын да тирәнрәк тамырларын һәм 10 буынын барладык: 1. Әбҗәлил – 2. Вәлит (1762 – 1829) – 3. Хисаметдин (1893 – 1848) – 4. Сәйфетдин (1832) – 5. Мәҗит (фаразлыйбыз) – 6. Гыйләҗетдин (1872 – 1918 (?)) – 7. Рәмзия (1914 – 2002) – 8. Камил (1941 – 2020) – 9. Луиза, Адель, Аида (1987) – 10. Василиса (2022) [4, 5, 6, 8, 9, 10].

Айдар Хәлим Гыйләҗетдин нәселенең Рәмиевләр белән туганлыгы турында әйтеп үтә. Билгеле алтынчылар Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең нәсел агачы күпләр тарафыннан өйрәнелгән һәм матбугатта тәкъдим ителгән. Шулар арасыннан “Бертуган Рәмиевләр” дигән фәнни-биографик җыентыкта (2002) Лирон Хәмидуллин тарафыннан Рәмиевләрнең нәсел шәҗәрәсен тасвирлап: “Чынлыкта исә Җиргән, Эстәрлетамак төбәгендә яшәүче Рәмиевләр белән Юлык төбәге Рәмиевләре арасында туганлык элемтәләре бик күптән өзелгән” [1: 53] дип язса да, 2022 елда гына басылган “Татар мулласы Мөхәммәтгариф Рәмиев көндәлеге”ндә (Мөхәммәтгариф Рәмиев Стәрлетамакның беренче мәхәллә мәчетендә 1891 елның 28 гыйнварыннан 1929 елның 1 августына кадәр имам-мөдәррис булып торган) Рәмиевләр нәселе турында бик тәфсилләп бирелгән, һәм мондый мәгълүмат бар: “Габделлатыйф җизнәнең (Мөхәммәтгарифнең әтисе Бәхетгәрәй белән бертуган Газизәнең) Гыйззеназ исемле кызы Эстәрлетамак сәүдәгәре Бәһаветдин Вәлидовка никахланмыш иде <...> Әсфәндияр, Искәндәр, Шәрәфетдин исемле угыллары, Лотфыкамал исемле кызы бар иде. Әсфәндиярның Габдрахман, Хәбибрахман исемле ике угылы булып, әлхаль Эстәрлетамакталар. Искәндәрнең Шәрифулла, Лотфулла исемле, Шәрәфетдиннең Зариф, Гариф, Гайфулла исемле угыллары булып, карьядә торалар. Лотфыкамал Орски өязе Юлык карьясендә Габделлатыйф Габбасов никахында булды” [2: 27].

Вәлитовлар нәселен Ревизская сказкалар буенча барлаганда, 1850 елгы документта Хисаметдиннең өченче племяннигы Баһаветдин Сәйфелмөлекнең

улы (31 яшь), икенче хатыны Гыйззеназ Габделлатыфова (23), уллары Әсфәндияр (5 яшь), Искәндәр (2 яшь) дип күрсәтелгән [5].

Димәк, көндәлектә тулы итеп бирелгән мәгълүмат рәсми документлар белән дә раслана, ягъни Шакир, Закир Рәмиевләрнең ике туганы яки туганнан туганы Гыйззеназ Рәмзиянең Хисаметдин бабасының абыйсы Сәйфелмөлекнең улы Баһаветдингә кияүгә чыккан була.

Шулай итеп, Рәмзия Вәлитованың биографиясе буенча билгеле булган мәгълүматларның бер өлеше дөреслеккә рас килә, кайсыларын әле ачыклап бетерәсе бар.

## Файдаланылган чыганаклар


1. Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-биографик җыентык. – Казан: Рухият, 2002. – 368 б.
2. Дневник татарского муллы Мухамметгарифа Рамеева – Татар мулласы Мөхәммәтгариф Рәмиев көндәлеге / Сост. Р.Ф. Масагутов, пер. А.М. Гайнутдинов. – Казань: Грумант, 2022. – 180 с.
3. Литературная карта Башкортостана. Стерлитамакский пед. техникум. URL: http://libmap.bashnl.ru/node/488?ysclid=loj2o968je537156947 (дата обращения 02.11.2023 г.)
4. НА РБ д. 408, л. 623 - 624 об. Ревизская сказка 1834 года апреля 17 дня, Оренбургской губернии города Стерлитамка о состоящих мужского и женского полов 3й гильдии купцах.
5. НА РБ д. 651, л. 28 - 29 об. Ревизская сказка 1850 года октября 30 дня, Оренбургской губернии города Стерлитамка о состоящих мужского и женского пола купцах.
6. НА РБ Ф.И 138 оп. 2 д. 105, л. 16. Ревизская сказка 1811 года сенября 22 дня, Оренбургской губернии города Стерлитамака о купцах.
7. Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 2 т. (XX гасыр – XXI гасыр башы). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 486 б.
8. ФИ.132, оп. 1, д. 1346. Список домовладельцев г. Стерлитамака Уфимской губернии. 1914 г.
9. Фонд 38, оп. 2, д. 4. Л. 361. ГА Об. респ. Ревизская сказка 1795 года. Оренбургская казенная палата.
10. ФР. 473, оп.1, д. 317. Подворная карточка переписи городского населения Стерлитамака, октябрь 1917 г.
11. Хәлим А. Минем Түгәрәк Имәнем. – Уфа: Вместе, 1990. – 760 б.

Хәбибуллина Р.Р., Ибраһимова Л.Ф.,
Арча районы “Г.Тукай исемендәге Ашытбаш урта гомуми белем мәктәбе"
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
башлангыч класс укытучылары

# БЕЛЕМ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮДӘ БӨЕК МЕТОДИСТЛАРНЫҢ (ВАГЫЙЗОВ С.Г.ҺӘМ ВӘЛИТОВА Р.Г.) РОЛЕ

**Аннотация:** Система образования в России имеет свою особенность. Она представляет собой совокупность взаимосвязанных элементов функционирующих как единое целое. Охватывает различные стороны сложного объекта: строение, состав, способ существования. Характеризуется свойствами целостности, сложности, организованности.

**Ключевые слова:** “Веселая грамматика”, татарская “Алифба”, ценности великих методистов, функциональная грамотность

Һәр чорда да укытучылар алдында укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү бурычы торды. Икенче буын ФДБС буенча да укучыларны төрле эшкә җәлеп итү аша, аларның фикерләвен, сөйләмен, рухи үсешен тәэмин итү бурычы билгеләнде. Без укучыларга әзер белем бирү белән шөгыльләнмичә, белемне укучыларның үзләреннән таптырту алымнарын күздә тотып эшләргә, алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтергә тиеш. Шул очракта гына безнең укучылар яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган һәм җәмгыятькә файдалы шәхесләр булып үсәчәкләр.

“Кешегә бетмәс – төкәмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, иреккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк “, - дип язган моннан күп еллар элек Л.Н.Толстой. Бүгенгесе көндә дә бу фикерләр белән килешми мөмкин түгел. Яңача укыту технологиясенең нигезендә укучы һәм укытучы арасында яңача мөнәсәбәт тора. Дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә, шатлык – бәхет алып килергә, дәрестән бала ниндидер ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш. Ә иң мөһиме – укучылар дәреснең һәр этабында логик яки иҗади фикер йөртсен өчен шартлар тудырырга кирәк.

Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерүгә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын кулланып эшләү, укучыларга алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтү.

Заманча мәктәпнең иң мөһим бурычларыннан берсе - функциональ белемле шәхес формалаштыру. Нәрсә соң ул “функциональ грамоталылык”?

Функциональ грамоталылык терминына килгәндә, совет һәм Россия лингвисты, психолог А.А.Леонтьев түбәндәге билгеләмәне бирә: «Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында

алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул». Әлеге билгеләмәне гадиләштерсәк, функциональ грамоталылык – кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, тиз җайлашу һәм анда эшләү сәләте

Белгәнебезчә, функциональ грамоталылык күпкырлы төшенчә. Ул үз эченә:

- уку грамоталылыгын,
- математик грамоталылыкны,
- табигый-фәнни грамоталылыкны,
- финанс грамоталылыгын,
- глобаль компетенцияләр,
- креатив фикерләүне ала.

Функциональ грамоталылык нигезләре башлангыч мәктәптә салына, анда сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә – язуга, укуга, сөйләшүгә һәм тыңлауга интенсив өйрәтү бара.

Төп максатларыбызның берсе – укучыларның алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтү. Уку грамоталылыгын формалаштыруда текст белән эшли белүгә игътибар итәргә кирәк, чөнки текст уку ул – белем бирү генә түгел, тәрбияви бурычлар үтәүне дә үз эченә ала. Шәхеснең рухи-әхлакый сыйфатларын формалаштыруда текст белән эшләүнең роле зур. Дәрестә текст белән эшләүне укучыларга кызыклы да, аңлаешлы да булырлык итеп оештырырга кирәк. Язма текстлар белән эшләгәндә дәресләрдә түбәндәге эш алымнары кулланыла:

- текстның исеменә игътибар итү, «Ни өчен текст шулай дип аталган?» соравына җавап эзләү, темасын билгеләү;
- төп сүзләрне аерып алу һәм язып кую;
- тексттан ачыктан-ачык бирелгән мәгълүматны яки фактларны таба белү, аларны тормыштан алынган мисаллар белән ныгыту;
- текстны кисәкләргә бүлү, планын төзү;
- тексттан төп вакыйгаларны аерып ала белү;
- тәкъдим ителгән рәсем һәм иллюстрацияләрнең текстның кайсы өлешен ачу өчен кулланылуын әйтү;
- текст нигезендә зур булмаган монологик яки диалогик сөйләм төзү;
- укылган текст эчтәлеге буенча дискуссияләр, дебатлар оештыру һ.б.

Критик фикерләү технологиясе элементларын куллану укучыларда уку грамоталылыгын формалаштыруның өстенлекле бер алымы булып тора. Фикерләү күнекмәсе укучыларга уку дәверендә генә түгел, алдагы тормышларында кирәк булачак (килеп туган мәсьәләне дөрес чишү юлларын табу, күпсанлы мәгълүмат белән эшләү, анализлау).

Кеше борын заманнан ук балаларны ана теленә өйрәткән, аның телен шомартуга, сүзлек хәзинәсен арттыруга, сөйләгәндә һәм язганда, аннан оста файдалануга бик нык игътибар иткән.

Ана, баласына “тел ачкычы” бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уеннар оештырган: үсә төшкәч, такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән, бәетләр әйткән, әкиятләр сөйләгән.

1960 елда Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова беренче «Әлифба» китабын төзи башлыйлар, ул 1965 елда гына дөнья күрә. Татарстан АССР мәгариф министрлыгы уздырган бәйгедә Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитованың зәңгәр тышлы «Әлифба»сы икенче урынны ала. Беренче урын бирелми. Шуннан соң «Әлифба»ларга «юл ачыла». 1986 елда 6 яшьлек балалар өчен тагын бер «Әлифба», 1997 елда латин шрифтында яңа «Әлифба» төзиләр. Аларның «Башлангыч сыйныфта татар телен укыту методикасы» дәреслеге «Лингводидактиканың ин зур казанышы» дигән бәя ала. Рәмзия Вәлитова Сәләй Вәгыйзов белән берлектә 40 тан артык исемдә дәреслек һәм уку-укыту ярдәмлеге төзи. «Совет мәктәбе» (*«Мәгариф»*) журналында, республика матбугатында педагогика темасына әледән-әле мәкаләләр бастыра. Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтында лекцияләр укый. Беренче сыйныф өчен «Татар теле», «Туган тел» дәреслекләре, «Язу һәм уку», «Рәсемле әлифба», «Кызыклы грамматика» һ. б. китаплары, методик кулланмалары хәзерге көнгә кадәр кулланыла.

Әлифба авторы Сәләй Вагыйзов әлифбадан тыш яңадан кырыктан артык китап һәм дәреслек язган. Күбесен Рәмзия Вәлитова белән берлектә. “Кызыклы грамматика” дигән китабы үз авторлыгында басылган. Сәләй Вагыйзов балага белем һәм тәрбиянең аеруча үтемле итеп уен аркылы бирелгәнлеген яхшы аңлаган. Уйнаган вакытта бала күп нәрсә таный, күнекмәләр ала.

Балалар белән сүз төзү уеннарын бик күп кулланырга була. Сәләй Вагыйзовның “Кызыклы грамматика” китабында алар бихисап.

Бу бәяләп бетергесез хезмәткә тупланган грамматик уеннар, мавыктыргыч күнегүләр, табышмак, башваткыч, әкият һәм мәзәкләрне татар теле дәресләрендә бик уңышлы кулланып була. Бүгенге көн укучыларына ныклы белем бирү һәм аларда мөстәкыйльлек, ихтыяр көче, зирәклек, максатка ирешү, бергәләп эшләргә өйрәнү кебек сыйфатларны тәрбияләүдә күренекле галим-педагогларыбызның хезмәтләре үз дәрәҗәләрен бер дә югалтмыйлар.

Күп укыган бала тиз укый. Шуңа күрә башлангыч сыйныфларда китап укуга һәвәслек тәрбияләү, әдәбиятны сүз сәнгате буларак кабул итәргә өйрәтү мөһим мәсьәлә булып тора. Уку күнекмәләре укуга һәвәслек белән бергә генә үсеш алырга мөмкин.

Сәнгатьле уку - әсәрне аңлату ысулы. Ул - әсәрне (геройларның халәтен, аларның кичерешләрен, авторның темага, эчтәлеккә мөнәсәбәтен, язылганның матурлыгын) тирәнтен аңлау нәтиҗәсе. Башта сәнгатьле укырга балалар укытучыга охшатып кабатлап өйрәнәләр, соңыннан кайбер әсәрләрне мөстәкыйль рәвештә сәнгатьле укый алалар.

Балалар китабы белән эшләү укучыларда йөгерек, аңлы, сәнгатьле уку, текст, дәреслек белән эшләү күнекмәләре булдыру өчен гаять кирәкле нәтиҗәле чара-алымнарның берсе булып тора. Мавыктыргыч китаплар нәниләргә укый-яза белергә өйрәтү чорында тәрбия, белем бирү процессын җиңеләйтә, аларда

кызыксыну уята, омтылыш, уңай хисләр, күңел күтәренкелеген булдыра, кыскасы, нәниләрне күңел кичерешләре аша ачышлар ясарга, алар белән шатланырга, гаҗәпләнергә өйрәтә, иҗади шәхес тәрбияләргә ярдәм итә.

Әлифба – татарча белем бирү системасында иң зур баскыч. Һәр бала мәктәпкә кадәр дә һәм мәктәп бусагасын атлап кергәч тә укырга, язарга һәм туган телебезнең хәзинәләрен өйрәнергә шушы тиңсез дәреслек буенча эшен башлап җибәрә. “Әлифба – белем чишмәсе”, “Әлифба – баланың беренче уку китабы” – дип истә калдырабыз.

Укытучылар “Әлифба” авторлары Сәләй Гататдин улы Вагыйзов һәм Рәмзия Гыйләҗ кызы Вәлитоваларның фәнни-методик мирасын даими өйрәнеп, иҗади кулланалар. Аларның хезмәтләре балаларга ана телебезне өйрәтүгә, шомартуга, сүзлек күләмен арттыруга, сөйләгәндә һәм язганда дөрес кулланыш табарга ярдәм итә.

Укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру максатында кулланыла торган алымнар бихисап. Шулай итеп, текст яки мәгълүмат белән эшләү уку процессы структурасында мөһим урын алып тора. Дәрестә генә түгел, дәрестән тыш чараларда да текст белән эшләүнең мөмкинлекләре күп.

Функциональ грамоталылыкны формалаштыру – катлаулы, күпкырлы, озак вакытлы процесс. Төрле заманча белем бирү технологияләрен кулланып кирәкле нәтиҗәләргә ирешергә була.

## Кулланылган әдәбият

1. Вагыйзов С. Г. Кызыклы грамматика : Укытучылар өчен кулланма / С.Г.Вагыйзов. – 3 нче басма. – Казан : Мәгариф, 2002. – 207 б.

2. Акушева, Н. Г. Развитие функциональной грамотности чтения / Н.Г.Акушева, М. Б. Лойк, Л. А. Скороделова // Наука, образование, общество: тенденции и перспективы развития: сборник материалов XVII Международной научно-практической конференции. – 2020. – с. 49-51.

# СЕКЦИЯ 6. МУЗЕЙНАЯ ПЕДАГОГИКА В КОНТЕКСТЕ МУЗЕЙНОГО ДЕЛА
# 6 НЧЫ СЕКЦИЯ. МУЗЕЙ ЭШЕ КОНТЕКСТЫНДА МУЗЕЙ ПЕДАГОГИКАСЫ

Багаутдинова Ландыш Шамилевна
МБДОУ «Десткий сад общеразвивающего вида №7 «Детство» г.Арск
Музыкальный руководитель

## МУЗЕЙНАЯ ПЕДАГОГИКА В ДОУ

Музейная педагогика является инновационной технологией в сфере личностного воспитания детей, создающая условия погружения личности в специально организованную предметно-пространственную среду.

Результативность реализации технологии музейной педагогики в условиях ДОУ:

-Ребенок проявляет интерес к настоящему и прошлому в мире

-Дети, полюбив и освоив музейное пространство, станут в старшем возрасте наиболее благодарными и восприимчивыми посетителями музейных выставок и культурных событий, приобретут познавательный интерес к «настоящему» музею.

-Ребенок проявляет любознательность по отношению к истории

Музейная педагогика использует разные формы работы. Многие из них пришли непосредственно из классической педагогики, а другие — это специфические наработки, применяемые только в данной дисциплине.

На первый план выдвигается задача помочь ребёнку увидеть «музей» вокруг себя, т.е. раскрыть перед ним историко-культурный контекст обыкновенных вещей, окружающих его в повседневной жизни, научить самостоятельно, анализировать, сопоставлять, делать выводы. Включение музеев в образовательный процесс – дело не такое простое, как может показаться на первый взгляд.

Чтобы воспользоваться музейной педагогикой, необходимо следовать определённым правилам.

**Правило первое.** К посещению музея необходимо серьёзно, целенаправленно готовиться, а потом закрепить полученные знания и впечатления. Ребёнок не подготовлен к восприятию сложного символического языка музея. Задача педагога состоит в том, чтобы помочь маленькому человечку в этой непростой и очень важной познавательной деятельности.

**Правило второе.** Необходимо четко осознавать конечную задачу своей деятельности – формирование творческой личности, способной заинтересованно воспринимать культурное наследие и сознавать свою ответственность не только за его сохранение, но и за приумножение и передачу этого наследия другим поколениям

В настоящее время проявляется всё больший интерес к традициям, истории, культуре своей малой родины. В ДОУ решаются задачи по раннему приобщению детей к народной культуре, познанию прошлого. Одна из форм ознакомления детей с родным краем – организация в детских садах мини-музеев.

В условиях систематической работы и методически правильной организации педагогического процесса не только возможно, но и необходимо начинать обучение музейному восприятию с раннего возраста. При этом неоценимо велика роль музея, его огромные возможности для приобщения к миру музейных ценностей.

Чтобы донести до сознания дошкольников, что они являются носителями народной культуры, воспитать ребят в национальных традициях, необходимо обратиться к истокам народной культуры и, в первую очередь, к народной кукле.

Создание мини-музея «Народные куклы» в образовательном пространстве значительно обогащает развивающую среду группы. Выполняя свою педагогическую функцию, мини-музей народной куклы открывает для детей возможность узнать культуру, историю страны, родного края, для формирования основ патриотического воспитания.

Мини-музей «Народные куклы» позволяет приобщать детей к истокам народной и национальной культуры, способствует сохранению народных традиций, воспитанию чувства патриотизма и духовности, позволяет развивать у дошкольников способности к эстетическому созерцанию и сопереживанию, потребность и способность самостоятельно осваивать окружающий мир.

Причиной создания мини-музея «Народные куклы» в детском саду стало то, что народные игрушки незаметно исчезли из жизни наших детей. Народная игрушка в наши дни стремительно превращается в сувенирную продукцию, не предназначенную для ребенка и не требующую педагогического сопровождения. В основном ребята играют с персонажами иностранных кукол и мультфильмов (куклы Барби, Винкс, Человеки-пауки и др.), которые не несут никакой педагогической ценности.

Таким образом, создание музейной среды в дошкольной организации с помощью детей и их родителей, социальных партнеров предоставляет редкую возможность приобщения к природным, материальным и внутренним богатствам общества в процессе интересной деятельности. Музейная педагогика научит детей, и не только их, дорожить и оберегать наследие предшествующих поколений и умело ими воспользоваться. Это даст ощущение почвенности и будет содействовать формированию единства картины мира и исторического процесса.

Вәлиева З.Җ.
Арча шәһәре, Арчаның 11 номерлы балалар бакчасы тәрбиячесе

# БАЛАЛАРГА ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮДӘ МУЗЕЙ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Туган тел – туган җир, Туган ил төшенчәләренең төп мәгънәсен бала аңына җиткерүче иң мөһим чара. Балаларга патриотик тәрбия бирү туган телдән башка мөмкин түгел. Баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып-белүе һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның туган телен – ана телен белүенә бәйле.

Милләтебезгә карата олы ихтирам хисләре тәрбияләгәндә, татар халкының милли мирасыннан файдалануга җитди игътибар ителергә тиеш, шунда гына мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телне яхшы үзләштерүләренә, аны ана теле итеп кабул итүләренә ирешергә мөмкин.

Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне аңлата, ягъни ул бала күңелендә Туган илнең табигатенә, туган йортына, туган авылына яки шәһәренә, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбәрәт.

Әхлакый-патриотик тәрбиянең кирәкле шарты булып әти-әниләр белән үзара тыгыз элемтә тора. Үз гаиләсенең тарихына кагылу балада көчле эмоцияләр барлыкка китерә. “Сезнең гаиләдә һәм сезнең кул астында булачак гражданин үсә… Илдә нәрсә генә булса да, сезнең күңелегез һәм сезнең фикерегез аша ул балаларга барып ирешергә тиеш”, – дип яза күренекле рус педагогы А.С.Макаренко. Укыту-тәрбия бирү процессында патриотик тәрбия бирү бакчада мөһим урын алып тора.

Кешенең мәктәпкәчә балалык чоры – аның әхлак йөзе үсешендә бик мөһим этап. Бу елларда тирә-якны иң беренче күзаллау, патриотик хисләр формалаша, әхлак нигезе салына. Галимнәр фикеренчә, нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтә балаларның акыл үсеше югары темпта була. Балалар бакчасындагы балалар шактый зур күләмле белемгә ия. Алар бүгенге көн белән генә түгел, үткәннәр белән дә кызыксына. Балаларның кызыксынуларын, яшь үзенчәлекләрен искә алып, мин балаларны туган якның тарихы белән таныштыра башладым. Һәм түбәндәге бурычларны куйдым:

– балаларда үз гаиләсенә, өенә, балалар бакчасына, урамга, шәһәргә мәхәббәт тәрбияләү;

– туган як табигате белән кызыксыну уяту;

– туган як тарихы, гореф-гадәтләр, матур йолалар, борынгы бәйрәмнәр, халык авыз иҗаты белән таныштыру;

– музей турында аңлатма биреп, күзаллауларын киңәйтү, танып-белүне үстерү, белгәннәрен көнкүрештә куллану;

– туган якның күренекле шәхесләре белән таныштыру.

Бакчабызда борынгы татар халкының тормышын күрсәткән мини-музей бар.Ул “Әбием сандыгы “дип атала. Анда төрле экспонатлар урнаштырылган: олы мич, чүлмәк, табагач, чиккән сөлгеләр, бала бишеге, урын-җирләр, сандык, сандык эчендә милли ирләр һәм хатын-кызлар киемнәре һ.б. Балаларны шул

әйберләр белән таныштырабыз, алар бик кызыксынып һәрбер әйберне игътибар белән карыйлар.

Яшь буынга патриотик тәрбия бирүдә музейларны “җанлы тарих” дип йөртәләр. Балалар бакчасы музейларының сабыйларны туган илебезне сөюче чын гражданнар итеп тәрбияләүдә булган мөмкинчелекләре искиткеч зур.

Музей... Монда нәрсә генә юк! Балалар әти-әниләр белән бергәлектә музейны тулыландыру максатыннан аерым кешеләрдән, шәхси коллекционерлардан тарихи әйберләр, истәлекле язмалар җыйганнар. Күптөрле һәм эчтәлекле экспозицияләр укучыларга туган төбәкнең үткәнен өйрәнергә; халкыбызның гореф-гадәтләренә, матур традицияләренә ихтирам тәрбияләүдә, тарихның төрле чорларында туган төбәгебез үсешенә зур хезмәт куйган шәхесләребез, Бөек Ватан сугышы каһарманнары, оешмалар турында күбрәк белергә ярдәм итәләр.

Музейның һәр экспонаты , экскурсоводларның мавыктыргыч сөйләме бала күңеленә үтеп кереп, тирән эз калдыра. Музей эшчәнлеге аша балалар күңелендә туган якты хисләр, һичшиксез, аларны чын патриотлар итә. Музейны бизәгәндә аның эстетик зәвыклыгына зур игътибар бирелгән. Һәр бүлектәге стендлар, стенага ясалган рәсемнәр эчтәлеге һәм матурлыгы белән балаларны үзенә җәлеп итә. Күргәзмәләрдәге әби-бабалардан буыннан-буынга күчеп килгән әйберләрнең кадерләп саклануын күреп, без туган төбәгебезгә һәм аның халкына тагын да зур хөрмәт белән карыйбыз.

Әлеге музейны без татар халкының яшәеше, милли үзенчәлекләре белән укучыларны якыннанрак таныштыруны күздә тотып оештырган идек.Ул татар өе рәвешендә күрсәтелде. Биредә милләтебезнең милли йөзен билгеләүче, халкыбызның үткәнен, гореф – гадәтләрен, хезмәтен чагылдыручы материаллар тупланган. Шәһәребездә яшәүче татарларның күбесенең руслашкан татарлар булуын искә алсак, кайбер балаларның мондый әйберләрне әлегә кадәр бөтенләй дә күргәне булмавын аңларга була. Милли йөзебез авылларда яшәүче өлкән буын кешеләрендә сакланган дип әйтсәк тә, кайбер предметларны инде авылларда да бик сирәк күрәсең. Шуңа күрә дә сәке, чабагач, гөбе, күмер үтүге кебек әйберләр балаларда зур кызыксыну уята. Һәрберсенең кайда һәм ничек кулланылуы турында беләселәре килә. Шул максат белән музейда әледән – әле экскурсияләр оештырыла. Аеруча кызыксынган балалар арасыннан экскурсоводлар төркеме оештырылып, алар музейга килүчеләр өчен кызыклы әңгәмәләр оештыралар. Бу - бик җаваплы эш. Чөнки һәрбер экспонат турында тулы мәгълүматлы булу белән бергә, дөрес һәм матур итеп сөйли белергә дә, кеше алдында үзеңне тота белергә дә кирәк. Шуңа күрә бу эш мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән башланып китә. Озак вакытлар үтеп, зур тырышлык куйганнан соң гына, алар конкурсларда катнаша алырлык дәрәҗәгә җитәләрһәм теләсә кем алдында сөйли алалар.

Шулай ук шөгыльләрдән тыш уздырыла торган чараларда да музей экспонатларыннан еш файдаланабыз. Әби – бабаларыбызның гореф – гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен балаларга җиткерүдә төрле кичәләрнең роле зур. Бакчабызда даими рәвештә уздырылып килә торган “Сөмбелә”,

“Нәүрүз”, “Әбием сандыгы”, “Аулак өй” кебек кичәләр вакытында да музей материалларыннан файдаланабыз.

Бакчабызда төрле төбәкләрдән килгән кунаклар да еш була. Музейда булу аларда зур тәэсирләр калдыра. Балаларыбызның халкыбыз тарихы, мәдәнияте, гореф – гадәтләре белән кызыксынуы һәм белүе кунакларда соклану тудыра. Читтән килгән кунакларны музейда милли ризыгыбыз – чәкчәк белән сыйлау да матур бер традициягә әйләнеп китте. Кунакларыбыз белән музейда татар халык уеннарын да бергәләп уйнап алабыз.Аеруча килгән кунакларыбыз “Капкалы”, “Зәңгәр чәчәк” уеннарын яратып уйныйлар.

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк”, - ди халкыбыз. Тарихыбызның гыйбрәтле һәм сокландыргыч сәхифәләренең, халкыбызның рухи мирасының бәяләп бетергесез кыйммәткә ия булуын аңлаганда гына күңелдә милләтең өчен горурлык хисе туарга мөмкин. Балаларда туган ягыбыз, аның халкы белән горурлану хисе тәрбияләү максатыннан, бер төркем балалар белән районыбызның “Казан арты музее”на да экскурсия оештырдык. Арчабыз элек-электән үзенең осталары, тырыш һөнәрчеләре белән дан тоткан. Алтын куллы һөнәрчеләребез читекләр теккәннәр, чыпта сукканнар, агачтан төрле җиһазлар ясаганнар. Район халкы, заманча технологияләр кулланып, бу традицияләрне бүген дә дәвам итә. Әлеге тарих белән балалар музейга куелган күпсанлы экспонатлар аша таныштылар.Музей хезмәткәрләре балаларны мавыктыргыч итеп Арчаның үткәне һәм бүгенге яшәеше, яңалыклары белән таныштырдылар.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: үзенең үткәненә һәм тарихына хөрмәт белән караган халыкның гына киләчәге бар. Шуңа күрә без олы шәхесләребез, күркәм затларыбыз, халкыбыз үткән олы тарихыбыз, гүзәл туган җиребез белән горурланырга, алар рухы белән яшәргә, илебезнең чын патриотлары булырга һәм укучыларыбызда да шушы сыйфатларны тәрбияләргә тиешбез. Патриотлар булып тумыйлар, патриотлар булып формалашалар. Музей эшчәнлеге белән кайнап үскән буын исә киләчәктә, һичшиксез, үз иленә лаеклы гражданин булуы белән горурланачак!

Кулланылган әдәбият чыганаклары

1.https://nsportal.ru/detskiy-sad/materialy-dlya-roditeley/2022/09/26//(Дата обращения:12.10.2023)

2.http://магариф.рф/(Дата обращения:12.10.2023)

3. http://teachersalliance.ru/index.php/biblioteka/klassnyj-rukovoditel/1936/(Дата обращения:12.10.2023)

4.Гера, Р. Воспитание патриотизма средствами краеведения / Р. Гера // Воспитание школьников. – 2005. - № 10. – С. 6-8.

5.Золотова Н. Музей и дети. Взаимосвязь эстетического и этического воспитания //Искусство в школе. - 2009. - N 4. - С. 58-59.

6.Зурабова К. Воспитать уважение к культуре // Дошкольное воспитание. – 2005. - N 4. - С. 82-90.

7.Скобликова Т. Музейные технологии приобщения к национальной культуре //Искусство в школе. – 2007. - N 2. - С. 30-31.

Ганиева Р.З., Сафиулина Н.Х.
г. Арск, МБДОУ «Арский детский сад №2»,воспитатели

# МУЗЕЙНАЯ ПЕДАГОГИКА В ДЕТСКОМ САДУ

**Аннотация** - Статья посвящена становлению и развитию нравственных и патриотических чувств молодого поколения через музейную педагогику. Музейная педагогика рассматривается как интегративная и качественно новая сфера образовательной деятельности и как инновационная педагогическая технология.

**Ключевые слова-** музейная педагогика, мини-музей, экспонаты, педагогические технологии.

Музейная педагогика является инновационной технологией в сфере личностного воспитания детей, создающая условия погружения личности в специально организованную предметно-пространственную среду. Музейная педагогика в последние десятилетия приобретает большую популярность в системе дошкольного образования и воспитания — создаются музейные программы, выходят книги, разрабатываются методические рекомендации (это работы М. Ю. Коваль, О. В. Дыбиной).Понятие «музейная педагогика» появилось в начале 80-х гг. и было заимствовано из немецкой терминологии. За это короткое время сам термин и обозначаемая им деятельность прочно вошли в педагогическую практику, об этом свидетельствуют музейно-образовательные программы для воспитанников образовательных учреждений. Понятие «музейная педагогика» было сформировано и введено в научный оборот в начале XX века в Германии.

Немецкий учёный Г. Фройденталь сформулировал совокупность требований кпроведению занятий в музее, актуальных и сегодня:

- каждое посещение музея – это занятие, и оно должно иметь конкретную (учебную, воспитательную, развивающую) цель;
- воспитатель и дети должны осознавать, что посещение музея – не развлечение, а серьёзная работа, а поэтому нужно готовиться к нему;
- посещать музей нужно после предварительной подготовки и в процессе занятий, когда дети не устали и готовы к восприятию;
- следует отказаться от обзорных экскурсий, «как безумно тяжёлых не только для сознания ребёнка, но и взрослого»;
- отбирать экспонаты для экскурсионного показа нужно на основе возрастных интересов ребёнка;
- итогом посещения музея должно быть самостоятельное творчество детей (рисунок, сочинение на тему увиденного, создание моделей и т.д.).

Основной целью музейной педагогики является: приобщение к музеям подрастающего поколения, творческое развитие личности. Поэтому на сегодняшний день музейную педагогику рассматривают как инновационную педагогическую технологию.

Результативность реализации технологии музейной педагогики в условиях ДОУ. Но Что же такое музей? И вообще понятие музейная педагогика?

«Музей – это смесь искусства и истории, документа и романа, которая посылает нам через многие годы луч света и доносит уникальные по ценности опыт и знания»

«Музейная педагогика – область науки, изучающая историю, особенности культурной образовательной деятельности музеев, методы воздействия музеев на различные категории посетителей, взаимодействие музеев с образовательными учреждениями».

Музейная педагогика в детском саду является одним из компонентов подготовки ребенка к дальнейшему обучению в школе. Важная особенность мини-музеев ДОУ — участие в их создании детей и родителей (законных представителей). Дошкольники чувствуют свою причастность к созданию мини-музея. Они могут: участвовать в обсуждении его тематики, приносить из дома экспонаты, ребята из старших групп проводить экскурсии для младших дошкольников, пополнять их своими рисунками. Заключается в следующем:

- У ребенка появляется шанс стать интеллигентным человеком, с детства приобщенным к культуре и к одному из ее замечательных проявлений - музею.
- Дети, полюбив и освоив музейное пространство, станут в старшем возрасте наиболее благодарными и восприимчивыми посетителями музейных выставок и культурных событий, приобретут познавательный интерес к «настоящему» музею.
- У детей формируется ценностное отношение к истории, появляется интерес к музеям и выставкам, развивается эмоциональный отклик. «Ребенок должен покидать музей с ощущением уверенности подъема «еще на одну ступеньку».

Задача педагога заключается в том, чтобы научить ребёнка распознавать эти скрытые в предметах смыслы.

Решившись на этот шаг, необходимо осознать и сформулировать **ближайшие задачи:**

* учить ребёнка видеть историко-культурный контекст окружающих вещей, т.е. оценивать его с точки зрения развития истории и культуры;

* формировать понимание взаимосвязи исторических эпох и своей причастности к иному времени, другой культуре посредством общения с памятниками истории и культуры;

* развивать способность к эстетическому созерцанию и сопереживанию;

* вызывать уважение к другим культурам;

*развивать способность и потребность самостоятельно осваивать окружающий мир путём изучения культурного наследия разных эпох и народов.

На первый план выдвигается задача помочь ребёнку увидеть «музей» вокруг себя, т.е. раскрыть перед ним историко-культурный контекст обыкновенных вещей, окружающих его в повседневной жизни, научить самостоятельно, анализировать, сопоставлять, делать выводы. Включение музеев в образовательный процесс – дело не такое простое, как может показаться

на первый взгляд. Чтобы воспользоваться музейной педагогикой, необходимо следовать определённым правилам.

**Правило первое.** К посещению музея необходимо серьёзно, целенаправленно готовиться, а потом закрепить полученные знания и впечатления. Ребёнок не подготовлен к восприятию сложного символического языка музея. Задача педагога состоит в том, чтобы помочь маленькому человечку в этой непростой и очень важной познавательной деятельности.

**Правило второе.** В настоящих музеях трогать ничего нельзя, а в мини-музеях не только можно, но и нужно! Их можно посещать каждый день, самому переставлять экспонаты, брать их в руки и рассматривать. В обычном музее ребенок — лишь пассивный созерцатель, а здесь он — соавтор, творец экспозиции. Причем не только он сам, но и его семья. Каждый мини-музей — результат общения, совместной работы воспитателя, детей и их семей. Мини-музеи постоянно пополняются новыми экспонатами. Здесь же размещаются детские работы, выполненные совместно со взрослыми.

**Экскурсионная работа с детьми решает следующие основные задачи:**
-Выявление творческих способностей детей;
- Расширение представлений о содержании музейной культуры;
- Развитие начальных навыков восприятия музейного языка;
-Создание условий для творческого общения и сотрудничества. Методические формы экскурсионной работы с детьми дошкольного возраста в условиях музея достаточно разнообразные: проведение обзорных и тематических экскурсий, познавательных бесед и мероприятий, организация выставок, викторины, дидактические игры, творческие задания.

Методические принципы экскурсионной работы четко определяются такими важными факторами, как развивающая направленность обучения, психологические особенности личности и возрастные особенности музейного восприятия.

**Особенности организации мини-музеев в дошкольном образовательном учреждении.**

Под мини-музеем в детском саду понимается не просто организация экспозиций или выставок, а многообразные формы деятельности, включающие в себя поиск и сбор материалов, встречи с интересными людьми, их рассказы, проведение досугов и праздников, исследовательская и проектная деятельность.

Конечно, в условиях детского сада невозможно создать экспозиции, соответствующие требованиям музейного дела. Поэтому назвали их «мини-музеями». Часть слова «мини» в данном случае отражает и возраст детей, для которых они предназначены, и размеры экспозиции, и определенную ограниченность тематики. Мини-музеи в детском саду актуальны и эффективны. Они дают ребенку возможность экспериментировать, синтезировать полученные знания, развивать творческие способности и коммуникативные навыки

**Для разработки технологии использования музейной педагогики как инновационной в процессе воспитания нравственности дошкольников выделены следующие принципы:**

- Последовательность ознакомления детей с музейными коллекциями.
-Кратковременность экскурсий.
- Поощрение детских вопросов и фантазий при восприятии.
-Доступность.
-Наглядность.
-Содержательность.
- Гуманизм.
- Подвижность структуры занятий-экскурсий (четкий сценарий, но возможность импровизации).

Алгоритм по созданию мини-музеев в группах:
1) выбор темы мини-музея
2) определение места размещения мини-музея
3) планирование экспозиций
4) выбор дизайна оформления мини-музея
5) подбор экспонатов
6) оформление визитной карточки и паспорта мини-музея
7) разработка форм работы с экспозициями мини-музеев
8) разработка ознакомительной экскурсии в мини-музей
9) разработка конспектов занятий с использованием экспозиций мини- музея
10) планирование организации поисково-познавательной деятельности в мини-музеях ДОУ.

**Размещение мини-музеев.**

Для расположения мини-музеев можно использовать различные части групповых комнат, «раздевалок», спальных комнат, стены у входа в группу и т.п. Даже картонная ширма – раскладушка, расположенная в раздевалке, поможет выделить место для маленького передвижного музея. Экспонаты могут располагаться на полках, стеллажах, прикрепляться к стенам, стоять на полу. Внимание детей дошкольного возраста еще недостаточно сформировано. Оно отличается кратковременностью, неустойчивостью. Поэтому эффективность всей работы в мини - музее будет в немалой степени зависеть и от того, насколько удачно расположены экспонаты, от степени их привлекательности для ребенка.

**Схема описания экспонатов в каталоге**.

*Краткая информация об экспонате:* (Где встречается, почему имеет такое название, особенности: например, листья, цветки, плоды у растений; цвет, форма у камней; как используется человеком; проблемы охраны; связи с другими компонентами природы — например, кто питается этим растением, животным, из каких растений сделано гнездо.)

*Как использовать в работе с детьми:* (При изучении каких блоков программы используется экспонат; на что обратить внимание при работе с детьми; какие виды деятельности можно использовать (экспериментирование, рисование, моделирование). *Дополнительная литература:* (Перечисляется литература для педагогов; литература для детей, в которой описывается этот объект, энциклопедии, справочники, в которых есть иллюстрации с его изображением и с изображением мест его обитания.) Мини-музей играет большую

познавательную и воспитательную роль для дошкольников, а также способствует укреплению сотрудничества детского сада и семьи. Создание мини-музеев способствует возникновению интереса, как у детей, так и у взрослых, желания узнать больше.Экспонаты музея используются для развития речи, воображения, интеллекта, эмоциональной сферы ребенка. Старшие дошкольники могут выступать в мини-музее в роли экскурсоводов.

Список использованной литературы:

1. *Столяров Б.А.* Музейная педагогика. История, теория, практика: Учеб. пособие. М., 2004.
2. *Воронович В.М.* Внедрение авторской программы воспитания учащихся средствами музейной педагогики: методические рекомендации. 3. Музей. Образование. Культура. Процессы интеграции. М., 2009.
4. *Троянская С.Л.* Музейная педагогика и её образовательные возможности в развитии общекультурной компетентности: Учебное пособие. 2007

Гарифуллина Р.Х.
Арча шәһәре, Арча 10 нчы балалар
бакчасының татар теле тәрбиячесе

БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА МУЗЕЙ ПЕДАГОГИКАСЫ

**Аннотация:** Мәкалә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирүдә музейларның ролен ачыклый, “ балалар бакчасы- музей” бердәмлеген булдыруда музей педагогикасының мөмкинлекләрен күрсәтә. Эшемнең максаты: бакчабызда эшләп килүче татар халкы тормышына багышланган музей-почмакның мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирүдә уңай тәэсирен күрсәтү. Бурычлар

- Музей педагогикасын гамәлгә ашырганда нәтиҗәле эш алымнарын ачыклау;
- Арчаның 10 нчы номерлы балалар бакчасының белем һәм тәрбия бирү эшчәнлеге тәҗрибәсе белән уртаклашу;
- Тема буенча фәнни- методик әдәбиятны барлау.

**Ачкыч сүзләр:** музей педагогикасы, музей почмак, экспонантлар, гореф-гадәтләр.

Музей педагогикасы соңгы унъеллыкта мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә аеруча популярлашып килә. Шушы юнәлештә махсус методик киңәшләр җыелмалары, методик әсбаплар, программалар басыла.

Музей педагогикасының төп максаты: үсеп килүче буынны музейларга тарту, шәхесне иҗади яктан үстерү. Балаларның күзаллауларын киңәйтү өчен, танып-белүгә кызыксынучанлыгын һәрдаим үстереп торырга кирәк. Бу эш төрле-

төрле алымнар һәм методикалар куллануны сорый.Шуңа да бүгенге көндә музей педагогикасы белем һәм тәрбия бирүдә инновацион технология булып санала.

“ Музей педагогикасы” төшенчәсе немец терминологиясеннән 80 нче еллар башында керә һәм тиз арада педагогик эшчәнлектә кулланыла башлый. Немец галиме Г. Фройнденталь тарафыннан музейда үткәрелүче шөгыльләрьгә карата куелган таләпләр бүген дә актуаль:

- Музейда булу- ул аерым бер шөгыль, шуңа күрә анда барыр алдыннан үзалдыңа өч бурычны кую мөһим: белем бирү, тәрбия бирү, үстерү бурычлары;
- Музейда булу- ул күңел ачу чарасы түгел, шуңа күрә анда барыр алдыннан якынча әзерлек эшен уздыру кирәк;
- Бала аңы, кабул итүе өчен авыр экскурсияләрдән саклану мөһим;
- Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килә торган экспонантларны сайлау;
- Музейга баруның нәтиҗәсе булып торучы мөстәкыйль иҗат оештырылу. Мәсәлән, рәсем ясау.

Белем һәм тәрбия бирүдә музей педагогикасын актив куллану халкыбызның культурасы, үткәне белән таныштырырга ярдәм итә. Үткәннәрне белмичә, тарихны өйрәнмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш ул – узган меңнәрчә елларның җимеше, нәтиҗәсе.

Музей тирәлегендә бала һәм олы кешенең үзара аралашуы, балаларның эзләнүен, иҗат итүен һәм тәрбия-белем бирүен эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итә. Шул максаттан чыгып, безнең балалар бакчасында музей почмак (мини-музей) оештырылды. Ул татар өе рәвешендә күрсәтелде. Биредә милләтебезнең милли йөзен билгеләүче, халкыбызның үткәнен, гореф – гадәтләрен, хезмәтләрен чагылдыручы материаллар тупланган. Шәһәребездә яшәүче татарларның күбесенең руслашкан татарлар булуын искә алсак, кайбер балаларның мондый әйберләрне әлегә кадәр бөтенләй дә күргәне булмавын аңларга була. Милли почмакны булдырганда түбәндәге мксатлар куелды:

- Балаларны туган ягыбыз тарихы үткәне,гореф-гадәтләре,йола-бәйрәмнәре белән таныштыру.
- Балаларда туган илгә,туган телгә мәхәббәт,әдәплелек, инсафлылык, кешелеклелек һәм башка әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.
- Балаларны музей эшенә тарту.

Балалар бакчаларында мини- музейлар оештыруның төп үзенчәлеге- аларны булдыруга әти-әниләрне һәм балаларны тарту. Алар өйләреннән экспонантлар алып киләләр, зуррак төркем балалары кечерекләргә экскурсия үткәрә ала.

Музей педагогикасына мөрәҗәгать иткәндә түбәндәге кагыйдәләрне онытмау мөһим: чын музейларда экспонантларга кагылу тыела, ә мини-музейларда моны эшләү рөхсәт ителә. Гадәти музейда бала пассив тыңлаучы булса, мондый музейда ул автордаш кебек. Ул гаиләсеннән экспонантны алып килә һәм аның нәрсә, кемнеке, аның ничек кулланылуы турында сөйләп бирә ала.

Балалар бакчасында музей төзү турында уйлагач, без ата-аналар белән анкета үткәрдек. Анкеталардан күренгәнчә, балалар бакчасында тәрбияләнүче нәниләрнең күбесенең музейларда булмаганлыгы ачыкланды. Сәбәпләре дә төрле булып чыкты:

- кайбер ата-аналарның вакытлары җитмәү;
- күбесенең балаларын яшь дип санаулары.

Билгеле, балалар бакчаларында музей эше таләпләренә тулысынча җавап бирерлек экспозицияләр тудырып булмый. Шуңа да алар почмак, мини сүзе белән йөртелә. Бу очракта мини сүзе әле балаларның кече яшьтә булуын да аңлата.

Музей почмаклар халкыбызның милли йола, гореф- гадәтләрен өйрәнү өчен дә уңай мохит. Чиккән сөлгеләр, карават япмалары, тәрәзә челтәрләре турында балалар ишетеп кенә калмыйча, күреп, тотып карап, яңа мәгълүмат туплыйлар. Әби-бабаларыбызның кул эшләренә алар белән бергә сокланабыз, түземле, сабыр булуларына таң калабыз. Бары түземнәр генә төннәр буе ай яктысында чигү чигеп, бәйләп утыра алган. Шуның өстенә алар оста куллы, сәнгатькә гашыйк та булганнар. Кулланыш өчен агачтан ясалган эш кораллары, талдан үрелгән бишекләр һәм башка әйберләр бүгенге көндә берәүне дә битараф калдыра алмый. Болар барысы да халкыбызның эшчәнлеге, уңганлыгы турында сөйли. Әлбәттә, моны безнең балаларыбыз белеп, матурлыкка сокланып һәм эшкә тартылып, үткәннәребезгә хөрмәт хисе белән тәрбияләнеп үсәргә тиешләр.

Экскурсияләр үткәргәндә, кайбер балалар: «Безнең әбинең дә шундый әйберләре бар», - диләр. Мәсәлән, көянтә, урак турында сөйләгәндә балалар төрле сораулар яудыра. Балаларның кызыксынуына, биргән сорауларына мин рәхәтләнеп җавап кайтарам һәм уйлап куям: димәк, хезмәт бушка китми, милләтебез яшәячәк. Ә балалар күңелендә милли үзаң, милли хисләр уяту искиткеч авыр хезмәт.

Мин бакчада татар теле тәрбиячесе булып эшлим. “ Әбиемнең сандыгы” кебек шөгыльләрне музей почмакта үткәрү гаять кызыклы. “Аулак өй”, “ Каз өмәсе”, “ Орчык бәйрәме”, “ Мич котлау” милли бәйрәм, йолаларны сәхнәләштергәндә, музейларда саклаучы экспонантлардан башка булмый. Милли бәйрәмнәрнең һәркайсында халкыбызның күркәм гореф-гадәтләре, матур йолалары, җыр-бию,уен-көлке чагыла. Милләтебезнең байлыгы булган татар халык фольклоры-бишек җырлары, такмаклар, такмазалар,әйтемнәр, санамышлар, сынамышлар сөйләм телен үстерүдә дә ярдәм итәләр.

Шөгыльләрдә әсәрләрне өйрәнгәндә, әңгәмәләр вакытында, төрле чараларга әзерләнгәндә, халкыбызның тормышы – көнкүрешенә караган төшенчәләр, әйберләр турында аңлатканда, экспонатлардан файдалану бик тә уңай. Аңлашыла да, истә дә кала. Әйтик, бала итәкле күлмәк, калфак, каба, ипи көрәге, кызыл башлы сөлгеләр турында сүз барганда, аларның һәрберсен күреп кенә калмыйча, тотып карарга мөмкинлек була. Рус балаларында татар телен өйрәнүгә кызыксыну тудыру чарасы буларак та музейның әһәмияте зур. Татарларның яшәү рәвеше, милли киемнәре, милли ашлары, һөнәрчелек үсеше турында мәгълүмат биргәндә, шулай ук шушы экспонатларга мөрәҗәгать итәбез.

Милли сәнгать әсәрләрен өйрәнү дә шушы әйберләр аша алып барыла.Әйтергә кирәк, алар татарларның тырыш та, пөхтә дә, уңган да, мәдәниятле булуларын искәртәләр.

Берничә ел элек төшерелгән видеоны сезгә тәкъдим итәсем килә. Музей почмакта төшерелгән әлеге видеокүренеш “ Әминәнең туган көне” дип исемләнде. Без анда татар, рус, мари халкы балаларының аралашып, дустанә мөнәсәбәттә яшәүләрен, бер-берсенең мәдәниятын теләп өйрәнүләрен чагылдырырга тырыштык ( видеоматериал).

Музей педагогикасын кулланып эшләү балаларның белемен киңәйтергә, системалаштырырга, туган якка мәхәббәт, аның тарихи үткәне белән кызыксынырга, ана телендә сөйләмне үстерергә мөмкинлек бирә.

Кулланылган әдәбият

Татар балалар фольклоры.Р.Ягъфәров “Раннур” нәшрияты 1999 ел.Уеннар, экиятләр, такмаклар,җырлар.

Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе.К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Р.А.Низамова Казан”Мәгариф”нәшрияты 1999ел.Дәресләр

Балаларга үгет-нәсыйхәт.Н.Ибраһимов,К.Бикчәнтәев, Ә.Мәдияров, А.Низамиев.Казан “Дом печати” нәшрияты 2001ел.Әңгәмәләр.

Гәрәева Л.Ә.
Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы
“1 нче санлы төп гомуми белем мәктәбе” МБГББУ,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## ПОЛИМӘДӘНИ ТӘРБИЯ БИРҮДӘ МУЗЕЙ ПЕДАГОГИКАСЫ
## МУЗЕЙНАЯ ПЕДАГОГИКА В ПОЛИКУЛЬТУРНОМ ВОСПИТАНИИ

**Аннотация:** В последние годы мы стали больше говорить о развитии национального самосознания людей, приобщении к этнокультуре, сохранении и уважении культурного многообразия. Поликультурное воспитание и создает условия для конструктивного взаимодействия на основе развития мировоззрения личности. Поэтому считаю значение музейной педагогики неизменным, так как именно она обеспечивает связь времён и создаёт условия, обеспечивающие развитие личности в поликультурном пространстве. Литературный музей Рафаэля Мустафина в первой школе Бавлинского муниципального района является одним из важнейших средств обучения и воспитания молодежи.

**Ключевые слова:** музейная педагогика, поликультурное воспитание.

Глобаль цифрлаштыру, техник прогресс ярдәмендә тормышыбыз тагын бер баскычка югары күтәрелгән чорда җәмгыятькә эшлекле кешеләр генә түгел, гомумкешелек мәдәнияте хәзинәләрен аңлый торган белгечләр дә кирәк. Шуңа күрә соңгы елларда кешеләрнең милли узаңы үсү, этномәдәнияткә тартылуы,

мәдәни күптөрлелекне саклау һәм хөрмәт итү, белем һәм тәрбия алуга тигез хокуклы булу, гомуммилләт сәяси, икътисадый, рухи кыйммәтләр формалаштыру турында ныграк сөйли башладык. Мәктәптә белем алган чагында бала шәхесенең гражданлык позициясе формалаша, шуңа күрә мәгарифнең бурычы: баланы үз милләте мәдәнияте өстенлегендә үзе яши торган төбәктәге башка халык мәдәниятләре үрнәгендә тәрбияләү. Икенче төрле әйткәндә, полимәдәни тәрбия бирү. Бу төшенчә бүгенге көндә бик вакытлы, бик актуаль яңгырый, чөнки ул шәхеснең дөньяга карашын үстерү нигезендә конструктив хезмәттәшлек итү өчен шартлар тудыра. Моннан тыш, полимәдәни тәрбия дистә еллар дәвамында безнең янәшәбездә яшәгән Идел буе халыкларның гореф – гадәтләрен, мәдәниятләрен, тарихларын хөрмәт итүне күздә тота.

Безнең Татарстаныбыз – гуманлылык тәрбияләү мәсьәләләре өстен куелган республика. Биредә 170 тән артык милләт һәм этник төркем вәкилләре яши. Шәһәрләрдә һәм авылларда татарлар, руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар, башкортлар, украиннар, әзербайҗанлылар һәм башкалар бәйрәмнәрне уртак итәләр. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында полимәдәни тәрбияләү мәсьәләсе аеруча актуаль. Үзеңне кече Ватаныңда – үз шәһәреңдә, үз урамыңда яшәүче кешеләрнең берсе буларак тоймыйча, илнең чын гражданины булу мөмкин түгел. Шуңа күрә полимәдәни тәрбия бирүдә музей педагогикасының әһәмияте алыштыргысыз дип саныйм. Кешеләр һәм вакыйгалар турында мәгълүмат чыганагы буларак музей гаиләнең социум белән хезмәттәшлегенә ярдәм итәргә, балаларда бердәмлек хисе тудырырга, тарихи һәм мәдәни мираска җәлеп итәргә, гражданлык бурычы җаваплылыгы, әхлакый кыйммәтләр һәм толерантлык тәрбияләргә сәләтле. Ә толерантлык ул – үзеңнең уникальлегеңне аңлау һәм шул ук вакытта башкаларның динен, карашын саклау хокукын тану. Мәктәп музее укучыларның шундый аңы формалашуга ярдәм итә дә. Яңартылган федераль дәүләт белем бирү кысаларында мәктәп музее – укытуда системалы-эшчәнлекле якын килүне гамәлгә ашыручы дәрестән тыш эшчәнлек мәйданчыгы да әле. Биредә эшне оештыручылар да, аның төп “кулланучылары” да – укытучылар һәм укучылар үзләре. Музейны тулыландыруда, үстерүдә, бизәүдә, музей материалларын кулланып, фәнни-тикшеренү, хәрби-патриотик, иҗтимагый проектларда катнашканда балалар үз эшчәнлекләренең нәтиҗәләрен күрәләр, шул рәвешле җәмгыятькә файда китерергә өйрәнәләр. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә: “Музей – сәнгать әсәрләрен, техник, тарихи, фәнни-табигый экспонатларны җыеп саклый һәм күргәзмәгә куеп тота торган оешма” диелсә дә, мәктәп музейларының эчтәлеге күпкә тирәнрәк.

Безнең мәктәптә, Баулы шәһәренең 1 нче санлы төп мәктәбендә, ике музей бар: Туган якны өйрәнү һәм Рафаэль Мостафинның әдәби музейлары. Беренчесе мәктәпнең үзе кебек 92 ел эшләсә, икенчесе – яшьрәк. Ул якташыбыз, язучы-эзләнүче, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, журналист, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, “Почёт билгесе” ордены иясе, 50 елга якын Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын фәнни тикшергән, халыкка бу герой-шагыйрьнең намуслы исемен кайтарырга, аны дөньяга танытырга

булышкан Рафаэль Мостафинга багышлана. Мондый музей дөньяда берәү генә. Ни өчен соң ул нәкъ менә бездә ачылды? Чөнки Рафаэль ага үзенең эшчәнлеген шушы мәктәптә тарих укытучысы булып башлап җибәргән, аның туган нигезе дә мәктәп янында гына.

Бишенче ел мәктәбебезнең укучылар һәм укытучылар коллективы, шушы әдәби музей белән рухланып, “Тормышка мәхәббәт һәм хакыйкатькә тугърылык” дип аталган проект өстендә эшлиләр. Әлеге тема һәр эшебездә чагыла. Ә балаларның хезмәтләре – музейның түрендә. Аларның тематикасы төрле: “Рафаэль Мостафинның “Өзелгән җыр эзеннән” әсәренең стиль үзенчәлекләре”, “Рафаэль Мостафин музееның тәрбияви әһәмияте”, “Рафаэль Мостафин иҗатында репрессияләр темасы”, “Тема добра и зла в произведении Р.А.Мустафина “Санта Барбара по-казански”, “Тема экологии и природы в творчестве Р.А. Мустафина”, “Журналисткая деятельность Р.А.Мустафина” һәм башкалар. Бу эшләр барысы да район, республика, төбәкара, ил күләмендә үткәрелә торган конкурсларда һәм фәнни-гамәли конференцияләрдә җиңүче урыннарны яулаган.

Моннан тыш мәктәптә ел саен рәсемнәр, иншалар конкурслары, сугыш һәм хезмәт ветераннары, язучылар белән очрашулар, Җиңү көненә багышланган Батырлык дәресләре һәм башка төрле хәйрия акцияләре, әлбәттә, Рафаэль Мостафинга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә.

Замана таләбе буенча без музейның мобиль вариантын да ясадык. Ягъни баннер, альбом, фотосурәтләр, алып чыгарга яраган экспонатлар ярдәмендә район күләмендә оештырыла торган семинарларда, бәйрәмнәрдә һәм күргәзмәләрдә катнашабыз. Шулай ук интернет-сылтамага кереп, музейга виртуаль сәяхәт тә ясап була.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, мәктәп музее, асылда, тикшеренү учреждениесе, иҗтимагый берләшмә, балалар клубы, иҗади остаханә функцияләрен үз эченә алган универсаль иҗтимагый институт. Ул заманнар бәйләнешен тәэмин итә – безгә кадәр яшәгән буынның фән, мәдәният, мәгариф өлкәсендәге тәҗрибәсеннән визуаль һәм практик файдалану мөмкинлеген бирә. Нәтиҗәдә, полимәдәни яссылыкта шәхеснең үсешен тәэмин итә торган шартлар тудырыла. Димәк, мәктәп музейларын хәзерге заман яшьләренә белем һәм тәрбия бирүнең мөһим бер чарасы буларак карау бик дөрес булыр.

Кулланылган әдәбият

1. Джуринский А.Н. Поликультурное воспитание в современном мире/М.: Прометей, 2012.

2. Макаев В.В., Малькова З.А., Супронова Л.В. Поликультурное образование – актуальная проблема современной школы /Педагогика, Москва, 2009. №3.

3. Музейная педагогика: Из опыта методической работы /Под ред. А.Н. Морозовой, О.В. Мельниковой. – М.: Творческий центр, Москва, 2018г.

4. Павлова И.Ю. Этнокультура тюркских и финно-угорских народов Татарстана, Казань: Татар.кн.изд-во, 2012.

5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан, “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005.

6. Таушканова А.О., Шанц Е.А. Роль музея в образовательном процессе школы//Теория и практика образования в современном мире: материалы II Междунар. науч. конф. – СПб., 2012.

Гәрәева Л.Ә.
Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы
“1 нче санлы төп гомуми белем мәктәбе” МБГББУ,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## ПОЛИМӘДӘНИ ТӘРБИЯ БИРҮДӘ МУЗЕЙ ПЕДАГОГИКАСЫ
## МУЗЕЙНАЯ ПЕДАГОГИКА В ПОЛИКУЛЬТУРНОМ ВОСПИТАНИИ

**Аннотация:** В последние годы мы стали больше говорить о развитии национального самосознания людей, приобщении к этнокультуре, сохранении и уважении культурного многообразия. Поликультурное воспитание и создает условия для конструктивного взаимодействия на основе развития мировоззрения личности. Поэтому считаю значение музейной педагогики неизменным, так как именно она обеспечивает связь времён и создаёт условия, обеспечивающие развитие личности в поликультурном пространстве. Литературный музей Рафаэля Мустафина в первой школе Бавлинского муниципального района является одним из важнейших средств обучения и воспитания молодежи.

**Ключевые слова:** музейная педагогика, поликультурное воспитание.

Глобаль цифрлаштыру, техник прогресс ярдәмендә тормышыбыз тагын бер баскычка югары күтәрелгән чорда җәмгыятькә эшлекле кешеләр генә түгел, гомумкешелек мәдәнияте хәзинәләрен аңлый торган белгечләр дә кирәк. Шуңа күрә соңгы елларда кешеләрнең милли узаңы үсү, этномәдәниятка тартылуы, мәдәни күптөрлелекне саклау һәм хөрмәт итү, белем һәм тәрбия алуга тигез хокуклы булу, гомуммиллэт сәяси, икътисадый, рухи кыйммәтләр формалаштыру турында ныграк сөйли башладык. Мәктәптә белем алган чагында бала шәхесенең гражданлык позициясе формалаша, шуңа күрә мәгарифнең бурычы: баланы үз милләте мәдәнияте өстенлегендә үзе яши торган төбәктәге башка халык мәдәниятләре үрнәгендә тәрбияләү. Икенче төрле әйткәндә, полимәдәни тәрбия бирү. Бу төшенчә бүгенге көндә бик вакытлы, бик актуаль янгырый, чөнки ул шәхеснең дөньяга карашын үстерү нигезендә конструктив хезмәттәшлек итү өчен шартлар тудыра. Моннан тыш, полимәдәни тәрбия дистә еллар дәвамында безнең янәшәбездә яшәгән Идел буе халыкларның гореф – гадәтләрен, мәдәниятләрен, тарихларын хөрмәт итүне күздә тота.

Безнең Татарстаныбыз – гуманлылык тәрбияләү мәсьәләләре өстен куелган республика. Биредә 170 тән артык милләт һәм этник төркем вәкилләре яши.

Шәһәрләрдә һәм авылларда татарлар, руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар, башкортлар, украиннар, әзербайҗанлылар һәм башкалар бәйрәмнәрне уртак итәләр. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында полимәдәни тәрбияләү мәсьәләсе аеруча актуаль. Үзеңне кече Ватаныңда – үз шәһәреңдә, үз урамыңда яшәүче кешеләрнең берсе буларак тоймыйча, илнең чын гражданины булу мөмкин түгел. Шуңа күрә полимәдәни тәрбия бирүдә музей педагогикасының әһәмияте алыштыргысыз дип саныйм. Кешеләр һәм вакыйгалар турында мәгълүмат чыганагы буларак музей гаиләнең социум белән хезмәттәшлегенә ярдәм итәргә, балаларда бердәмлек хисе тудырырга, тарихи һәм мәдәни мираска җәлеп итәргә, гражданлык бурычы җаваплылыгы, әхлакый кыйммәтләр һәм толерантлык тәрбияләргә сәләтле. Ә толерантлык ул – үзеңнең уникальлегеңне аңлау һәм шул ук вакытта башкаларның динен, карашын саклау хокукын тану. Мәктәп музее укучыларның шундый аңы формалашуга ярдәм итә дә. Яңартылган федераль дәүләт белем бирү кысаларында мәктәп музее – укытуда системалы-эшчәнлекле якын килүне гамәлгә ашыручы дәрестән тыш эшчәнлек мәйданчыгы да әле. Биредә эшне оештыручылар да, аның төп “кулланучылары” да – укытучылар һәм укучылар үзләре. Музейны тулыландыруда, үстерүдә, бизәүдә, музей материалларын кулланып, фәнни-тикшеренү, хәрби-патриотик, иҗтимагый проектларда катнашканда балалар үз эшчәнлекләренең нәтиҗәләрен күрәләр, шул рәвешле җәмгыятькә файда китерергә өйрәнәләр. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә: “Музей – сәнгать әсәрләрен, техник, тарихи, фәнни-табигый экспонатларны җыеп саклый һәм күргәзмәгә куеп тота торган оешма” диелсә дә, мәктәп музейларының эчтәлеге күпкә тирәнрәк.

Безнең мәктәптә, Баулы шәһәренең 1 нче санлы төп мәктәбендә, ике музей бар: Туган якны өйрәнү һәм Рафаэль Мостафинның әдәби музейлары. Беренчесе мәктәпнең үзе кебек 92 ел эшләсә, икенчесе – яшьрәк. Ул якташыбыз, язучы-эзләнүче, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, журналист, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, “Почёт билгесе” ордены иясе, 50 елга якын Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын фәнни тикшергән, халыкка бу герой-шагыйрьнең намуслы исемен кайтарырга, аны дөньяга танытырга булышкан Рафаэль Мостафинга багышлана. Мондый музей дөньяда берәү генә. Ни өчен соң ул нәкъ менә бездә ачылды? Чөнки Рафаэль ага үзенең эшчәнлеген шушы мәктәптә тарих укытучысы булып башлап җибәргән, аның туган нигезе дә мәктәп янында гына.

Бишенче ел мәктәбебезнең укучылар һәм укытучылар коллективы, шушы әдәби музей белән рухланып, “Тормышка мәхәббәт һәм хакыйкатькә тугърылык” дип аталган проект өстендә эшлиләр. Әлеге тема һәр эшебездә чагыла. Ә балаларның хезмәтләре – музейның түрендә. Аларның тематикасы төрле: “Рафаэль Мостафинның “Өзелгән җыр эзеннән” әсәренең стиль үзенчәлекләре”, “Рафаэль Мостафин музееның тәрбияви әһәмияте”, “Рафаэль Мостафин иҗатында репрессияләр темасы”, “Тема добра и зла в произведении Р.А.Мустафина “Санта Барбара по-казански”, “Тема экологии и природы в творчестве Р.А. Мустафина”, “Журналистская деятельность Р.А.Мустафина” һәм

башкалар. Бу эшләр барысы да район, республика, төбәкара, ил күләмендә үткәрелә торган конкурсларда һәм фәнни-гамәли конференцияләрдә җиңүче урыннарны яулаган.

Моннан тыш мәктәптә ел саен рәсемнәр, иншалар конкурслары, сугыш һәм хезмәт ветераннары, язучылар белән очрашулар, Җиңү көненә багышланган Батырлык дәресләре һәм башка төрле хәйрия акцияләре, әлбәттә, Рафаэль Мостафинга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә.

Замана таләбе буенча без музейның мобиль вариантын да ясадык. Ягъни баннер, альбом, фотосурәтләр, алып чыгарга яраган экспонатлар ярдәмендә район күләмендә оештырыла торган семинарларда, бәйрәмнәрдә һәм күргәзмәләрдә катнашабыз. Шулай ук интернет-сылтамага кереп, музейга виртуаль сәяхәт тә ясап була.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, мәктәп музее, асылда, тикшеренү учреждениесе, иҗтимагый берләшмә, балалар клубы, иҗади остаханә функцияләрен үз эченә алган универсаль иҗтимагый институт. Ул заманнар бәйләнешен тәэмин итә – безгә кадәр яшәгән буынның фән, мәдәният, мәгариф өлкәсендәге тәҗрибәсеннән визуаль һәм практик файдалану мөмкинлеген бирә. Нәтиҗәдә, полимәдәни яссылыкта шәхеснең үсешен тәэмин итә торган шартлар тудырыла. Димәк, мәктәп музейларын хәзерге заман яшьләренә белем һәм тәрбия бирүнең мөһим бер чарасы буларак карау бик дөрес булыр.

Кулланылган әдәбият

1. Джуринский А.Н. Поликультурное воспитание в современном мире/М.: Прометей, 2012.

2. Макаев В.В., Малькова З.А., Супронова Л.В. Поликультурное образование – актуальная проблема современной школы /Педагогика, Москва, 2009. №3.

3. Музейная педагогика: Из опыта методической работы /Под ред. А.Н. Морозовой, О.В. Мельниковой. – М.: Творческий центр, Москва, 2018г.

4. Павлова И.Ю. Этнокультура тюркских и финно-угорских народов Татарстана, Казань: Татар.кн.изд-во, 2012.

Гильфанова Р.Н,
Балтасинский муниципальный район МБОУ “Нуринерская СОШ”,
учитель татарского языка и литературы;
Сабирова Ф. Т.,
методист МКУ “Управление образования Балтасинского районного испонительного комитета”

## МУЗЕЙ – ТӘРБИЯ УЧАГЫ

**Аннотация:** В это смутное время необходимо своевременно вносить семена воспитания в душу ребенка. Это очень важно, потому что воспитание, которое сегодня получают наши ученики, завтра – будущее нашего государства. Мы считаем, что литературный туризм - один из эффективных способов

воспитания у учащихся патриотизма. Как учителя языка и литературы, мы часто пользуемся этим методом. Музеи, которые есть в нашем районе, являются для нас большой опорой в нашем сложном труде.

**Ключевые слова**: патриотизм, воспитание, любовь к Родине, семье, национальная культура и традиции.

Бала кайсы чорда гына яшәсә дә, җәмгыять күптөрле үсеш юлларының кайсын сайласа да, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләүдә төп рольне әхлак нормалары үти. Бу болгавыр заманда бала күңеленә тәрбия орлыкларын вакытында салырга кирәк. Бу бик әһәмиятле, чөнки укучыларыбызның бүген алган тәрбиясе – иртәгә дәүләтебезнең киләчәге. Укучыларда патриотизм тәрбияләүдә әдәби туризм - отышлы алымнарның берсе дип саныйбыз. Тел һәм әдәбияты укытучысы буларак, без бу алымнан еш файдаланабыз. Төбәгебездә булган музейлар безгә катлаулы хезмәтебездә зур ярдәмче булып торалар. Шодада урнашкан "Мирхәйдәр Фәйзи", Карадуган авылында урнашкан "Себер тракты һәм Муса Җәлил", Чепья авылында урнашкан "Халыклар дуслыгы" музейларында еш кунак без. Ә мәктәп каршында эшләп килүче "Кәшифә Тумашева исемендәге музей" – күп мөгалимнәрнең ныклы ярдәмчесе.

Һәр төбәк үзенең мәдәният - сәнгатькә сәләтле, мәгърифәтле кешеләре белән билгеле. Нөнәгәр авылы да шундыйлардан дип әйтү ялгыш булмас. Татарлардан беренче хатын - кыз режиссер Кәшифә Тумашеваның тамырлары безнең авылга килеп тоташа. ***Теманың актуальлеге***: 2023нче ел – Татарстанда милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. ***Максат:*** туып үскән төбәгем Нөнәгәр авылы белән нык бәйләнгән беренче профессиональ татар хатын-кыз режиссеры Кәшифә Тумашева истәлекләрен ачыклау, аның эшчәнлеген өйрәнү аша музейларның тәрбияви әһәмиятен ачыклау. Максатка ирешү өчен алдыбызга түбәндәге **бурычларны** куйдык: Кәшифә апаны белгән шәхесләрнең истәлекләрен барлау, алар белән танышу максатыннан, миниэкспедицияләр оештыру; «Туган якны өйрәнү» музеендагы материаллар белән танышу; төбәк музейларында кунакта булу; музейларның тәрбияви әһәмиятен исбатлау. ***Өйрәнү объекты:*** «Туган якны өйрәнү» музеендагы материаллар; Кәшифә апаның кызы Зөммәрә апа һәм аны белгән кешеләрнең истәлекләре. Туган як тарихын өйрәнү үткәннәрне исән чыгармаска, киләчәкне күзалларга ярдәм итә. "Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк" ди татар халык мәкале. Үз туган җиренең тарихын белергә омтылмаган кеше - ваемсыз, дәвамына кешелек кыйммәтен бирә алмаучы мескен кешедер. Авылыбызның мең елдан артык булган тарихы – халык байлыгы. Безгә үз тарихыбызны, телебезне, мәдәниятыбызны сакларга, ныклап өйрәнергә кирәк. «Тарихыбызны ни өчен белергә кирәк?» дигән сорауга без түбәндәгечә җавап бирер идек: һәркемгә тормыш агышында югалмыйча, үз урынын белү, билгеләү өчен; туган туфрагың, ата-бабаң нигезен хөрмәтләү, Ватаныңны ярату өчен; хәзерге буыннан соң дөньяда тормыш дәвам итәчәген һәм киләсе буыннарга якты истәлек калсын өчен. Моны музейларга сәяхәт аша тормышка ирештерә алабыз.

Мәктәп музейларының специфик үзенчәлеге бар. Беренчедән, алар - укыту-тәрбия учагы, чөнки барлык җыелган материал укучыларның һәм

укытучыларның үз куллары белән эшләнгән һәм алар дәресләрдә кызыклы күрсәтмәлелелек ролен үтиләр. Мәктәптәге күп чаралар музейда үтә. Икенчедән, музей эшчәнлеге үзе үк укучылар үзидарәсен эшләтә, укучыларны эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә тарта. Өченчедән, мәктәп музее ул - җыелган кыйммәтле әйберләр җыю урыны гына түгел, ә фәнни-педагогик эшчәнлек алып бару урыны да. Музеебыз экскурсоводлары – мәктәп укучылары. Алар туган як тарихы белән башкаларны да таныштыра. Мәктәпкә килгән кунаклар да музейга чакырыла. Алар үз чиратларында авыл тарихы, аның үткәне, киләчәге турындагы уй-фикерләрен, теләкләрен әйтәләр; музейдагы дәфтәргә экскурсия турындагы фикерләрен язалар. Кайчандыр шушы мәктәпне бетереп киткән күренекле шәхесләрнең язмаларын укып, укучыларда туган якларына карата зур горурлык хисләре уяна. Бу тәрбия түгелмени?! Нинди генә тәрбия әле.

Музей ишеген ачып керүгә, йөрәкләрне җилкендереп, туган авылыбыз табигате, картасы һәм туган авылымның матур урыннары төшерелгән картиналар галереясы каршы ала. Шулай ук бу бүлектә колхоз тарихына караган альбомнар, авылыбызның хезмәт алдынгылары турында газета материаллары, күп санда фоторәсемнәр тупланган. Аларны караганда, балалар үз әби-бабаларын танып, алар өчен горурлану хисләре кичерәләр. Хезмәт тәрбиясенә, профориентациягә багышланган сыйныф сәгатьләренә бу материаллар - үзе бетмәс хәзинә. Укучыларда туган авыл белән горурлану хисләре туа. Бу хис икенче залга узганда да озата бара. Түрдә зур ак мич. Янында сәке, агач өстәл, урындыклар. Өстәл өстендә, кукыраеп, җиз самавыр утыра. Шулай ук элеккеге авыл тормышын гәүдәләндергән бик күп экспонатлар тезелеп киткән. Ирексездән күңел мич артыннан чыгучы табагач тоткан Акъәбине көтә. Әхлак тәрбиясе шул түгелмени?! Өлкән яшьтәге апалар күзләрен бетереп, йөрәк җылыларын биреп чиккән сөлгеләрен, намазлыкларын да алып килеп, шушы музейга бирәләр, чөнки аларның аны куярга өйләрендә урыннары юк. Хәзерге яшьләрнең дизайнга булган мөнәсәбәтләре башка, аларга чиккән сөлгеләр кирәк түгел. Димәк, музей бик кирәкле ядькәрләр җыела торган урын да булып тора.

“Мәктәбем-горурлыгым” бүлегендә мәктәпнең бер гасырлык тарихы тупланган. Пионер тарихына караган экспонатлар-галстуклар, значоклар, байраклар, укучы формасы бар. Совет чорын гәүдәләндергән бу почмак – шулай ук тәрбия чарасы. Музейда “Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый!“ дигән почмак урнаштырылган. Бу почмакта Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашларыбыз турында бай мәгълүмат тупланган. Уртада - репрессия корбаннарына багышланган стенд. Язучы Ибраһим Сәләховның авылдашыбыз Алкин Разит Рияз улына язган хатлары, алар турында истәлекләр тупланган. Укучыларда патриотик хисләр тәрбияләр өчен бар нәрсә үз урынында.

Тарих битләрен актарганда, халыкның горурлыгы булган, эшләгән эшләре, ирешкән уңышлары белән ил күгендә якты эз калдырган шәхесләр белән танышасың. Чын мәгънәсендә олы тормыш юлы узган бу затлар. Кайда туып ускән, яшәүгә көч, илһам каян алган икән дип куясың. Кешеләрне, тормышны яратып, хезмәтен, иҗатын халыкка багышлаган шәхесләр арасында безнең туган төбәгебездә туып үскән кешеләр дә бик күп. Димәк, игелекле туган туфрагыбыз

аларга яшәү көче биргән, сайлаган кыйблаларына тугрылыклы калырлык ныклык өстәгән. Яшәү кыйбласын, тормышын театр, сәнгать дөньясы белән аерылгысыз дип исәпләгән Кәшифә Җамалетдин кызы Тумашева - әнә шундыйларның берсе. Аның өчен бәхет - сәхнә, спектакльләр, сәнгать, газиз халкына хезмәт итү була. Юкка гына музей һәм аның иң зур залы бу олы шәхескә багышланмагандыр.

“Театр яктылыкка-нурга илтә, Кире юлга жибәрми уңга илтә,” – дип язган бөек шагыйребез Г.Тукай халык мәдәниятендә бик зур әһәмияткә ия булган сәхнә турында. Чыннан да, яшь буынны тәрбияләү өлкәсендә драма әсәрләрен өйрәнү бик файдалы дип уйлыйм. Укучылар башлап зур драма әсәрләре белән 5 нче сыйныфта таныша башлыйлар. Бу – Нәкый Исәнбәтнең “Хуҗа Насретдин”ы. Бишенче сыйныф укучылары өчен нинди кызыклы һәм мавыктыргыч әсәр ул. Тик аның сәхнәгә куелышы турында дәреслектә мәгълүмат бирелми. Заманында Мәскәүдә үткән татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында югары бәя алган бу әсәрне сәхнәгә куючы режиссер безнең авылдашыбыз, татар хатын-кызлары арасында беренче һәм бүгенге көнгә кадәр бердәнбер махсус югары белемгә ия булган Кәшифә Җамалетдин кызы Тумашева була. Бала чагы гаять үзенчәлекле булган Кәшифә хезмәт юлын “Зауральская” дигән сәхнә ләкабе белән башлап җибәрә. Рус драма театры каршында татар театры оеша. Режиссеры – Р. Тумашев, баш рольләрне башкаручы – К. Тумашева. Крестьян кызы үзен талантлы артистка итеп таныта. Чын артистка булып китүенә ире Рәхим абыйның һәм сәнгать эшләре җитәкчесе Леонид Баскойның роле зур була. Аны бу гына канәгатьләндерми: режиссер булу теләге тынгылык бирми. 1923нче елның җәендә Тумашевлар Казанга кайталар. Шул елны Казан театр техникумына укырга керә. Аны техникумның 2нче курсына кабул итәләр. 1926нчы елда тәмамлап, режиссер-педагог итеп шунда калдырыла. 1927нче елда Казанда радиостанциядә диктор һәм режиссер булып эшли башлый. Балалар өчен спектакль куюны да Кәшифә Тумашева башлый. Академия театрында 15 ел эшләү дәверендә утызга якын спектакль чыгара. Махсус югары белем алган режиссер диплом спектакле итеп студент-медик Хәбиб Фәтхуллинның “Күзләр” драмасын сайлый. Салих ага Сәйдәшев әсәргә тетрәндергеч көй яза... Кәшифә апа гаҗәеп эшчән һәм кешелекле була. Ул һәрчак башкалар өчен борчылып, башкаларны кайгыртып яши. Бу бигрәк тә Сара апа белән бәйле вакыйгада ачыла. Режиссер М. Фәйзинең “Ак калфак”әсәрен сәхнәләштерергә җыена. Әсәргә музыка яздырырга кирәк. Сәхнә әсәрләренә бер тапкыр да музыка язмаган Сара апаны музыка язарга күндерә. Бу Сара апаның драма әсәрләренә музыка язуга ышанычлы беренче адымнары була. Үзен талантлы режиссер итеп таныткан остазны 1955нче елда Республика күчмә театрының баш режиссеры итеп билгелиләр. Театр сәхнәсе өчен хатын-кыз режиссер сирәк күренеш булса да, ул үз хыялына тугры кала. Кәшифә Тумашеваның тынгысыз хезмәте югары бәяләнә. 1956нчы елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

Музей укытучылар, ата-аналар, авыл халкы белән тыгыз элемтәдә тора. Укытучылар музейда дәрес-экскурсияләр, тәрбия сәгатьләре үткәрәләр, музей

материалларын файдаланып, төрле конкурсларда катнашалар. Музейга экспонатлар туплауда, туган як, туган халкыбызның тарихын өйрәнүдә, төрле чаралар һәм конкурсларда катнашуда ата-аналарның да роле зур. Укучылар үз гаиләләренең тарихын, һөнәр-шөгыльләрен өйрәнеп, нәсел шәҗәрәләрен төзеде. Балаларга алдагы буыннарның бай тормыш тәҗрибәсен өйрәтү, тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру кебек төп максатларга ирешү өчен музей материаллары чиксез бай хәзинә. Җәмгыять, милләт, халык тарихы да онытылырга тиеш түгел. Аның эчендә меңнәр, миллионнар язмышы...

Файдаланылган әдәбият

1. Балтач энциклопедиясе - Казань: 2010.
2. Кәшифә Тумашева исемендәге музей хезмәткәрләре. “Мирас”, 2013.
3. Х. Әюпов. “Сабыр савытлары”. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992

Закирова Р.М., Шарафетдинова Л.Р.
г. Арск МБДОУ «Арский детский сад №10»,
воспитатели

## МУЗЕЙНАЯ ПЕДАГОГИКА В КОНТЕКСТЕ МУЗЕЙНОГО ДЕЛА

**Аннотация:** С самого раннего возраста дети начинают интересоваться предметным миром. Познание осуществляется путём накопления чувственных впечатлений от окружающих ребёнка вещей. Музей же способен обогатить впечатлениями от подачи совершенно новых, незнакомых предметов, которые ребёнок никогда не мог встретить в доступной ему деятельности. Это необычайно расширяет кругозор и представление о мире, поэтому педагоги образовательных учреждений и сотрудники музея стремятся к более раннему приобщению детей к искусству. Музеи – это древнейшее хранилище общечеловеческого опыта и ценностей. Но сокровища, чтобы не таять, а приумножаться, должны работать. Мы можем
выступить хранителями ценностей человечества, а главное, выполнить свою миссию и передать их следующим поколениям.

**Ключевое слово:** накопления, впечатлениями, кругозор, хранилище, ценностей.

На современном этапе развития человечества, формирование духовной культуры становится важной задачей развития личности. Значимую роль в этом может сыграть музей, который в отличии от других образовательных центров более демократичен и обладает способностью к воспитательному воздействию на все возрастные категории населения. Обратимся к понятию «музей». Это научное, научно-просветительское учреждение, которое осуществляет комплектование, хранение, изучение и популяризацию памятников естественной

истории, материальной и духовной культуры – первоисточников знаний о развитии природы и человечества. Ведущими учеными, специалистами-музееведами был выделен педагогический потенциал музея как компонента социокультурной среды (Н.Ф.Федоров, Н.Б.Крылова, Н.Г.Макарова и др.), обусловлены направления педагогической работы в условиях музея (А,Г.Бойко, Е.Г.Ванслова, Н.Л.Кульчинская, Б.А.Столяров), разработаны вопросы содержания образования ребенка в музейной среде (Е.Г. Ванслова, М.А.Волчкова, Т.Н.Панкратова, Т.В.Чумалова).

Как писал Р. Маркузе в своей статье «Меняющиеся музеи в меняющемся мире»: «Целью посещения музеев перестало быть запоминание имен, дат, событий; экскурсия представляет собой развитие умения видеть и понимать те особенные черты, которые различают искусство одной эпохи, страны от другой, и это становится уникальным вкладом музея в систему образования и может быть применено к любой возрастной группе и любому исходному уровню образования» Обществом все четче стали осмысливаться положения о потребности приумножения и широкого использования духовных культурных ценностей, всемерного поощрения и развития профессионального и народного декоративно-прикладного искусства с учетом специфических особенностей музейных средств. Музеи являются социальными институтами, в работе которых должно осуществляться и реализовываться воспитательное воздействие на подрастающее поколение независимо от возраста и образования.

Рассмотрим плюсы обучения и воспитания дошкольников на базе экспозиции музеев: • Во-первых, сосредоточивание в музеях многообразного систематизированного редкого материала, который способствует превращению его в подлинные очаги художественной культуры. • Во-вторых, обучение и воспитание дошкольников на базе музея подразумевает информирование детей об истории и культуре на основании оригинальных экспонатов, сконцентрировав основное внимание на тенденциях развития тех или иных сторон музейного дела. Именно подлинность, уникальность, ценность музейных экспонатов придает знаниям дошкольников особую убедительность, наглядность и достоверность. Обращаясь к уникальности музея можно сказать, что опыт личного соприкосновения с реальностью истории и культуры - то основополагающее, без чего нельзя обеспечить другие институты цивилизации.

Музей являющийся символом культуры, а так же как образовательное учреждение призван исполнить важную роль в формировании целостной личности, развитии ее общекультурной компетентности. Крупнейшим специалистом в области формирования личности дошкольника средствами музея считается выдающийся педагог А.В. Бакушинский. Анализируя образовательную работу музея в педагогике, он считал необходимым строго соблюдать возрастную специфику посетителя, который является не «объектом воздействия», а, прежде всего, партнером. На основании выдвинутых идей он считал, что педагог оказывает большое значение в развитии личности дошкольника. В связи с этим были установлены три неотъемлемых условия в работе специалиста дошкольного образования: - суметь лично прочувствовать

произведение искусства; - знать историко-искусствоведческую основу произведения; - психологически подходить к каждому ребенку.

Помимо А.В. Бакушинского теоретическое определение, музейной педагогике дали основатели экскурсионной школы, Н.А. Гейнике, И.М. Гревс; приверженцы обширного применения в целях образования педагогических, школьных и детских музеев М.В. Новорусский, М.С. Страховой, Н.Д. Бартрам, А.У. Зеленко. Рассмотрим музейную педагогику на современном этапе ее развития. Она ориентирована на приобщение подрастающего поколения к музейному пространству и его культуре с самого раннего возраста, активизацию творческих возможностей личности, формирование многоступенчатой системы музейного образования. М. В. Соколова определяет музейную педагогику как фактор развития социального опыта дошкольников: искусство дает возможность для обогащения жизненного опыта, музей в свою очередь содействует формированию этого опыта и умений у обучаемых. Т. В. Чумалова изучает развитие ценностного отношения к культурно-историческому прошлому у дошкольников средствами музейной педагогики.

Современная музейная педагогика помимо традиционных форм выделяет, новые инновационные технологии работы с детьми старшего дошкольного возраста. Основываясь на проведенных исследованиях, можно сказать, что посещение музея дошкольниками в настоящее время зависит, непосредственно, от стремления и желания педагога, уровня его специальной художественно-эстетической подготовки. Академик Д. С. Лихачев акцентировал внимание, на том, что культура держится на трех китах: музеях, архивах, библиотеках. Художественно-эстетическое воспитание средствами музейной педагогики не должно сводиться только к наглядным показом экспонатов.

Одной из самых важных задач сегодняшнего музея считается его просветительское образовательно-воспитательное влияние на самые обширные массы, в особенности на молодежь, и в частности дошкольников. Поэтому, разрабатывая систему мероприятий в рамках музейной педагогики, нужно обратить внимание на проблему взаимосвязи музея с системой художественного образования и, в частности, на музее как средстве формирования художественно-эстетической культуры дошкольников.

3.Мортазин М.Г.150 атаклы татар турында. Кызык та, кызганыч та: Публицистик язмалар. Казан.«Мәгариф-Вакыт”нәшр, 2002.2384б:фото-рәсемнәр белән.

4.Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р..Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII– начало XX веков).-Казань:изд-во “Фест”,1994-с.71-72,170-172

5.[Электронный ресурс] Сайт Википедия http//atnya.tatarstan.ru/rus about. htm (дата обращения 14.01.2023)

6. .[Электронный ресурс] Большая Атня/Команда кочующие и Марийские Лесхозы.komanda-k.ru (дата обращения 18.01.2023)

7. .[Электронный ресурс] Большая Атня.: Татарская энциклопедия Tatarica tatarica.org (дата обращения 18.01.2023)

8. .[Электронный ресурс] История района.atnya.tatarstan.ru(дата обращения 04.02.2023)

9. .[Электронный ресурс] История села Большая Атня.nailtimler.com (дата обращения 08.02.2023)

Камалетдинова Р.Г.
г. Арск, МБДОУ «Арский детский сад №5»,
воспитатель

# БЕЛЕМ ДӨНЬЯСЫНЫҢ ЧИШМӘ БАШЫ – "ӘЛИФБА"

**Аннотация:** В статье покзано, что “Алифба” является первым помощником в обучении детей чтению на родном языке и источником нравственного воспитания детей и формирования личности человека. “Алифба”, созданная педагогами С. Г. Вагизовым и Р. Г. Валитовой, является культурным наследием татарского напрода, что подверждается богатым материалом, собранным в музее “Алифба” . Посещение музея зарубежными гостями свидетельствует о большом интересе к трудам С. Г. Вагизова и Р. Г. Валитовой.

**Ключевые слова:** С. Г. Вагизов, Арча педагогия көллияте, музей, “Әлифба”, экспонатлар, белем.

**Abstract:** The article states that “Alifba” is the first assistant in teaching children to read in their native language and a source of moral education of children and the formation of a person's personality. "Alifba", created by teachers S. G. Vagizov and R. G. Valitova, is the cultural heritage of the Tatar people, which is confirmed by the rich material collected in the museum “Alifba”. Visiting the museum by foreign guests indicates a great interest in the works of S. G. Vagizov and R. G. Valitova.

Key words: S. G. Vagizova, Arsky Pedagogical College, museum, “ABC", exhibits, knowledge.

Әлифба", "Әлифба",
Син - минем юл башым.
Син-белем илендә,
Иң якты кояшым.

Разил Вәлиев

Мәкаләне атаклы татар язучысы, җәмгыять эшлеклесе Разил Вәлиев сүзләре белән башлап җибәрергә уйладым. Чөнки, күңелдә туган фикерләрне, уй-кичерешләрне бөтен тирәнлеге белән, аңлаешлы итеп әйтеп бирүдә туган телебезнең мөмкинчелеге чиксез. Ана телендә әкиятләр тыңлап, шигырьләр сөйләп үскән һәр баланың теләге - укырга, язарга өйрәнү. Ә туган телендә укырга, язарга өйрәтүдә беренче ярдәмче ул - Әлифба - һәр бала кулында кадерле китап.

1960 нчы елларда яңа дәреслекләр төзү ихтыяҗы туа. Мәгариф министрлыгы яңа дәреслекләр төзү буенча конкурс игълан итә. Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары С.Г.Вәгыйзов, аның тормыш иптәше Р.Г.Вәлитова конкурсантлар исемлегенә керәләр. Аларның "Әлифба" китабы иң яхшы дип табыла һәм дәреслек итеп бастыруга тәкъдим ителә. Шул көннән башлап бу фидакәр укытучылар дәреслекләр төзү белән шөгыльләнә башлыйлар. Беренче "Әлифба" лары 1965нче елда басылып чыга. Шуннан

башлап "Әлифба" ел саен меңәрләгән тираж белән чыга, тулылана, төзәтмәләр керә, камилләшә бара. Алар 6 яшьлекләр, өчьелык, дүртьеллык башлангыч мәктәпләр өчен "Әлифба", "Рәсемле Әлифба"лар язалар. Аларның иҗаты башлангыч класслар өчен дәреслекләр һәм методик күрсәтмәләр, китаплар язу белән давам итә. С.Г. Вагыйзов үзе болай дип сөйләгән: "Шушы бәрәкәтле гомеребезне, дан-шөһрәт, дәрәҗә, байлык артыннан кумыйча, игелекле хезмәткә - халык мәгарифе эшенә, дәреслекләр, "Әлифба" язуга багышладык. Кыйблабыз бер булды. Милләтебез яшәсен, халыкка файда китерик, дип без яхшы дәреслекләр язарга тырыштык. Дәреслек – иң кирәкле китап ул. Дәреслек булганда - китап яши, китап булса - милләт яши."

Татарстанның мәгариф министры булып эшләгән Харисов Ф.Ф теләге һәм күрсәтмәсе нигезендә Арча педагогия колледжда "Әлифба" музее төзү башлана. Моның төп нигезе һәм кирәклеге бу колледжда эшләгән һәм Арчада яшәүче татарларның хәзерге чор "Әлифба" авторларының зур иҗат нәтиҗәләре булды.

Аларның иҗаты һәм дөнья халыкларының әлифбалары коллекциясенә таянып "Әлифба" музеена нигез салына. Вагыйзов С.Г.ның 90 еллык юбилее 1998 елның 20 октябрендә билгеләп үтелә. Ә инде 1999 елның 6 октябрендә "Әлифба" музеен ачу тантанасы үтә.

Арча педагогия көллияте бинасында урнашкан дөньяда бердәнбер уникаль "Әлифба" музеенда "Әлифба" китабы төп урынны алып тора. Бу музей үзләренең бөтен гомерләрен халыкка, хезмәткә багышлаган, 40 елдан артык Арча педагогия көллиятендә эшләп, меңнәрчә укытучылар хәзерләшкән, К.Д.Ушинский исемендәге премия (С.В.Вагыйзов), Каюм Насыйри исемендәге премия лауреатлары, Татарстанның атказанган укытучылары, Россия Федерациясенең халык мәгариф отличниклары, Һ.Максуди, М.Корбангалиев, Һ.Сафиуллинарның традицияләрен дәвам иттереп, кеше тормышында иң изге китап "Әлифба" һәм 40 тан артык методик,фәнни хезмәтләр авторлары С.Г.Вәгыйзов һәм Р.Г.Вәлитоваларның якты истәлегенә багышлана.

"Әлифба" музее күп экспонатлар белән баетылган. Монда 210 милләтнең 1 класс дәреслеге - "Әлифба"лар җыелган.

Аеруча зур игътибар татар "Әлифба"лары тарихына бирелә. Татарлар мең ел буена "Иман шарты" белән укыйлар. (1000 ел - IX гасырлардан 1928 елга кадәр). "Иман шарты - әллепи - әлифба" уку-язуга өйрәтү генә түгел, ә әхлак кагыйдәләрен үзләштерүдә, XY1П-X1X гасырларда татар язуы һәм әлифбалары яңарыш кичерә: гарәп алфавиты галдиләштерелә, укыту ысуллары үзгәрә. Бу авторлар арасында Сагыйт Хәлфин, К.Насыйри, Х.Вәдыйгов, Х.Максуди, Ш.Тахири һ.б. Иң күренекле авторларның берсе Х.Максуди, аның "Әлифба"сы бүген дә мәдрәсәләрдә тәп дәреслек булып тора.

Музейның үзәк экспонатларыннан Әхмәтһади Максудиның "Татарстан әлифбасы": "Мөгаллим әүвәл". Бу кулъязма Ә.Максудиның үз кулы белән төзелеп, тел галиме Х.Курбатов тарафыннан "Бөек зат Һади Максудиның бу кулъязмасы бүгеннән Рәмзия ханым белән Сәләй туган милкенә күчә. Хәлиф

Курбатов. Казан. 1997 ел 12 март" дигән язу белән соңгы 40 ел эчендә татар әлифбаларын төзүчеләр Р.Вәлитова С.Вагыйзовларга тапшырыла.

1928 елда гарәп графикасыннан "Яңалиф"кә күчү була. "Яңалиф" латин алфавитына нигезләнә. Ә инде 1938 елда безнең "Әлифба" рус графикасына нигезләнә.

Ә "Әлифба" музееның төп өлешен Сәләй Гата улы Вәгыйзов һәм Рәмзия Гыйләж кызы Вәлитованың педагогик һәм иҗат эшләре тәшкил итә. "Әлифба" музее язу тарихына да шактый урын бирә. Монда идеографик язудан аваз хәрефләренә күчү күрсәтелә. Грек, латин, рус, татар, алфавитларының килеп чыгу юллары ачыклана. Музейда 400 гә якын дөнья халыкларының әлифбалары бар. Беренче алфавитларның килеп чыгышы турында кызыклы мәгълүмәтләр дә тупланган һәм төрле халыкларның идеографик язу үрнәкләре дә бирелгән монда. Кайсы телдә ничә хәреф барлыгын белү дә кызыклы. Латин графикасында 26, грекларда 28, Индонезиядә яшәүче бер кабилә өчен 12 хәреф тә җитеп ашкан. Кытайда исә 25 меңнән артые иероглиф бар, урта мәктәптә аларның 300 генә өйрәнелә икән.

Музейда Төркиядән, Финляндиядән, Америкадан, Англиядән, Германиядән, Франциядән, Кытайдан, Кореядан, Белоруссиядән, Украинадан, Башкортстаннан, Кыргызстаннан, Кырымнан, Ингушетиядән һәм башка илләрдән килгән туристлар һәм делегацияләр булдылар. Чит илдән килүчеләрдә музей бик нык кызыксыну тудыра. Музей заллары ел әйләнәсе буш тормый. Музей диварларына хәтта милләте буенча татар булмаган АКШ кунаклары да килде. Әлифба авторларының шәкертләре дә музейның еш кунаклары. Чыгарылыш сыйныф укучылары һәм студентлар белән очрашулар да оештырыла монда. Алар укытучылар турында истәлекләре белән уртаклашалар. Музей хезмәткәрләре мәктәпкәчә яшьтәге балаларны да шатланып каршы алалар. Балаларның игътибарын җәлеп итә торган экспонатлар бик күп бирелдә. Кечкенә булсалар да аларның һәркайсы кадерле, кирәкле икәнлеген аңлый балалар. Аңлаешлы телдә музей хакында кызыклы мәгълүмәтләр бирәләр.

Гомумән "Әлифба" музее зур рухи байлык чыганагы булып тора һәм татар халкының рухи потенциалын нигезли…

Бүгенге көндә яңа, көн таләпләренә туры килә торган әлифбалар язылып тора. Ул шулай булырга тиеш тә. Әмма, ярты гасырга якын балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләүнең, кеше шәхесенең формалашуының чишмә башы булып торган Сәләй Гата улы Вагыйзов һәм Рәмзия Гыйлаж кызы Вәлитова язган "Әлифба" китабы үзенең әһәмиятен беркайчан да югалтмас. Педагогия көллияте каршында "Әлифба"га куелган һәйкәл моңа дәлил булып тора.

Мин халыкның ихтирамын казанган һәм рәхмәтен яулаган бу изге, олуг затларның рухлары тыныч һәм шат булсын дип, һәйкәл алдында баш иям.

Еллар үтте, үсеп җиттек,

Ерабыз без тормыш сукмагын.

Тик һаман да таба алмадым мин

"Әлифба"дай тормыш китабын.

Кулланылган чыганак
1. Камалетдинова С.С. “Мәгариф маяклары"- Арча педагогия көллияте, 2005, 46 бит.
2. Сәгъдиев И. А. "Мәгариф” журналы, 1998.
3. Сибгатуллина Рәсимә “Мәдәни җомга” 2000. Интернет ресурс: https://arsk.tatarstan.ru/index.htm/news/1604028.htm (Мөрәҗәгать итү датасы: 13.10.2023)

Камалова Г.И.
МБОУ “Старочурилинская средняя общеобразовательная школа”,
учитель начальных классов

БЕРДӘНБЕР “ӘЛИФБА” МУЗЕЕ

**Аннотация:** В статье специального корреспондента газеты “Ватаным Татарстан” Александр Филипов рассказывает об истории создания музея “Алифба”, посвященного его открытию.Автор статьи пишет о том, что первые учебники носили название (Иман шарты).В конце 19 в начале 20 веков Каюм Насыри вводит изменения арабскому алфавиту, используя закономерности татарского языка. До появления учебника “Алифба”С.Вагизова и Р.Валитовой были учебники, написанные латинской графикой. В 1965 году эти авторы внесли огромный вклад в образовательный процесс татарского языка, издав в учебник “Алифба” для начальных классов. Также Р.Валитова и С.Вагизов разработали методические пособия для учителей начальных классов. В музее “Алифба” мы можем увидеть образцы “Алифба”, написанные на арабском, латинском и других языках.

**Ключевые слова:** “Музей Алифба”, авторы учебника С.Вагизов, Р.Валитова,Арский педагогический колледж, методические пособия.

Арча педагогия көллиятендә Татарстан һәм Россиядә генә тугел, ә дөньяда беренче тапкыр “Әлифба” музее ачылды. Дөресрәге, моны дөнья халыклары хәреф сәнгате музее дип эйтергә дә мөмкин булыр иде. Анда әле хәзергә элекке СССР территориясендә яшәгән 102 халыкның төрле чорларда бастырып чыгарылган 500 дән артык “Әлифба” китабы ( әлбәттә, алар төрле телдә төрлечә атала) тупланган. Музей ачылу уңаеннан көллияттә бәйрәм тантанасы булды. Аны педагогия көллияте директоры Илдус Сәгъдиев башлап җибәрде. Аның чыгышыннан аңлашылганча, Татарстан Мәгариф министрлыгының “Әлифба” музеен нәкъ менә Арча педагогия көллиятендә оештыру турында беренче сүз моннан бер ел элек Арчада “Мәгариф музее” ачуга республика мәгариф министры Фарис Харисов килгәч булган икән. Хакимият башлыгы Илһам Сабиров та, көллият укытучылары да, бу башлангычны күтәреп алып, зур эшкә керешәләр. Ә мондый музей оештыру идеясенең сәбәпчеләре биредә 40 елга

якын татар балаларын белем дөньясына алып кергән “Әлифба” авторлары – ирле-хатынлы Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вәгыйзов.

Татарстан мәгариф министры Фарис Харисов та музейны ачканда ясаган чыгышында тантанада катнашучы “Әлифба” авторларына иң җылы сүзләрен җиткерде. “Әлифба” авторлары безнең алда утыра, - диде ул. Алар 60 елдан артык инде татар мәгарифен үстерүгә хезмәт итәләр. Бу, бер яктан, Сәләй ага белән Рәмзия апаның хезмәтләрен мәңгеләштерүнең күркәм күренеше булса, икенче яктан, “Әлифба” белән эшләүче укытучылар өчен зур методик үзәк тә булып торачак.

Яңа музей ачылганда район хакимияте башлыгы Илһам Сабиров та үзенең дулкынлануын яшермәде.

-Арча ягы үзенең бөек мәгърифәтчеләре, күренекле язучылары, сәнгать эшлеклеләре, тырыш һәм эш сөючән мәгърифәтле халкы белән данлыклы, - диде ул. –Арчаның 1000 еллык тарихы һәм үзенә генә хас йөзе бар. Арчалылар үз тарихларын онытмыйлар. Бөек якташыбыз Габдулла Тукай үзенең чагылышын Кушлавыч авылындагы музей – йортында һәм Яңа Кырлай авылындагы мемориальүзәктә тапты. Бөек мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәсигә багышланган музей Күлтәс авылында әле яңа гына эшли башлады. Гөберчәк авылында якташыбыз Мөхәммәт Мәһдиевкә музей әзләнеп бетеп ята. Узган ел Арчада беренчеләрдән булып мәгърифәт музее ачылды. Татарстанда бердәнбер әдәбият һәм сәнгатьмузее да Арчада эшли.

Ветеран укытучы, “Әлифба” авторы Сәләй ага Вәгыйзов белем ачкычы булган беренче китапны зурлап музей оештыручыларга үзенең иң җылы рәхмәтләрен җиткерә.

Музейга керү юлына сузылган ал тасманы Татарстан мәгариф министры Фарис Харисов, район хакимият башлыгы Илһам сабиров һәм көллият директоры Илдус Сәгьдиев кисте. Тамашачыны икенче каттагы музейга менеп җиткәнче татар халкына 1000 ел буе мәгърифәт нуры иңдергән, Көнчыгыш бизәкләре белән эшләнгән гарәп графикасы хәрефләре озатып бара.

Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән иң беренче әлифбалар “Иман шарты” дип йөртелгән. Ул озак гасырлар буе үзгәрешсез кулланылган. Биредә аның узган гасырларда кулланышта йөргән нөсхәсе урнаштырылган. “Иман шарты”, әлифба булудан тыш, иманга, намуска, әхлакка өйрәтү китабы да булган.

XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында татар мәгарифендә яңарыш проөессы башлана. Шунлыктан гарәп алфавитын татар теле закончалыкларына туры китереп эшкәртү кереп китә. Аның иң беренчеләрдән булып Каюм Насыйри башлый һәм 1895 елда басылган “Әнмүзәҗ” дигән китабында, аваздан хәрефкә барып, татар телендә 10 сузык аваз булуын ачыклый һәм аларны белдерү өчен хәрефләр тәкъдим итә. “Әлифба” музеенда бу да чагылыш тапкан.

Музейда Әхмәтһади Максуди (1867- 1941) иҗаты зур урын алып тора. Ул татар имлясын камилләштерүгә зур өлеш керткән. Биредә аның үз кулы белән язылган “Татарстан әлифбасы” : “Мөгаллим әүвәл” урнаштырылган. Бу кульязма Ә.Максудиның үз кулы белән төзелеп, тел галиме Х.Курбатов тарафыннан “Бөек зат Һади Максудиның бу кульязмасы бүгеннән Рәмзия ханым белән Сәләй туган

милкенә күчә. Хәлиф Курбатов. Казан. 1997 ел,12 март”дигән язу белән татар әлифбаларын төзүчеләр Р. Вәлитова һәм С. Вәгыйзовка тапшырыла. Шулай итеп, бу кыйммәтле кулъязма музей экспонатына әверелә. Әхмәтһади Максуди әлифбаларының 50 дән артык басмасы бар.

XX гасыр башында гарәп язуы нигезендә Х. Зәбири, Г.Нугайбәк, Г.Әхмәров, Г.Алпаров, Н.Думави,Х.Гали, Г.Ибраһимов әлифбалары да дөнья күрә. 1928 елда бу әлифбаны камилләштерү процессы тукталып, латин графикасы унъеллыгы башлана. Латин графикасы нигезендәге беренче әлифбаны Г.Нугайбәк белән М.Корбангалиев төзи. Ул елларда балалар, өлкәннәр, эшчеләр, крестьяннар өчен аерым- аерым әлифбалар эшләнә.

1939 елда татар язуын кириллицага күчергәч, беренче татар әлифбасын Мөхетдин Корбангалиев һәм Габбас Сәйфуллин төзи. Бу әлифба 1964 елга кадәр хезмәт итә.

1965 елдан Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вәгыйзов чоры башлана. Бу әлифба бүген дә үз эшен башкара. Алар бу чор эчендә башлангыч сыйныфлар өчен 40 тан артык методик хезмәт төзеп, бастырып чыгаралар.

Татар әлифбасының XIX гасыр азагы һәм XX гасыр чорын чагылдырган бүлмәсендә бер почмакта данлыклы Кышкар авылы мәдрәсәсе, икенче почмактаилленче еллар мәктәбенең башлангыч сыйныф, ә өченче почмакта Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вәгыйзовның эш бүлмәсе күренешләре бирелгән. Чал чәчле “Әлифба” авторлары, үзләренең музейга күчерелгән эш өстәле янындагы урындыкларга утырып, көллияттә үткән елларын, әлифба төзү, методик материаллар язу мәшәкатьләрен искә төшерделәр.

Икенче бер бүлмәдә дөньяхалыклары әлифбалары һәм язу үрнәкләре тупланган.Алар арасында Иван Федоровның 1574 елда эшләп бастырган букваре “Азбука”да бар.Бу, әлбәттә, аның күчермәсе. Төп нөсхәсе Американың Гарвард университетында саклана икән.

Шулай итеп, Арча педагогия көллиятендә оештырылган музейда без борынгы идиографик язмалардан башлап безнең эрага кадәр X гасырда кулланышта булган грек, латин, гарәп һәм башка күп төрле алфавитлар белән дә таныша алабыз.

Музейга тупланган бай материалны җыюда һәм урнаштыруда көллиятнең тарих укытучысы Хөсәен Хәйруллин, Татарстан Берләштерелгән дәүләт музее фәнни хезмәткәрләре Р.Абзалина һәм О.Гасыймов күп көч куйганнар.

Мухаметшина Э.Г.
Ахметзянова Э.Г.
МБОУ «Качелинская ООШ»

# МИЛЛИ МӘКТӘПТӘ УКЫТУ-ТӘРБИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ “ТУГАН ЯК”МУЗЕЕНЫҢ РОЛЕ

**Аннотация:** В статье рассматриваются история становления и развития музейной педагогики, проблемы её современного состояния. Характеризуются формы взаимодействия музея и школы, организуемые в рамках музейно-педагогического процесса.

**Ключевые слова:** культурно-образовательная среда, музейная педагогика, музейно-педагогическая программа, формы взаимодействия музея и школы, музейно-педагогический процесс.

Гадәттә, музейларны кешелек тарихының бәяләп бетергесез кыйммәтле ярдкарьләре тупланган серле сандык белән чагыштыралар. Бәлки, монда билгеле дәрәҗәдә хаклык та бардыр. Чөнки безнең әби-бабаларыбыз да үз нәселләре өчен истәлекле, кадерле, борынгы әйберләрен сандыкта саклаган. Аны һәр буын үзенчә яңартып, тулыландырып торган. Әби-бабайлар, еллар үткәч, әлеге сандыкны ачып, оныкларына бик үзенчәлекле тәрбия дәресләре үткәргән, сандыктагы әйберләрне җанлы образ буларак сурәтләгән, тарихлары белән таныштырган. Мондый “дәрес”тән соң кайсы гына бала борынгы бабалары белән горурланмас икән? Озак еллар дәвамында музей залларына тупланган экспонатлар белән танышкач та, шундый ук халәт кичерәсең. Туган төбәкнең борынгы тарихы, аның гүзәл табигате искиткеч талантлы, кызыклы язмышлы кешеләре, табигый байлыклары сине үзенә әсир итә.

Музейларны мәдәни һәйкәлләрнең бәя биреп бетергесез келәте дип атаучылар да бар. Әлбәттә инде, биредә төп геройлар – экспонатлар. Әмма экспонатлар «терелсен», төрле чорларның кызыклы вакыйгалары белән бирегә килүчеләрне таныштыра алсын өчен музей хезмәткәрләренә күп көч куярга туры килә.

Гадәттә, без музейларга теге яки бу тармак буенча белем хәзинәбезне арттыру, тулыландыру, күбрәк белү, нәрсәнедер ачыклау, кешелек дөньясы тудырган казанышлар белән якыннан танышу өчен киләбез. Музей – тарихи җәүһәрләрне барлау, аларның иң мөһимнәрен сайлау, туплау, киләсе буыннар өчен югалтмыйча саклау урыны да. Музей ул – һәрберебезнең дөньяга карашын формалаштыруга, баетуга ярдәм итә торган үзенчәлекле дөнья.

Музейлар элек-электән яшь буынга рухи, патриотик, эстетик һәм хезмәт тәрбиясе бирү вазифасын да үти. Киң карашлы, үз эшенә нык бирелгән педагоглар укучыларын музейга еш алып киләләр. Балаларны халкыбыз тарихы, рухи казанышлары, милли үзенчәлекләре, йолалары, тормыш-көнкүрешенә

кагылышлы экспонатлар белән таныштыралар. Мондый чаралар еш кына чын мәгънәсендә тормыш дәресләренә, дөньяны танып белү дәресләренә әверелә, хәтергә берегеп кала.

Кунаклар да, яңа урынга аяк басуга, музейларга кереп чыгу, бу төбәккә кагылышлы экспонатлар белән танышу мөмкинлеген кулдан ычкындырмаска тырыша. Чөнки шушы бер бинада булу гына да җирле халыкның тарихын, бүгенгесен ачыграк аңлау өчен искиткеч бай мәгълүмат бирә.

Музейлар барлыкка килгәндә, аларның максатын тарихыбызга бәйле мирасны саклау һәм халыкка күрсәтү дип аңлаганнар. Әлбәттә, тормышның һәр тарихи этабында күп нәрсә, шул исәптән, максатлар да алмашына. Әмма музейларның әһәмияте, тоткан юнәлеше үзгәрми. Төп игътибар һаман да үткәннәребезнең кадерле ядкарьләре булган рухи мирасны саклау, халыкка күрсәтүгә юнәлдерелә. Фондка тупланган экспонатларны музейга килүчеләргә алар аңларлык, белем дә, мәгълүмат та табарлык, кирәк икән, хезмәтләрендә кулланырлык, хәтта кәефләрен күтәреп җибәрерлек итеп күрсәтү мөһим. Әйтик, сәнгать музейларына килүчеләр андагы экспозицияләрне ләззәтләнеп карап йөри, шул ук вакытта аларга соклана, шатлана, кайвакыт нәфрәтләнә дә.

Гражданнарның мәдәният учреждениеләреннән файдалану һәм мәдәни кыйммәтләр белән танышуга Конституция биргән хокукларын тәэмин итү бүген дә музейлар һәм музей тыюлыклар эшчәнлегенең төп бурычы булып тора. Әлеге учреждениеләр гражданнарны патриотик тәрбияләү, милли мәдәниятләрне саклау, үстерү вазифаларын да башкара.

Татарстанда бүгенге көндә йөздән артык дәүләт һәм муниципаль музей эшли. Аларда 1,5 миллион чамасы экспонат саклана, диләр. Музейлар челтәре, фондларның гомуми күләме буенча Татарстан Россиядә иң алдынгы саналган Мәскәү шәһәре, Ленинград һәм Свердловск өлкәләреннән генә калыша. Идел буе федераль округында ул иң алдынгы булып исәпләнә. Бер ел эчендә генә дә республика музейларын 1 миллион 628 мең кеше караган.

Тарихтан күренгәнчә, музейларны оештыруда меценатлык зур роль уйнаган. 2015 елның 5 апрелендә үзенең 120 еллыгын билгеләп үткән Татарстан Милли музеен оештыруга да Казан коллекционеры Андрей Фёдорович Лихачёв тупламасы нигез булып тора. 1890 елда абыйсы үлгәч, энесе вице-адмирал Иван Фёдорович аның хатыныннан барлык коллекцияне сатып ала һәм шәһәргә бүләк итә. Коллекциядә 20 меңләп вак акча һәм медальләр була. Тарих фәннәре докторы, Татарстан Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипованың әйтүенә караганда, хәтер мәгарәсенә уникаль экспонатлар китерүчеләр бүген дә бар икән. Әле күптән түгел генә бер татар егете 1847 елгы рәсемнәрне Боратынский музеена алып килгән. Ул аларны, антиквариат кибетендә күреп, үз акчасына сатып алган булган. Бу ядкарьләр яңа экспозициядә күрсәтеләчәк. Андый рәсемнәр башка бер генә музейда да юк икән. Танылган галим Марсель Әхмәтҗанов 1000 данәгә якын тарихи материаллар алып килеп, бушлай тапшырган. Шундый кешеләр бик күп икән.

Татарстан Республикасының һөнәрчеләр академиясе төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе Дамир Гыйбадуллин карашынча, соңгы вакытта

эшкуарлар борынгы технологияләрне торгызу буенча музейлар белән эшли башлаган. Һөнәрчеләр теге яки бу товарны җитештерүнең борынгы технологиясен өйрәнәләр, аларны сувенирлар җитештерүдә киң кулланалар. Андый сувенирлар туристларның игътибарын күбрәк җәлеп итә.

Чыннан да, безнең Арча районы – музейлар ягы. Районда республиканың бердәнбер Әдәбият һәм сәнгать музее, Габдулла Тукайның мемориаль комплексы, Тукаевлар гаиләсенең Кушлавыч авылындагы музей-усадьбасы, дөньядагы бердәнбер Әлифба музее, язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең туган җире Гөберчәктәге музее, Арчада Халык мәгарифе музее эшли. Райондагы тагын ике музей игътибарны җәлеп итә: Үрнәк бистәсендәге Табигать музее, кайберәүләр аны Агач әйберләр музее дип тә йөртә. Аның рәсми исеме – Арча урман хуҗалыгының тарих музее. Икенчесе – Сунар урманчылыгындагы урман җәнлекләре һәм үсемлекләре музее. Мәктәпләр каршындагы туган якны өйрәнү, күренекле якташларыбызга багышланган музейларга да халык бик яратып йөри. Алар районның һәр авылында диярлек бар. Кайберләрендә хәтта дәүләт музейлары хезмәткәрләрендә кызыксыну уятырлык экспонатларны очратырга була.

Безнең Кәче төп гомумбелем мәктәбендә дә бик бай “Туган якны өйрәнү” музее эшләп килә. Һәр мәктәптә диярлек туган төбәкне өйрәнү музейлары бар. Алар укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре, туган як тарихына, тормыш-көнкүрешенә кызыксыну, халыкның үткәненә, гореф-гадәтләренә хөрмәт уятуга этәргеч булып тора.

Музей... Монда нәрсә генә юк! Укучылар музейны тулыландыру максатыннан аерым кешеләрдән, шәхси коллекционерлардан тарихи әйберләр, истәлекле язмалар җыйдылар. Күптөрле һәм эчтәлекле экспозицияләр укучыларга туган төбәкнең үткәнен өйрәнергә; халкыбызның гореф-гадәтләренә, матур традицияләренә ихтирам тәрбияләүдә, тарихның төрле чорларында туган төбәгебез үсешенә зур хезмәт куйган шәхесләребез, Бөек Ватан сугышы каһарманнары, оешмалар турында күбрәк белергә ярдәм итәләр.

Музей эшчәнлегендә туган ил тарихын өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Укучылар өчен музейда үткәрелгән класс сәгатьләре балаларга бай тарихи мәгълүмат бирә, тарихи вакыйгаларны аңларга ярдәм итә, илебез тарихына кызыксыну уята. Татар халкы тарихын өйрәнүдә музейда саклаучы иске кулъязмалар, болгар чоры тарихын чагылдырган экспонатлар, фоторәсемнәр, китаплар белем һәм тәрбия бирүдә зур әһәмияткә ия.

Музей үз эшчәнлеген күпкырлы юнәлештә алып бара, 5 бүлектән тора:

1. Кәче авылы тарихы.
2. Авылдашлар Бөек Ватан сугышы чорында.
3. Этнография.
4. Мәктәп тарихы.
5. Махсус хәрби операциядә катнашкан авылдашларыбызга багышланган почмак.

Музейның беренче бүлегендә төп урынны туган төбәгебездән чыккан шәхесләребезгә, вакыйгаларга, колхоз оешмасына багышлаган хезмәтләр алып

тора. Стендларда туган ягыбызның тарихын чагылдырган фотосурәтләр, язмалар чагыла.

Этнография бүлегендә 19 гасыр ахырында яшәгән авыл кешесенең тормышы күрсәтелә. Нәрсә генә юк монда: иске патефон, агачтан ясалган бала арбасы, чигелгән, тегелгән күлмәк-сөлгеләр, әби-бабаларыбыз кулланган эш кораллары, көмештән эшләнгән алка-беләзекләр, иске язу машиналары, авыл тарихын яктыртучы язма-документаль мәкаләләр, материаллар, тимер һәм кәгазь акчалар, иске бизмән, күкеле сәгать, самовар, чуен үтүк, чабаталар.

Музейның мәктәп тарихына багышланган бүлегендә мәктәпнең 91 еллык тарихын чагылдырган материаллар тупланган. Монда без күп кенә альбомнар белән таныша алабыз.

Музейда патриотик тәрбия юнәлеше

Хәзерге заманда үз илен, туган телен, үз туган ягын яратучы яшьләр азаеп бара. Һәр кеше үзен генә кайгыртып яши. Кайда яши, янәшәдә кемнәр бар, алар нишлиләр – монысы аны борчымый. Яшь буынга “монысы - яхшы, ә монысы - начар” дип кенә бернәрсә дә аңлатып булмый. Алар үз күзләре белән күрергә, анализларга тиештер, мөгаен. Патриотик тәрбия дигәндә мин үзем Туган җирне, Туган илеңне, эти-әниеңне ярату хисе, дип аңлыйм. Мәктәпләрдә тормыш иминлеге нигезләре дәресләре аша укучыларга патриотик тәрбия бирелә. Моның өчен белем учакларында тиешле шартлар тудырылган, укулар үзе үк тәрбиягә юнәлтелгән. Әмма хәзерге буын яшьләрнең Ватанга, өлкән буынга карата карашлары сүлпән диясем килә. Патриотик хис туган туфрак, агач, үлән, чишмә буйларыннан, эти-әниең, гаиләңнән башлана һәм ул бала туган көннән башлап гаиләдә тәрбияләнә. Үзен яраттыра алган ата-ана баласында да туган теленә, туган иленә карата да хөрмәт тәрбияли ала. Бала укырга кергәч, ул мәктәптә дәвам итә.

Туган тел! Туган ил! Бу сузләр эчендә әйтеп бетергесез мәгънә ята. Алар һәрбер кеше тарафыннан зур горурлану белән әйтелә. Туган илеңә, Ватаныңа хезмәт итү, буыннар арасындагы бәйләнеш, үткәндәге батырлыкларның киләчәк белән ялгануы, бүгенге көндә дә безнең иминлегебез өчен кайгырту... Бу сүзләр бүген дә бик актуаль яңгырый. Туган илебезнең иреген көрәшләрдә яклаган бабаларыбызга, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм хәрби көчләр, ветераннарга мәңгелек дан җырлана. Алар җиребезне генә түгел, ә Ватаныбыз традицияләрен, бабаларыбыз васыятен, тугрылык һәм югары әхлакый кануннарны саклап калдылар. Халкыбыз Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Әфганстан дәһшәте аша үткәннәргә, кайнар нокталарда булып, зур сынау юлы узганнарга, һәм бүгенге көндә дә махсус хәрби операция хезмәтендә безнең иминлегебез сагында торучыларга ихлас соклана.

Яшь буынга патриотик тәрбия бирүдә музейларны “җанлы тарих” дип йөртәләр. Мәктәп музейларының балаларны туган илебезне сөюче чын гражданнар итеп тәрбияләүдә булган мөмкинчелекләре искиткеч зур.

Музейның һәр бүлеге һәм андагы һәр экспонат, экскурсоводларның мавыктыргыч сөйләме бала күңеленә үтеп кереп, тирән эз калдыра. Музей

эшчәнлеге аша балалар күңелендә туган якты хисләр, һичшиксез, аларны чын патриотлар итә.

Мәктәп музеен бизәгәндә аның эстетик зәвыклыгына зур игътибар бирелгән. Һәр бүлектәге стендлар, стенага ясалган рәсемнәр эчтәлеге һәм матурлыгы белән балаларны үзенә җәлеп итә. Күргәзмәләрдәге әби-бабалардан буыннан-буынга күчеп килгән әйберләрнең кадерләп саклануын күреп, без туган төбәгебезгә һәм аның халкына тагын да зур хөрмәт белән карыйбыз.

Балаларга патриотик тәрбия бирүдә музейның “Авыл Бөек Ватан сугышы елларында” дип исемләнгән бүлеге бигрәк кадерле. Музейның бу бүлегендә куп кенә экспонатлар тупланган. Алар арасында фронттан килгән солдат хатлары, сугыш еллары фоторәсемнәре һәм иң кадерлесе – фронтовик якташларыбызның хатирәләре саклана.

Музейда уздырылган һәр чара (экскурсия, дәрес, батырлык дәресләре, сугыш ветераннары белән уздырылган кичәләр) зур тәрбияви һәм танып-белү үзенчәлегенә ия. Шуңа күрә укучылар бу бүлектә уздырылган һәрбер чараны йотлыгып тыңлыйлар. Җиңү бәйрәме кичәләренә әзерләнгәндә укучылар үзләре теләп катнашалар.

Музейларның әһәмияте нидә соң? Бу сорауга җавапны ерактан эзлисе юк. Мәктәп музее тик тормый, ул һаман саен үзенең байлыгы белән уртаклаша. Дәресләрдә, класс сәгатьләрендә музей экспонатлары киң кулланыш таба. Укучылар музейдагы сугыш һәм эш коралларын, милли киемнәрне, өй җиһазларын, бизәнү-ясану, көнкүреш һ.б. әйберләрне үз күзләре белән күрәләр һәм, куллары белән тотып карап, хәтерләрендә калдыралар, бабаларыбызның, әбиләребезнең тырышлыгына, осталыгына сокланалар. Туган як тарихын, мәдәниятен тирәнтен белергә теләгән укучылар өчен, түгәрәк эшли. Түгәрәк членнары предприятия-оешмалар турында, якташларыбызның хезмәт һәм сугыш батырлыкларын, тормыш сәхифәләрен өйрәнәләр, материаллар туплыйлар, альбомнар төзиләр, кызыклы очрашулар уздыралар. Мондый эш башкару укучыларда патриотлык хисе тәрбияли, туган як тарихы, халкы белән кызыксыну уята.

Туган якны өйрәнүдә IT- технологияләр куллану, укучыларны кызыксындыру, музей экспонатлары белән тирәнтен таныштыру максатыннан музейның үз сайты булдырылды. Һәр экспонатка беркетелгән куар-кодлар аша экспонат белән якыннанрак танышырга мөмкин. Музей экспонатларын куар-кодлаштыру туган якны өйрәтүдә заманча адымнарның берсе булып тора.

Укучылар өчен, мәктәптә узган район укытучылары семинарлары, очрашулар вакытында экскурсоводларның музейдагы экспозицияләр, анда тупланган экспонатлар, материаллар турында чыгышлары тыңлаучыларда туган төбәк – Кәче тарихына кызыксынуны көчәйтә, үз халкы белән горурлану хисе тәрбияли. Мондый чаралар балаларда туган ягының хезмәт сөючән халкына хөрмәт һәм ихтирам тәрбияли.

Музейда кичәләр, чаралар да үздырыла. Аларның һәркайсы халкыбызның гореф–гадәтләрен, йолаларын, буыннан-буынга күчеп килгән гүзәл

сыйфатларын үстерүгә юнәлтелгән, сыйныфтан тыш чаралар әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләренә нигезләнгән.

Музеебыз көннән-көн үсә, матурая, тарихи экспонатларга байый. Авыл халкы, укучылар бүген дә музейны истәлекле әйберләр белән тулыландырып торалар.

Музей материаллары - укучылар өчен үзе бер хәзинә. Төрле конкурслар, бәйгеләр үткәрелсә, укучылар музей материиалларын кулланалар, чөнки монда бай материал табып була. Музей материаллары кулланып эшләгән эшләр район, республика күләмендә призлы урыннар яуламый калмый. Укучылар тарих белән кызыксына икән, димәк, музейларның киләчәге бар!

Халкыбызның рухи мирасын, аның тарихын өйрәнүдә балаларга чын мәгънәсендә әхлак тәрбиясе бирүдә туган як музее эшчәнлеге әйтеп бетергесез әһәмияткә ия.

Кулланылган әдәбият

1.Мөлекова Ф.Р. Музей – тәрбия учагы. Ачык дәрес. Сентябрь,2020.
2. Җирле чыганаклар.
3.Закиров Ф.Д. ”Кәче тарихы” 2023
4. “Мәгариф” журналы. 2021-2022 еллар

Набиуллина Л.З.,
МБОУ Терсинская средняя общеобразовательная школ
Агрызского муниципального района Республики Татарстан,
учитель родного (татарского) языка и литературы и
МБУ ДО «Дом детского творчества «Радуга талантов»
Агрызского муниципального района РТ,
педагог дополнительного образования

## МУЗЕЙНАЯ ПЕДАГОГИКА В ШКОЛЕ

**Аннотация:** История страны в каждом школьном музее. Музейные предметы - неиссякаемый источник патриотического воспитания детей и сохранения исторической памяти. Бумага хрупкий материал. Цель нашего музея: сохранить документы, содержащиеся в фондах школьного музея, перевести их в цифровой формат и опубликовать в Интернете (сайт школы https://edu.tatar.ru/agryz/tersi/sch/page2888863.htm) и в виде издательских проектов. Ключевые слова: МБОУ Терсинская СОШ Агрызского муниципального района РТ, школьный музей, хранитель памяти, краеведение.
Музейная педагогика в школе

«Музей – память человечества». Именно музеям принадлежит неоценимая роль передачи интеллектуального и духовного опыта от одного поколения к другому. Я хочу отметить школьные краеведческие музее, главной задачей

которых является воспитание патриотизма, любви к своей земле. А эти чувства, в свою очередь, служат основой формирования таких нравственных качеств, как гордость за свой край, уважение к предкам и согражданам, сопричастность к судьбе своей Родины и понимания бережного отношения к её природному и культурному наследию.

В МБОУ Терсинской СОШ Агрызского муниципального района РТ функционирует «Музей краеведения». В музее два выставочных зала. В первом выставочной комнате размещены материалы историко-краеведческого цикла истории школы, во второй комнате - предметы быта и этнографии. В рекреациях школы оформлен Зал Боевой Славы: «История села и его знаменитые люди» и «Никто не забыт, ничто не забыто».

Использованию основ музейной педагогики способствуют основные направления деятельности школы:

- гражданско-патриотическое воспитание учащихся средствами музейной педагогики и системы дополнительного образования;
- развитие инициативы учащихся через органы ученического самоуправления;
- создание условий для укрепления и развития здоровья учащихся, применение здоровьесберегающих технологий в образовательном процессе.

Музейная педагогика оказывает неоценимую помощь в процессе воспитания, помогает ребенку стать творческой личностью. Школьный музей призван помочь детям открыть многообразие способов освоения культуры, сформировать устойчивую потребность общения с ее ценностями. Он позволяет использовать образовательный и воспитательный потенциал, положив в основу проектный и исследовательский методы обучения и воспитания. Здесь учащиеся занимаются поиском, хранением, изучением и систематизацией подлинных памятников истории, культуры, природы родного края, различных предметов и документов. Она стала средством творческой самореализации, является маленьким исследовательским центром по сохранению, возрождению и развитию культурноисторических традиций, участвует в диалоге поколений и культур.

Музей обладает большим образовательным потенциалом, производя отбор событий, фактов, людских судеб через функцию документирования, особенно если этой деятельностью занимаются не только взрослые, но и учащиеся 1–11-х классов. Музейные предметы – вещи, ценности – выступают в качестве источника информации о людях и событиях, способны воздействовать эмоционально, вызывать чувство сопричастности, так как позволяют проникнуть в дух прошлого, в мир творца. Так прокладывается мостик к сердцу ребенка, так формируются правильные жизненные ориентиры, происходит приобщение к вечным ценностям жизни. В этом суть музейной педагогики. Кроме того, сегодня музей становится средством приобщения человека к культурной среде и выступает противоположностью миру компьютерных технологий. Продолжая оставаться местом хранения реликвий, музей становится базой для общения, формирования нравственных ориентиров, воспитания человека высокой культуры.

Школьный музей включен в учебный процесс для осуществления наглядного метода преподавание, знакомство с действительностью, с требованиями окружающей жизни. Ведь важнейшей функцией музея наряду со сбором, изучением и хранением тематических экспонатов является деятельность, направленная на просвещение населения и популяризацию наследия, хранимого в музеях.

Самая большая ценность нашего школьного музея альбом «Хатлар ни сөйли?» (“О чем рассказывают письма”) и рукопись Сайфи Амирова **«**Рождение и краткая история Агрызской организации РКСМ**». Первое** - это архив фотографий, фронтовых писем, воспоминания фронтовиков Великой Отечественной войны, их письма пионерам нашей школы 1970-1980 годах, где воспоминание о боях, подвигах и гибели однополчан, газетные вырезки о фронтовиках. Письма еще раз заставляют вспомнить о лихолетье, заставляют переживать и задумываться об итогах и уроках былой войны… А второе, история комсомольской организации района. С 1972 года Сайфи Амиров публиковал свои статьи в районной газете «Путь победы» (“Җиңү юлы”) об истории комсомола и пионерии Агрызского района. Работа «Рождение и краткая история Агрызской организации РКСМ» хранится в нашем школьном музеи. Все материалы его исследований, являются достоверными, взятыми из архивов и периодической печати.

Музейный урок – форма музейной работы, предусматривающая коллективное углубленное изучение материала и предполагающая проверку его усвоения.Благодаря музейным урокам, обучающиеся нашей школы используют материалы для написания исследовательских работ для конкурсов и конференции : например, X Республиканская конференция исследовательских краеведческих работ «Жить, помня о корнях своих…», Республиканская научно-практическая конференция «Хроники Великой Победы»,

Межрегиональный конкурс краеведческих работ "К Звёздам!", в которых наши ученики стали призерами и финалистами. Особое воспитательное значение имеют материалы стендов, относящихся к истории Великой Отечественной войны.

Музейная среда не только стимулирует познавательные интересы учащихся, но и способствует всестороннему их развитию, а наличие подлинных музейных предметов побуждает к самостоятельному поиску информации.

*Музейная педагогика,* как одно из направлений деятельности музея, становится все более востребованной в практике духовно-нравственного, гражданско-патриотического, историко-краеведческого воспитания личности в едином образовательном процессе. Стремление к гуманитарному обновлению образования, ориентированному на сотрудничество музея и школы, составляет основу новой образовательной парадигмы XXI века.

В эпоху массового снижения нравственных ценностей необходимо воспитывать духовность, гражданственность и патриотизм через приобщение школьников к нетленным ценностям, которые хранит музей. Музейная педагогика как область научного знания, возникающая на стыке педагогики,

психологии, музееведения, искусства и краеведения, осуществляет связь прошлого с настоящим и будущим, несет в мир то лучшее, что накопило человечество.

Музейная среда стимулирует не только познавательные интересы школьников, но и способствует их всестороннему развитию, а наличие незнакомых предметов вызывает чувство удивления, побуждает к самостоятельным поискам информации. Музейная работа представляет большие возможности для того, чтобы сделать процесс обучения и воспитания школьника активным, содержательным, насыщенным познавательной деятельностью и тем самым превращает его в существенный фактор развития личности.

Активное использование музейной педагогики в образовательном процессе школы предполагает приобщить обучающихся к истокам народной национальной культуры. Способствует сохранению народных традиций.

В школе создаются все условия, способствующие всестороннему духовному, нравственному и интеллектуальному развитию детей. Воспитанию патриотизма и гражданственности, а также уважения к памятникам защитников отечества и старшему поколению.

Подводя итог, следует отметить, что на сегодняшний день музейная педагогика в образовательных организациях рассматривается как одно из важнейших средств образования, выполняет функции дополнительного образования и осуществляет их в специфической форме – символическом акте встречи прошлого и настоящего, в диалоге музея и учащегося, обладающего правом выбора и интерпретации увиденного и услышанного. Музейно-образовательная среда обеспечивает у обучающихся деятельность образовательную, нравственные и духовные идеалы, гражданскую позицию, гражданский долг.

Список использованных источников

Митриковская М.С. Музейная педагогика в школе/ Молодой ученый.- 2016.№9(113)

Нуриева Миләүшә Әмир кызы,
Арча шәһәре, Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте

## УКЫТУ-ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫНДА МУЗЕЙ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ

Бүген без катлаулы, шул ук вакытта тынгысыз заманда яшибез. Ләкин кайдадыр йөрәкнең бер почмагында киләчәккә ышаныч, җәмгыятебезнең уңай якка үзгәрүенә өмет чаткысы бар. Бу чаткыны тормышка ашыручылар - кешелекле, миһербанлы, шәфкатьле яшь буын булырга тиеш. Яшь буынны дөрес, тиешенчә, җәмгыятькә файдалы шәхесләр итеп тәрбияләгән очракта гына киләчәктә матур, тыныч, якты тормышка өметләнеп була.

Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, патриотик тәрбия бирүдә музейлар зур әһәмияткә ия.

Музейларда ФГОС таләпләренә җавап биргән дәресләр үткәрү; укучыларның танып белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү; үз халкына, тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту аеруча отышка ия.

Бүген республикабызда барлыгы ничә музей эшләвен тәгаен генә әйтеп тә булмыйдыр. Халкыбызга фидакарьләрчә хезмәт итүче милләт җанлы кешеләр көче белән яңа мәдәни учаклар тергезелә. Ватаныбызның, туган ягыбызның тарихын белмичә һәм өйрәнмичә алга карап яшәү мөмкин түгеллекне тормыш һәрвакыт безнең исебезгә төшереп тора. Илдә барган үзгәрешләр музейлар эшчәнлегендә дә чагылыш таба. Тарихка, шәхесләргә булган караш үзгәрә, тарихи исемнәр әйләнеп кайта, яңалары ачыклана тора. Шул үзгәрешләрнең дәвамы булып яңа музейлар ачыла. Музейлар үз халкының данлы тарихы, даһи шәхесләре, бөек мәдәнияте белән горурлана. Музейларда бөтен бер халыкның тарихы, әдәбияты, сәнгате. Музей – ул хәтер хәзинәсе. Халкыбызда кадерләп сандыкларда сакланган яки ваемсызлыкка очрап чәчелеп – аунап яткан ядкарьләрне эзләп табып кире халыкка кайтарган, тарихыбызны барлап, милли хәтеребезне яңарткан хәлдә генә, без милләт булып сакланып кала алабыз.

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Соңгы елларда Арча районында тарихыбызны тулырак күзаллау, халкыбызның данлы үткәнен кадерләп, киләчәк буыннар өчен мөмкин кадәр тулырак саклау юнәлешендә күп эшләр башкарыла, яңа музейлар сафка баса. Музейлар белән укучыларны якыннан таныштыру - татар теле һәм әдәбият укытучыларына дәресләрне тагын да кызыклырак, мавыктыргыч итеп үткәрергә мөмкинлек бирә.

Дөньядагы бердәнбер “**Әлифба” музее** 1999 нчы елда Арча педагогия көллиятендә ачыла. Аеруча мөһим экспонатлар арасында дөнья халыклары әлифбалары коллекциясе (265 саклау берәмлеге), С.Г. Вагыйзов һәм Р.Г. Вәлитованың шәхси әйберләре, дәреслекләре бар.

2009 елның 8 декабрендә ачылган “Казан арты” Арча тарих-этнография музее да районыбызның бай музейларының берсе. Биредә музей хезмәткәрләре, фәнни-гамәли конференцияләр, төбәктән чыккан шәхесләргә багышланган әдәби кичәләр уздыра. Укучылар да бу чараларда бик теләп катнашалар.

Әдәбият дәресләрендә язучыларыбызның тормыш юлын, иҗатын өйрәтүдә Мөхәммәт Мәһдиев музее да зур роль уйный. Ул язучының туган йорты урынында салынган. Музей коллекциясендә язучының туган йорты, үз әсәрләрен иҗат иткән Казан фатирындагы эш бүлмәсе күренешләре, әти-әнисе язмышына бәйле материаллар укучыларда зур кызыксыну уята.

Бер акыл иясе әйткәнчә, милләтне бары бер кеше, бер даһи да тотып тора һәм саклый ала. Безнең өчен ул, әлбәттә – Габдулла Тукай.

Бүген бөек Тукаебыз мирасын Арчабызның Кушлавыч һәм Яңа Кырлай авылларында урнашкан музейлар саклый һәм укучыларга җиткерә.

Кушлавыч авылы һәм аның тирә-як табигате шагыйрьнең шигырьләрендә һәм истәлекләрендә бу урынга багышланган юлларны хәтердә яңарталар. Музей

экспозициясендә шагыйрьнең ата-анасы йортын, аның ул замандагы эчке күренеше күрсәтелгән. Витринада шагыйрьнең әнисенең шәхси әйберләре куелган.

Бүгенге көндә Тукаевларның музей-йорты Г.Тукай әдәби-мемориаль музей комплексы филиалы булып тора.

“Габдулла Тукай дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексы” республика статусына ия. Бүген музей комплексы карамагында парк, күл, төп биналардан тыш Сәгъди абзый, Бай йортлары, Шүрәлеләр паркы ансамбле, фонд бинасы, китапханә, келәтләр, лапас, амбар, кое, ярдәмче корылмалар бар. Видеосалон ачык. Шагыйрь турында фильмнар карарга мөмкин. Укучыларга бөек әдип, әдәбият, мәдәният, тел турында дәресләр үткәрү өчен бик яхшы мөмкинлекләр тудырылган. Музей белем арттыру, мирасны саклау, дөньяга карашны киңәйтү мәркәзе, ял итү урыны. Димәк, алда әйтеп үтелгән музейларда укытучылар укучылар белән дәрес-экскурсияләр, тәрбия сәгатьләре үткәрә алалар.

Музейлар җанга рухи дәва бирүче туган як табигате, аның сихри көчкә ия булган чишмәләре, сабый чакта йөгереп узган яшел хәтфә чирәмле тугайлары аша да туган илгә мәхәббәт тәрбияли. Халкыбызның бай мирасы ярдәмендә үсеп килүче яшь буынның күңеленә изге орлыклар салу – тәрбия эшенең төп максаты.

Халкыбызның милли байлыклары, сәнгатебезнең һәм әдәбиятыбызның милли ядкәрләре озын гомерле, кадерле булсын дисәк, мәктәпләрдә музейлар булдыру, аларның эшенә укучыларны тарту, милли байлыгыбызны өйрәнүгә һәм саклауга кызыксыну уяту-безнең изге бурычыбыз.

Ә музейлар - үткән белән бүгенгене тоташтыручы күпер ул.

Прыткова Н.Ф.
г. Арск, МБОУ «Арская СОШ №2»,
учитель истории и обществознания

## ШКОЛЬНЫЙ МУЗЕЙ – КАК ИННОВАЦИОННОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ ПРОСТРАНСТВО ШКОЛЫ

**Аннотация:** Современный образовательный процесс трудно представить без такой его составляющей, как музейная педагогика. Музейная педагогика решает вопрос, – каким быть человеку в этом постоянно меняющемся мире. Роль школьных музеев стала значительно возрастать. Во многом это связано с тем, что направления работы школьных музеев обширны, что позволяет активно включать его в образовательное пространство школы.

**Ключевые слова:** Музейная педагогика, исследовательская деятельность, инновационные технологии, школа.

В Законе РФ «Об образовании» определены требования к образовательной деятельности, где среди важнейших задач является формирование культурно - исторических ценностей, патриотического воспитания, воспитание

гражданственности, трудолюбия, уважения к правам и свободам человека, любви к окружающей природе.

Современный образовательный процесс трудно представить без такой его составляющей, как музейная педагогика. Музейная педагогика решает вопрос, – каким быть человеку в этом постоянно меняющемся мире.

Музейная педагогика является инновационной технологией в сфере личностного воспитания детей, создающая условия погружения личности в специально организованную предметно-пространственную среду.

Понятие «музейная педагогика» появилось в начале 80-х гг. XX века. За это короткое время сам термин и обозначаемая им деятельность прочно вошли в педагогическую практику.

В настоящее время наше общество начинает осознавать, что будущее России и судьбы новых поколений зависят от того, удастся ли нам сохранить и приумножить богатейшее наследие национальной культуры.

Роль школьных музеев стала значительно возрастать. Во многом это связано с тем, что направления работы школьных музеев обширны, что позволяет активно включать его в образовательное пространство школы.

Целью создания и деятельности школьного музея является содействие развитию коммуникативных компетенций, навыков исследовательской работы учащихся, поддержке творческих способностей детей, формированию интереса к отечественной культуре и уважительного отношения к нравственным ценностям прошлых поколений.

Задачи школьного музея следующие:

–совершенствование образовательного процесса в школе;

–сохранение традиций;

– участие в научно-исследовательской деятельности;

– проведение внеклассных мероприятий среди учащихся

Школа является одним из источников формирования гражданско-патриотического воспитания. В МБОУ «АСОШ №2», работа в музее дает возможность учащимся постигать прошлое, изучать традиции своего народа. На уроках истории, мы широко используем школьный музей. По материалам музея ученики пишут проектные работы, делают сообщения на уроках, проводят познавательные, интересные экскурсии и мероприятия.

Школьный музей можно разделить на три направления:

1. Исследовательская деятельность
2. Экскурсия
3. Внеклассные занятия.

**Исследовательская деятельность.**

Исследовательская деятельность формирует у обучающихся умения и навыки практического применения теоретических знаний, развивает критическое мышление, логику, учит постановке целей, задач и поиску способов их достижения, требует освоения различных методов. Поскольку это приобретается на основе собственного опыта, что приводит к более глубокому осмыслению.

Одним из направлений патриотической работы музея школы является связь с участниками локальных конфликтов. Участники локальных конфликтов (Афганистан) являются постоянными гостями школы, приходя на различные встречи, мероприятия. Живой пример пробуждает интерес учащихся к исследовательской деятельности.

Исследовательской деятельностью охвачены учащиеся 5-11 классов. Обучающиеся работают над исследовательскими работами по тематике: Великая Отечественная война, история семьи в истории страны, история школы, книга посвященная М. Лотфуллину, которая была выпущена в нескольких экземплярах на двух языках. В школе прошла презентация книги.

В «Исследовательской деятельности» совместно с учащимися были созданы следующие проекты:

1. «Директора школы»;
2. «Марат Лотфуллин. Путь в бессмертие»;
3. «История школы МБОУ АСОШ №2»,
4. «Учителями славится Россия»

Мы продолжаем традиции выпускников школы, которые на протяжении многих лет сохранили нить, связывающую молодое и старшее поколения. Коллектив учителей и учеников ведут активную работу с ветеранами ВОВ, трудового фронта, участниками локальных войн – выпускниками нашей школы, отцами, братьями, дедами наших учеников.

**Экскурсии.**

Преимущество экскурсии в школьном музее перед другими образовательными формами заключается в том, что объекты восприятия можно увидеть, рассмотреть, а в некоторых случаях даже взять в руки. На базе музея работает кружок «Живая нить времен». В основе деятельности кружка лежит поиск, систематизация и оформление материалов по истории родного города, МБОУ Арской СОШ, а также материалов, связанных с историей Великой Отечественной войны. Ученики с хорошей дикцией, творческими способностями привлекаются к экскурсионной деятельности и помогают в оформлении материалов. Ученики знакомятся с экспонатами, представленные в музее, проводят экскурсии для учащихся 1-11 классов на татарском и русском языках.

Центральное место в нашем музее занимает экспозиция, посвященная выпускнику нашей школы, воину – афганцу Марату Лотфуллину. Экскурсоводы рассказывают историю школы о ее педагогическом коллективе и директорах, которые были ценны и незаменимы по-своему в определенный момент истории школы.

В коллективе нашей школы в разные годы работали прославленные учителя. Среди них отличники народного образования РСФСР, заслуженные учителя РТ, ветераны труда; заслуженные учителя Российской Федерации, почетные работники общего образования РФ.

**Внеклассные занятия.**

Социальные партнёры «Арская централизованная библиотечная система» и городская библиотека-филиал №1, Историко-этнографический музей «Заказанье», ОГИБДД отдела МВД России по Арскому району, Северное территориальное управление МЭ и ПР РТ и ГКПЗ «Ашит», Арский военкомат и ДОССАФ РТ по Арскому району, Первичное отделение ТРО ВДПО РТ также вносят свой вклад в приобщение дошкольников к национальной культуре, родному языку. В нашем детском саду успешно проходят мероприятия: встреча с писателями Арского района «Талантларга бай син, Арчам!»; музыкально-литературные слушания, посвящённые татарским писателям Фанису Яруллину «Җан жылысы кирэк кешегә», Мусе Джалилю «Муса Җәлил- герой шагыйрь», праздник «Нәүрүз», экологическое развлечение «Карга боткасы», «День родного языка», «Арча читекләре», «Тукай дөньясына сәяхәт» (квест игра), «Зәлидә» уены.

Считаю, что педагог тоже должен развиваться. Для успешной работы в этом направлении я использую один из самых наиболее ярких, развивающих, интересных и значимых методов – это проектная деятельность.

Мной разработаны и проведены такие проекты, как «В мире татарской музыки», «Татарские композиторы - прошлое и настоящее», «Татарские национальные музыкальные игры», «Приобщение детей дошкольного возраста к культуре и традициям татарского народа», «Татар халык гөреф-гадәтләре».

**Основной целью проектов является:**

Приобщение детей к культуре татарского народа, его истокам, языку; познание быта и традиций предков, постижение своих родословных корней; формирование интеллектуальной, нравственно-эстетической культуры, формирование творческой личности ребенка через развитие его музыкальных способностей с помощью слушания и воспроизведения татарской музыки; воспитание искреннего интереса к родной культуре, патриотических чувств любви к родному краю.

Как видим, дошкольное обучение родному языку направлено на активное усвоение языка, пользование им в процессе общения детей между собой и дома с родителями.

Конечно, нельзя сказать, что дети все быстро усваивают, но есть дети, у которых отличное произношение звуков татарской речи. Думаем, что у детей всё ещё впереди. Мы очень рады, что за столь короткий срок родители наших воспитанников стали нашими единомышленниками, они понимают важность изучения татарского языка, возрождения культурных традиций. Надеемся, что родители и педагоги приложат к этому все усилия.

Список использованных источников

1. Р. К. Шаехова, Р. Ф. Шайхелисламова, Г. Х. Манюрова. Радость познания-региональоная образовательная программа дошкольного образования.-2016.-210 с.
2. Интернет ресурсы.

Архипова А.В.
МБОУ “Иштуганская СОШ Сабинского муниципального района Республики Татарстан”, учитель начальных классов

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

Заманча технологияләрне белү, алар ярдәмендә дәресләр оештыру югары нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән уку процессын яңача кору, укучыларны актив эшчәнлеккә җәлеп итү, заманча таләпләргә җавап бирүче шәхес тәрбияләү өчен кирәк.

Бүгенге көндә уку эшчәнлеген заманча технологияләрсез күз алдына китерү мөмкин түгел. Әгәр татар теленә, әдәби әсәрләргә кызыксыну бәләкәй яшьтән, балалар бакчасыннан, гаиләдән башлана икән, ныклы эшчәнлек башлангыч сыйныфлардан башлана.

Бу чорда укытучы беренче сыйныф укучыларында укуга кызыксыну уятырга һәм аларның базасын булдырырга, үз эшчәнлегендә бу максатка ирешү ысулларын һәм алымнарын өйрәнергә тиеш. Әлбәттә, бу эш бүгенге көн таләпләренә туры китереп һәм яңа технологияләр кулланып алып барыла.

Без заман белән бергә барырга, тормыштагы барлык яңалыклардан хәбәрдар булырга, яңа технологияләрне яхшы белергә, аларны тирәнтен өйрәнергә, яңа буын балаларына төпле белем һәм тәрбия бирү, татар телен өйрәнүгә кызыксындыру арттыру өчен үз эшчәнлегебездә актив кулланырга тиешбез.

Уку процессында заманча технологияләрне куллану-белем сыйфатын яхшырту өчен бик эффектив чара. Чөнки алар укуга кызыксыну уята, уку материалын тирәнрәк үзләштерү теләге уята, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү мөмкинлеге бирә. Бары тик теләк белән башкарылган эш кенә истә кала, баланың сәләтләрен һәм аңын үстерә. Әгәр дә материалны үзләштерү авыр булса, укучының күңеле суынырга һәм телне өйрәнү теләге бөтенләй сүнәргә мөмкин.

Татар теле дәресләрендә компьютер техникасын кулланганда телне өйрәнүгә кызыксыну барлыкка килә. Балалар мәктәптә укытыла торган башка фәннәр арасында татар теле дәресләрен компьютер, Интернет ярдәмендә өйрәнергә мөмкин икәнен күрәләр. Бу, үз чиратында, телнең абруен күтәрү өчен зур стимул булып тора.

Башлангыч сыйныфларда куллану өчен мультимедия тавышы белән интерактив "Бала" китапханәсе бик файдалы. Монда татар телендә мультфильмнар карарга мөмкин. Аларның саны даими үсә. "Бала" китапханәсендә мультикларны караганнан соң төрле кызыклы биремнәрне үтәү мөмкинлеге дә бар.

Шулай ук укытучылар өчен интерактив уеннар чыганагы булып SuperKid Online платформа - конструкторы бик актуаль. Әлеге платформа дәресләрне мөмкин кадәр мавыктыргыч һәм кызыклы итеп алып барырга булыша.

Платформадагы шаблон төрләре: төркемнәргә бүл,викторина, сүз куй, кроссворд, космик математика, карточкалар, парын тап, анаграмма, кубиклар, тәрәзәне ач, элементларны бәйлә, җавап яз, әйе/юк, хәрефне куй.

Бу платформада ничек эшләргә соң?

1 Адым: SuperKid сылтамасы буенча сайтка керәсе

2 адым: үзегезгә ошаган Шаблонны сайлыйсы

3 адым: форманы тутырып, фонны сайлыйсы

Һәм безнең интерактив уеныбыз әзер!

Дәресләргә әзерлек беркайчан да тиз һәм җиңел булмаган! Сайтта бушлай тариф бар, шуңа күрә сез интерактив уеннар һәм биремнәр ясауның җиңел юлларын карый аласыз.

Шулай ук киң кулланышта булган,дәресләрдә яратып куллана торган тагын бер сайт белән таныштырып китәсем килә – Festisite (фэстайзит).

Әлеге сайттагы биремнәр татар теле, әдәби уку дәресләрендә уку тизлеген арттыру өчен бик яхшы дип саныйм.

“Текстның макеты” бүлегенә кереп, төрле мавыктыргыч, кызыклы һәм шул ук вакытта өйрәтүчән уеннар төзеп була.

Мәсәлән: үзең теләгән текстны

1. Лабиринт формасында
2. Спираль формасында

3. Йөрәк формасында

4. Дулкыннар формасында ясап, балаларга укырга тәкъдим итергә мөмкин.

Бу төр күнегүләр уку тизлеген генә арттырып калмый, ә укуга мәхәббәт тә уята.

Яңа стандартлар белем бирү процессында электрон белем бирүнең төрле формаларын да куллануны таләп итә. Шундыйларның тагын бер берсе - LearningApps.org сервисы. Бу сервис төрле дидактик биремнәр (уеннар) тәшкил итә. Биремнәрне әзер килеш алып кулланырга да мөмкин, укытучы үзе теркәлеп, узенчәлекле викториналар, пазллар җыю, парын табу, кроссворд чишү кебек уеннарны да төзи ала.

LearningApps.org миңа дәресләрне күңелле, нәтиҗәле итеп үткәрергә ярдәм итә. Укучыларда фәнни фикерләү тибын формалаштыра. Бу сервис дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек өчен бик уңайлы инернет ресурс булып тора.

LearningApps.org кече яшьтәге мәктәп укучыларының белем бирү өлешен киңәйтү мөмкинлеге бирә. Балалар һәм аларның ата-аналары белән үткәрелгән күзәтүләр, әңгәмәләр нәтиҗәсендә, балаларга өйдә һәм тәкъдим ителгән ресурслы мәктәптә эшләү бик ошый, аларга бу кызыклы. Димәк, уку эшчәнлеген мотивацияләү арта һәм, нәтиҗә буларак, сыйныф укучыларының белем дәрәҗәсе арта.

Минемчә, татар теле дәресләрендә балаларның белемнәрен актуальләштергәндә, яңа тема өйрәнгәндә һәм ныгытканда, LearningApps.org сервисын куллану бик нәтиҗәле кушымта булып тора.

Моннан тыш, татар теле буенча электрон дәреслекләр, алынган белемнәрне тикшерү өчен тестлар җыелмалары, кирәкле материаллар белән төрле сайтлар, электрон сүзлекләр укучыларга теге яки бу тема буенча мәгълүмат эзләү, кроссворд төзү кебек биремнәрне рәхәтләнеп башкарырга мөмкинлек бирә.

Мисал итеп ,әйдәгез бергәләшеп, “Сайланма диктант” күнегүен төзеп карыйк .

1.“Новое упражнение”- “Яңа күнегү” төймәсенә басабыз

2. Тәкъдим ителгән макетлар арасыннар “Простой порядок” - “Гади тәртип”дигәнен сайлыйбыз

3. “Создать новое приложение” – “Яңа кушымта төзү” төймәсенә басып , күнегүне эшли башлыйбыз

4. “Постановка задачи ” - “Бурычлар кую” өлешендә күнегүнең биремен язабыз (мәсәлән , “Текстны 1 -2 минут эчендә кара. Бирелгән җөмләләрне тексттагы тәртип буенча төзеп куй”)

5. “Карта 1” өлешендә “текст” төймәсенә басып , текстның беренче җөмләсен язабыз.

6. “Добавить следующий элемент” – “Киләсе элементны өстә” төймәсе ярдәмендә текстның һәрбер җөмләсен тутырып язабыз.

Мин тәкъдим иткән текстта 5 җөмлә.

*Кешеләр пошины кулга иянләштерергә күптән тырышалар. Кострома өлкәсендәге поши фермасы бар. Поши – чыдам, салкынга бирешми торган хайван. Пошилар калын карда да, язгы пычракта да җиңел йөриләр. Азыклары – агач кайрысы, нарат, чыршы һәм усак ботаклары.*

7.“Обратная связь” – “Кире элемтә” өлешендә күнегү дөресс эшләнгән очракта, мактау сүзләре өчен сүзләр языла. (Афәрин!!! Булдырдың!! Шәп!)

8. “Помощь” – “Ярдәм ” өлешендә текстны беркетергә мөмкин. Текст төзүдә авырлыклар туып , бик озакка сузылса , укучы ,сул якта өске почмакка кирәкле төймәгә басып, текстны карап алырга мөмкин.

9. “Установить и показать в предварительном просмотре” – “Беренчел карау” төймәсенә басып эшләнгән күнегүне эшләп карыйбыз , өстәмәләр кертәсе булмаса , саклап куябыз “Сохранить приложение ” – “Кушымтаны саклау”

Күнегү эшләве кыенлык тудырса, тәкъдим ителгән күнегүләр арасыннан охшаганын сайлап, үзгәртергә була. Моның өчен уңышлы дип табылган күнегүне ачып, “Создать подобное приложение” – “Охшаш кушымта төзү” төймәсенә басабыз. Әзер мисалны үзебезгә ничек кирәк, шулай үзгәртәбез.

LearningApps.org программасында интерактив күнегүләрне эшләп өйрәнү, эш тәҗрибәсендә куллану дәресләрне тагын да кызыклырак, файдалы, заманча үткәрүгә бер адым булыр дип ышанам.

Йомгаклап әйткәндә, уку-тәрбия процессын нәтиҗәле оештыруга юнәлдерелгән күп кенә заманча технологияләр бар. Аларны безнең дәресләрдә дөрес һәм урынлы куллана белү генә кирәк. Заманча технологияләр укытучылар алдында торган төрле мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә: уку материалын аңлаешлырак итәргә, белемнәрне системалаштырырга, укучыларның иҗади үсешен тәэмин итәргә, укытуны яхшыртырга, яңа теманы җиңелрәк үзләштерергә мөмкинлек бирә. Уку процессын компьютерлаштыруның өстенлекләре турында күпме генә сөйләшсәк тә, укытучының тере сөйләмен бернәрсә дә алыштыра алмый. Дәрестә компьютер куллану укытучы һәм укучы арасында аралашу белән бергә булырга тиеш.

## Файдаланылган әдәбият

1. Вәлиев Р. Информационное обеспечение процессов образования/Р. Вәлиев // Мәгариф.−2005.−№ 6.
2. Минһаҗев А. Дәресләрдә компьютер куллану/А.Минһаҗев // Мәгариф.−2006.−№ 7.
3. Нигъмәтуллин Х. Тестларны компьютер ярдәмендә чишү/Х.Нигъмәтуллин //Мәгариф.−2007.−№ 8.
4. http://www.balarf.ru/
5. https://superkid.online/
6. https://learningapps.org/

Асхадуллина А.Г.
г.Арск, МБДОУ «Арский детский сад №11 общеразвивающего вида»,
воспитатель

# РОДНОЙ ЯЗЫК В ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ ОРГАНИЗАЦИИ: СОЗДАНИЕ УСЛОВИЙ ДЛЯ ВОВЛЕЧЕНИЯ РЕБЕНКА В ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ ПРОЦЕСС

Аннотация: Как известно, важнейшим условием полноценного развития народа является сохранение своего родного языка. Язык – одно из самых глубинных, внутренне присущих человеку свойств, определяющих его этническую, национальную принадлежность..
Ключевые слова:

*«Родной язык – святой язык, отца и матери язык,*
*Как ты прекрасен! Целый мир в твоем богатстве я постиг!*
*Качая колыбель, тебя мне в песне открывала мать,*
*А сказки бабушки потом я научился понимать.*
*Родной язык, родной язык, с тобою смело шел я вдаль,*
*Ты радость возвышал мою, ты просветлял мою печаль.*
*Родной язык, с тобой вдвоем я в первый раз молил творца:*

Это прекрасные строки из стихотворения Габдуллы Тукая, который вошел в историю татарской литературы как великий народный поэт, заложивший основу национальной поэзии и создавший ее классический стиль. Признание и уважение всех языков, является ключом к сохранению мира. Каждый язык неповторим. Он имеет собственные выражения, которые отражают менталитет и обычаи народа. Подобно нашему имени, мы обретаем родной язык от нашей матери в детстве. Он формирует наше сознание, пропитывает заложенной в нем культурой. Родная речь - это живой воды родник, питающий страницы лучших книг. И тем ценней святой её глоток, что травят, загрязняют наш исток.

В настоящее время возникает необходимость в том, чтобы ребенок почувствовал уникальность своего народа, знал его культуру, пришел к пониманию и осознанию собственной неповторимости и значимости каждого человека, живущего на земле.Приобщение дошкольников к национальной культуре становится актуальным педагогическим вопросом современности, так как каждый народ не просто хранит исторически сложившиеся воспитательные традиции и особенности, но и стремится перенести их в будущее, чтобы не утратить исторического национального лица и самобытности.

Овладение родным языком, развитие речи являются одними из самых важных приобретений ребенка в дошкольном детстве и в современном

дошкольном образовании рассматриваются как общая основа воспитания и обучения детей. Поэтому так важно с детства создавать представление о том, что язык –это главное сокровище народа; воспитывать любовь и бережное отношение к родному языку. Родной язык необходим не только как средство общения и познания окружающей действительности, но и как средство фиксации, сохранения национальных культурных традиций.

В наш детский сад посещает 120 детей. Из них татароязычные, русские-2.К сожалению, детей знающих свой родной язык становится все меньше и меньше. И перед нами встала проблема: как возродить татарский язык? Решение данной проблемы мы видим в изучении родного языка в детском саду. Чем раньше это обучение произойдет, тем лучше будет результат. Но главное состоит в том, что в раннем возрасте ребенок овладевает умение, которое существенным образом влияет на его последующее поведенческое, интеллектуальное и личностное развитие, а именно – способность понимать язык и активно пользоваться им в общении. Через речь, которой ребенок овладевает в эти годы, он получает прямой доступ к важнейшим достижениям человеческой материальной и духовной культуры. Также ребенок открывает для себя назначение многих предметов и начинает не просто манипулировать ими, а действует с ними по-человечески. У ребенка формируется предметная деятельность. Ребенок воспроизводит действия взрослых с предметами, у него проявляются предметные игры-подражания. Они представляют собой первые шаги к символизации, связанной с усвоением норм и форм поведения взрослых, а далее- с формированием у ребенка определенных личностных качеств. Позднее появляется сюжетно-ролевая игра, в которой ребенок копирует способы обращения людей с предметами и общения друг с другом в различных ситуациях. Именно в этом возрасте дети легко могут освоить 2 языка: русский и татарский.

Русскоязычный ребенок начинает обучаться родному языку со сформировавшейся под влиянием семьи, окружающих его взрослых потребности научиться говорить на родном языке. Это безусловно, является большой побудительной силой. Но малого дитя все-таки невозможно учить родному языку, опираясь только на этот мотив. Его необходимо подкрепить мотивацией, заложенной в самом образовательном процессе, построенном с учетом возраста, интересов и потребностей детей. Все начинается с языка, а в языке со слова, ибо «В начале было Слово». Поэтому представляется необходимым остановиться на проблеме создания условий для вовлечения ребенка в образовательный процесс. Первичное обучение родному языку может начинаться с 2- летнего возраста, если позволяет благоприятная языковая ситуация. Но в некоторых смешанных семьях вообще отсутствует среда общения на родном языке.

В настоящее время вступает в силу ФОП. В нем учитывается приобщение детей к социокультурным нормам, традициям семьи, общества и государства;

формирование познавательных интересов и познавательных действий ребенка в различных видах деятельности; учет этнокультурной ситуации развития детей.

В связи с этим был разработан и составлен учебно-методический комплект « Туган телдә сөйләшәбез”. Предложенный УМК включает в себя методические пособия по обучению родному (татарскому ) языку и развитии речи детей дошкольного возраста, рабочие тетради, начиная со средней группы,аудиозаписи,серии картин. Основная цель УМК – формирование правильной устной речи детей дошкольного возраста. Главной задачей для программы является обучение детей правильно и красиво говорить. Он предусматривает совместную работу с детьми педагогов ДОУ, родителей в различных видах деятельности и в семье.

Работая в детском саду, накапливается опыт по обучению детей языку. А для этого, в первую очередь должно быть предусмотрено учебно-методическое, кадровое, материально-техническое, правовое обеспечение. Материальную основу всего учебно-воспитательного процесса современного детского сада составляют программы, наглядные пособия, методическая литература, технические средства обучения. Основное содержание программы воспитания в детском учреждении составляет национальный региональный компонент. Дети дошкольного возраста воспитываются в среде с национальным колоритом, знакомятся со сказками, стихами, загадками слушают народные песни, играют, учатся исполнять национальные танцы. По-моему мнению, в этом нужен комплексный подход. Учитывая возрастные особенности детей и руководствуясь Госстандартом по образованию и воспитанию мною проводятся занятия по изучению татарского языка с русско-язычными детьми. При подготовке к занятиям, ставятся следующие задачи: воспитывать у детей любовь к родному краю, к её природе и бережное отношение к ней; воспитывать патриотические чувства у детей, гордость и уважение к прошлому и настоящему родного края; познакомить детей с интересными историческими событиями, трудовой деятельностью, культурой, бытом и праздниками татарского народа.

Все эти задачи осуществляются не только на занятии по обучению родному языку, но и реализуются в изобразительной деятельности, самостоятельной художественной деятельности. Огромная роль принадлежит декоративно-прикладному искусству, музыке, ознакомлению с народными обычаями, традициями. Важнейшее значение имеет проведение татарских праздников.

Основным направлением обучения татарском языку в дошкольном учреждении является формирование и развитие у детей простейших умений и навыков овладения татарской речью в устной форме. В исследованиях А.Ш. Асадуллина, С.Г.Вагизова, Р.Г.Валитовой, Ф.Ф. Харисова, Ч.М. Харисовой и др. подчеркивается , что дети старшего дошкольного возраста не только понимают значения слов татарского языка, но и умеют пользоваться словами и

словосочетаниями для построения собственных высказываний и через словари знакомятся с богатством родного языка, с обычаями и традициями своего народа.

К концу подготовительной группы, дети должны уметь воспринимать татарскую речь на слух и вести несложный разговор (диалог), составлять небольшое описание предмета, рассказать о детском саде, о своей семье, о себе, о друзьях и т.д., в пределах доступной их возрасту тематике; усвоенных слов, грамматических форм, синтаксических конструкций и типов предложений.

Важнейшим моментом, по-моему мнению, является учет их психологических особенностей.Формирование и развитие умений и навыков татарской устной речи проводится в игровых и учебных ситуациях по темам всего, что их окружает(игрушки, предметы одежды, обуви, продукты питания, посуда ,овощи, фрукты, семья, детский сад и т.д.)Программа обучения детей татарскому языку в группах с различными категориями детей ,должна раскрывать уровень речевого развития, состав и последовательность работы по усвоению звуковой системы языка, его лексики и грамматического строя.

На практике я убедилась, что основной формой работы с детьми дошкольного возраста и ведущим видом деятельности для них является игра. Именно поэтому занятия в основном представляют собой разговорные упражнения, про проведении которых детям прививаются первоначальные умения в диалоге, монологической речи на татарском языке, чтение стихотворений, прослушивание аудио сказок. В работе по воспитанию у детей дошкольного возраста любви и уважения к национальным традициям татарского народа мною используется татарский фольклор и детская национальная литература. Дошкольники младшего и среднего возраста лучше воспринимают потешки, песенки, народные игры. В этих группах не ставим целью запоминание национальной принадлежности фольклорного материала. Как воспитатель, работающий с современными детьми, стараемся использовать мультимедийные ресурсы нового поколения .Используем различные презентации, просмотр мультфильмов, прослушивание аудиосказок.

При изучении родного языка, стараемся постепенно включать в свою речь новые слова, формы слов, типы предложений, образцы связной речи.

Прилагая все усилия, чтобы изученные слова регулярно использовались в речи детей. Опыт работы показал, что изучение татарского языка в дошкольном учреждении может быть успешно реализовано в том случае, если язык будет выступать не только в качестве предмета изучения, но, и будет регулярно, активно использоваться детьми в их повседневной жизни и деятельности.

Дети очень любят сказки. Татарские народные сказки раскрывают традиции народа, его устои: глубокую почтительность и отзывчивость, сострадание к ближнему. Знакомлю детей с бытовыми сказками и сказками о животных: «Саран и юмарт», «Хвосты», «Три дочери» и т.д.; с замечательными сказками основоположника татарской детской литературы Г.Тукая «Шурале», «

Водяная» , «Сказка о козе и баран». Художественная литература дает богатый материал для нравственного воспитания, заставляет ярче и глубже переживать нравственные поступки, чувства героев.

Таким образом, основным компонентом национальной культуры выступает национальный язык. Именно благодаря нему сохраняется нация, правильное понятие о древних традициях и культуре, знания о своей религии. В образовательной деятельности при обучении татарскому языку дошкольники получают не только новые знания о родной земле, о национальностях, проживающих на территории республики, а тем самым создаются условия для формирования нравственных чувств.

Язык - это такой символ культуры, который ничем не заменить. Это богатство. И чем больше языков знает человек, тем он духовно богаче! А для этого нам нужно уметь искать, собирать знания по крупицам и быть упорными в приобретении знаний. Именно этому мы должны учить детей.

Воспитывать любовь к чтению, знаниям. И делать это будет намного эффективнее в тесном сотрудничестве с родителями. В результате своих размышлений, мы пришли к выводу, что ничто другое так не оказывает влияния на душу ребенка, как личный пример взрослого. А значит, впереди нас ждет большой и упорный труд, который непременно принесет свои плоды!!!

Список использованной литературы:

1. Бурганова Р.А., Хисамова Ф.М. Малыши изучают татарский язык. Пособие для воспитателей детских садов. На татарском языке.- Казань: Магариф, 2005.-207с.
2. Муяссарова И.Х. Отдохнем чуть-чуть: Физкультминутки и сссюжетные игры ( на татарском языке).- Казан, 1998.-60с.
3. Программа по обучению детей татарскому языку в детском саду.- Казань: Школа,2004.-84с.
4. https\\edu.tatar.ru\nkamsk\dou68\umk\u
5. Харисова Ч.М. Методика обучения татарскому произношению.=Казань: Магариф, 2000.-167с.

Ахметшина Н.Р., Миннебаева Г.М.
МБДОУ “Арский детский сад №9”

## БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА ТУГАН ТЕЛ: БАЛАНЫ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЦЕССЫНА ҖӘЛЕП ИТҮ ӨЧЕН ШАРТЛАР ТУДЫРУ

Мәктәпкәчә яшь ул-шәхеснең үсешендә иң мөһим чор. Бу чорда бала үзен чолгап алган тирәлек, кешеләр, табигать дөньясы белән таныша, аралаша башлый. Сабыйның дөньяны танып белүе гамәлгә ашырыла,үзен

кызыксындырган сорауларга җавап эзли, җавап таптыра. Нәкъ менә шушы чорда нәни кешенең шәхес булып формалаша башлавында беренче адымнар ясала да инде.

Ләкин,бүгенге көндә балаларның сөйләм теле бик түбән дәрәҗәдә. Бик күпләрнең теле озак һәм авыр ачыла. Мин моның сәбәбен бала белән аралашу җитмәүдә күрәм. Ата-ананың бала белән сөйләшергә, төрле уеннар уйнарга вакыты да, теләге дә юк. Бала күбрәк компьютерда утыра, телевизор карый. Шул сәбәпле тел озак һәм авыр ачыла. Хәзерге чорда компьютерның үтеп кергән, техниканың алга киткән вакытында туган тел югала башлый. Сөйләмгә чит ил сүзләре үтеп керә, ә компьтер теле әдәби матурлыктан мәхрүм. Шуңа күрә дә балаларны кечкенәдән үк үз туган телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Балаларның авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп ,үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә, ашыкмыйча сөйли белүләренә ирешү өчен, сөйләм үстерү юнәлешендә даими эш алып барылырга тиеш. Бу очракта халык авыз иҗаты әсәрләое ярдәмгә килә.

Татар халык авыз иҗаты аша бала туган телне өйрәнеп кенә калмый, ә аның матурлыгына төшенә, гореф – гадәтләре турында беренчел күзаллаулар барлыкка килә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән тел үстерү чаралары вакытында да, уйнаганда да таныштырырга була. Җанлы һәм тапкыр сүзле мәкаль-әйтемнәр, санамыш, такмак, табышмак, экиятләр балаларда тел матурлыгын тоемлау тәрбиялиләр, танып белү эшчәнлеген, сөйләм телен үстерәләр. Халык авыз иҗаты әсәрләренең тәрбияви әһәмияте дә аеруча зур.

Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрнең төп бурычы - балаларны рухи яктан бай, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Алар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Ә шулар арасында иң әһәмиятлесе- уеннар. Бала тормышын уеннарсыз күз алдына китереп булмый. Ул уйный-уйный тормышны өйрәнә. Уен ярдәмендә балаларда зирәклек, оешканлык, коллективта үзеңне тота белү, җитезлек кебек сыйфатлар тәрбиләнә. Уен – шөгыльдә алынган белемнәрне ныгыту чарасы да ул. Уен мәктәпкәчә яшьтәге баланың танып белү эшчәнлеген, иҗади фикерләвен һәм сөйләмен үстерә, уенда бала үзе белмәгәнне өйрәнергә, аны эшләргә омтыла. Сөйләмне үстерү – балаларның бәйләнешле сөйләмен (диалогик, монологик) һәм сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, камилләштерү, сүзлеген баету бит инде ул. Бу әйткәнемчә, безнең балалар белән бердәм эшчәнлектә төрле уеннар: дидактик, сүзле, хәрәкәтле, җырлы-биюле, устерелешле уеннар, бармак уеннары, сюжлы-рольле уеннар аша тормышка ашырыла.

Уеннарның максаты сөйләм үстерү күнекмәләре бирү генә түгел, ә баланың мөмкинлекләренә игътибарлылык, күзаллау, фикерләү, хәтер үсешен тәэмин итүче буларак та бәяләнә

Заман уку-укыту эшчәнлегенең барлык тармагына да үзгәрешләр кертә, безгә, тәрбиячеләргә дә, яңа таләпләр куя. Сыйфатлы белем бирү өчен, мәгариф өлкәсендә модернизацияләү кирәклеген аңлап, без дә дәресләребездә инновацион технологияләр кулланып эшләргә тиеш. Балалар бакчасында тәрбия эше эчтәлеген яңарта бару, инновацион технологияләрне куллану — тормыш таләбе. Яңа педагогик технологияләрне куллануның төп максаты - белемле, тәрбияле, тормышта үз юлын табарга әзер булган, яхшыны яманнан аера, тиешле карар кабул итә белгән шәхес тәрбияләү.Укыту процессында инновацион технологияләр куллану балаларда татар телен тагын да ныграк белергә кызыксыну уята.

Информацион технологияләрне куллану формалары:

- Әзер электрон продуктларны куллану. Белем бирүнең сыйфатын яхшырта, күрсәтмәлелек принцибын ачык итеп тормышка ашырырга ярдәм итә.
- Мультимедиалы презентацияләр куллану. Уку материалын тиешле бер эзлеклелектә биреп, материалны ассоциатив рәвештә истә калдырырга булыша.
- Интернет челтәре ресурслары куллану. Белем алуга кирәкле информацияне таба белергә һәм системага салырга ярдәм итә.

Бүген мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә эшләүче татар теле тәрбиячеләре алдында торган бурычларның берсе – рус телле балаларга татар теле өйрәтү, аларны халкыбызның тарихы, матур йола, гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре, мәдәнияте белән таныштыру. Бу эш бездән бик зур җаваплылык, түземлелек һәм осталык сорый. Бу эштә безгә укыту- методик комплектлары зур ярдәм итә. Бу комплектлар балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү, шул телләрдә сөйләшү, аралашу бурычларын үз эченә ала. Балалар белән эшчәнлекнең төп максаты инфомацион-коммуникатив технологияләр, уен-ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру. Чынлап та, бу комплектлар һәрбер эшчәнлекне оештыру өчен төсле матур күргәзмә, таратма рәсемнәр, битлекләр, аудиоязмалар, бармак театрын үз эченә ала.

Укыту-методик комплектларның төп компонентларыннан берсе –эш дәфтәрләре. Алар балаларга сүзләрне истә калдырырга, аларны сүзтезмәләрдә һәм җөмләләрдә дөрес кулланырга бик нык ярдәм итә, шулай ук сүзләргә аваз анализы ясаганда булышлык итә. Шулай ук тәрбиячегә дә материалны ныгытырга, эшчәнлеккә кызыксыну уяту вакытында баланың хаталарын төзәтергә мөмкинлек бирә. Болар барысы да балаларның сүз байлыгын, сүзләрне отып калу аша хәтерен, зиһенен үстерә һәм иң дә отышлысы, гади диалогта катнаша белү күнекмәсен үстерә.

Икетеллелекне ныгыту максатыннан, бакчабызда музей оештыру бик отышлы булды. Бүгенге көндә музей педагогикасын эшебездә уңышлы кулланабыз. Шулай ук бакчабызның күрке булган татар йорты почмагы да шуның бер үрнәге. Балаларны халкыбызның милли киемнәре, милли ризыклары, савыт-сабалары, бизәнү әйберләре, көнкүреш кирәк-яраклары, уенчыклары, эш

кораллары, китап-журналларын күрсәтеп таныштыру- максатыбызга ирешүдә зур этәргеч булып тора.

Балалар бакчасында татар төркемнәре булуга карамастан, рус мохите хөкем сөрә. Тәрбиячеләр татар булса да, бөтен бала аңласын өчен русча сөйләшергә мәҗбүр. Балалар да үзара рус телендә аралаша. Чөнки күпчелек әти-әни гаиләдә туган телдә сөйләшми, шуңа да бакчага рус телле балалар килә. Минемчә, өйдә татарча аралашкан бала ана телен онытмый. Шулай ук ата-ананың телгә мөнәсәбәте нинди, баланыкы да шундый. Балам үз ана телен белергә тиешдигән фикердәге ата-аналар, кызганыч ки, еш очрамый. Тәрбияченең үзенә генә баланы татарча яхшы итеп сөйләшү дәрәҗәсенә җиткерү мөмкин түгел, моңа гаиләнең дә ярдәме кирәк. Балаларны дәүләт телләренә өйрәтүдә безнең иң якын ярдәмчеләребез - төркем тәрбиячеләре һәм ата-аналар.

Ата аналарны үзебезнең эшкә җәлеп итү өчен балаларны дәүләт телләренә өйрәтү чаралары, алымнары, татар халык бәйрәмнәре, татар язучыларының юбилейларына багышланган материаллар, гомумән, мәгариф өлкәсендәге яңалыклар белән таныштыру өчен информацион-күрсәтмәматериаллар булдырдык. Һәр төркемнең чишенү бүлмәсендә төркем балаларының яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып,ата-аналар өчен «Татарча сөйләшәбез» дип аталган папкалар ясалды. УМК кергән мультфильмнарны өйдә карарга биреп җибәрәбез. Балалар бакчасында өйрәнгән шигырьләрне ныгыту өчен өйгә алырга тәкъдим итәбез. Әти-әниләр өчен “Уйный-уйный өйрәник...”, “Уйнаганда өйрәник”, “Туган тел саекмас чишмә” темаларына консультацияләр тәкъдим итәбез. Уеннарның уйнау тәртибен әти-әниләргә аңлатырга, өйрәтергә тырышабыз. Бергәләп эшләсәк , зуррак нәтиҗәләргә ирешербез дип өметләнәбез.

Гарәпшина Рузия Миннехан кызы
Арча ш., ДАҺБУ “Г.Тукай исемендәге
Арча педагогия көллияте”,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

## МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРДА ТУГАН ТЕЛГӘ КЫЗЫКСЫНДЫРУ УЯТУ ЮЛЛАРЫ

**Аннотация:** Статья посвящена одной из важных проблем современной системы дошкольного образования. Она отражает содержание, особенности национально-регионального компонента в дошкольном образовании.

**Ключевые слова:** национальное образование, обучение, родной язык, воспитание детей, обучение грамоте.

**Abstract:** The article is devoted to one of the important problems of the modern system of preschool education. It reflects the content and features of the national-regional component in preschool education.

**Keywords:** national education, education, native language, parenting, literacy training.

Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес тә, халык та тарихсыз“. Рухи хәзинә, рухи байлык – ул бик киң төшенчә. Аңа сәнгатьнең барлык төрләре, халкыбызның гасырлар буе яшәп килгән гореф-гадәтләре, әхлак кагыйдәләре, тормышның һәр өлкәсендә тупланган халык акылы, аның тормыш тәҗрибәсе керә. Милли рухи байлык аерым халыкның гына түгел, ул – гомум кешелек кыйммәтләренең нигезе. Димәк, балаларны кечкенәдән үк үз халкының , үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру гомум кешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора. Ләкин үз халкыңның бу байлыгын бөтен нечкәлеге белән аңлау һәм үзләштерү тел белүдән башка мөмкин түгел. Шуңа күрә олы фикер ияләре ана телен халыкның бөек тәрбиячесе дип атыйлар һәм баланың акыл сәләте дөрес юнәлештә үссен өчен иң элек үз телен яхшы үзләштерергә тиешлеген ассызыклыйлар. Бөек педагоглар Ян Амос Коменский һәм К.Д. Ушинский да башта ана телен, аннан соң гына башка телләрне өйрәтә башларга кирәклеген әйткәннәр.

Ләкин бүгенге мохит безне бүтән шартларга куя, үз таләпләренә яраклашырга мәҗбүр итә. Икетеллелек, тигезсез икетеллелек дип әйтергә кирәк, шартларында татар авылларында, татар гаиләсендә туып-үскән балаларның да русча сөйләшкәненә инде гаҗәпләнми дә башладык. Бездә ике дәүләт теле дисәк тә, һәр җирдә берсенең өстенлек алуын күрәбез. Бала ике телне ишетсә дә, кызганычка каршы бер телдә генә аралаша. Балалар күбесе русча аралаша. Моның сәбәпләре күптөрле: тәүлеккә 24 сәг. эшли торган телевизион каналлар, интернет челтәре, балалар кулында уенчык ролен башкаручы телефон, үз туган телен кирәксезгә санап, белсә-белмәсә русча сөйләшеп, баланың бер телне дә тиешенчә үзләштерә алмавына сәбәпче булган әти-әни, әби-бабайлар. Димәк, бала өйдә дә туган телен ишетми , аралашмый дигән сүз. Шул сәбәпле, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында яшь буынга туган телләрендә белем һәм тәрбия бирү эшенә зур игътибар бирү бурычы куела. Ә бурыч түбәндәгедән гыйбарәт: үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның иң кыйммәтле үрнәкләрен балаларга җиткерү аша үз туган телен өйрәтү.

Татар телен өйрәтүдә бик күп төрле алымнар, әсбаплар кулланыла. Моңа мисал итеп, татар теле шөгыльләрендә кулланырга мөмкин булган электрон ресурсларны, “Бала.РФ” дип аталучы интерактив мультимедияле, тавышлы китапханә, Күңелле әлифба» проектының видеоларын китерергә мөмкин. Болар чынлап та, татар теленә кызыксыну уята торган чаралар.Еш куллана башлагач, балаларның мондый чараларга да исе китми башлый.

Шул сәбәпле татар теле шөгыльләрендә үзләрен пассив тоталар. Ничек итеп һәм нинди юллар аша балаларда татар теленә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләргә соң? Татар теле шөгыльләрен ничек кызыклы һәм мавыктыргыч итеп үткәрергә? Шөгыльдән тыш вакытларда ничек итеп татарча сөйләштерергә?

Бу максаттан төрле сюжетлы-рольле уеннар, экиятләрне сәхнәләштерү кебек чаралар уңай нәтиҗә бирүен барыбыз да яхшы беләбез.

Шуларның иң нәтиҗәлесе халкыбызның сәнгате, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары, милли әдәбияты белән таныштыру. Сезнең һәрберегез халык авыз иҗаты әсәрләрен көндәлек хезмәтендә киң куллана.

Җор телле әби-бабаларыбыз иҗат иткән табышмаклар, санамышлар, такмаклар, тел көрмәкләндергечләр, мәкаль-әйтемнәр, экиятләр, бишек җырлары – тел өйрәнүдә иң бай чыганак. Татар халкының яшь буынны тормышка әзерләү тәҗрибәсе, гореф-гадәтләр, традицияләр, бәйрәмнәр, буыннан буынга тапшырылып камилләшә барганнар. Милли бәйрәмнәр һәм гореф-гадәтләр, балаларыбызны халык культурасы белән таныштыруда да зур урын алып тора.

Һәр халыкның традицияләре, йолалары үзенчәлекле. Милләтләр арасында толерантлык тәрбияләү ягыннан бу бигрәк тә актуаль булып тора. Халык сәнгате, традицияләре белән якыннан танышу, бәйрәмнәрендә катнашу, балаларны рухи яктан баета, сөйләм үсешенә уңай йогынты ясый, аралашу теләген көчәйтә,үзенең халкы өчен горулану хисләре тәрбияли һәм аның тарихына, мәдәниятенә кызыксыну уята. Халык бәйрәмнәре – ул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була.Татар халкының Нәүрүз, Сөмбелә, Сабантуй, Нардуган, каз өмәсе бәйрәмнәре елдан-ел камилләшә, кызыклы итеп оештырыла башлады.

Халык җәүһәрләрен балалар җиңел, табигый кабул итәләр. Ни өчен дип уйлыйсыз? Чөнки алар хәрәкәтле, җырлы-биюле халык уеннары белән үрелеп бара. Бу уеннарда һәр бала нинди дә булса бер роль башкара,үзен җаваплы, кирәкле кеше итеп тоя.

Уеннар тәрбия чыганагы да, баланың төрле яктан үсүенә дә йогынты ясый. Аларда катнашу баланың физик көче, җыр-биюгә осталыгын, сүз байлыгын арттырырга ярдәм итә. Күмәк эшләү, ярдәмләшү кебек уңай сыйфатларны үстерә. Ләкин бәйрәмнәрне көн дә үткәреп булмый. Аларны үткәрү зур хәзерлек һәм бик күп көч таләп итә. Ә теге яки бу бәйрәм турында белгәннәре балаларның хәтерендә ныгып калсын өчен соңгы вакытларда телгә өйрәтү максатында кулланылышка кереп баручы өстәл уеннары да сөйләм үстерүдә нәтиҗәле алым дип әйтә алам.

“Хәрәкәт”, “Сабантуй”, “Хәзинә” кебек өстәл уеннарын безнең студентлар да дөньяларын онытып уйныйлар. Бу уеннарны гадиләштереп балалар бакчаларында да кулланырга мөмкин. Менә бүгенге тема белән бәйләнгән берсен сезгә тәкъдим итәм. “Сабантуй” бәйрәме. Моны эшләүнең бер кыенлыгы да юк.

Халык тарафыннан кертелгән гореф-гадәтләр – шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Алар халыкның милли горурлыгын, милли аңын, хисләрен, рухын, көчен тәрбияләргә, формалаштырырга ярдәм итеп кенә калмый, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү тудыра. Үз милләтен хөрмәтләүче кеше тәрбияләүне халык педагогикасына таянып эш итү зарур.

Кулланылган әдәбият

1. Туган телем – бөек анам теле: татар балаларын ана теленә өйрәтү өчен тәрбиячеләргә методик кулланма – Яр Чаллы, 2004. – 127 б.
2. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма. – Казан: Фолиант, 2013. – 224 б.

Гарипова Ч.Р.
МБДОУ “Арский детский сад №9”

## МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫ ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮ НИГЕЗЛӘРЕ

Туган телгә өйрәтү шөгыльләренең үзенчәлеге шунда: алар башкалардан төп эшчәнлек булган сөйләүгә корылуы белән аерыла. Сөйләү эшчәнлеге акыл эшчәнлеге, акыл активлыгыбелән бәйле. Биредә балалар тыңлыйлар, уйлыйлар, сорауларга җавап бирәләр, үзләре сорау бирәләр, чагыштыралар, гомумиләштерүләр, нәтиҗәләр ясыйлар. Ягъни биредә бала үз фикерен сүздә җиткерергә өйрәнә. Балалар эчке яктан актив булалар. Мондый шөгыльләрнең нәтиҗәлелеге тәрбияченең ни дәрәҗәдә куелган максат һәм бурычларны тормышка ашыруда активлык күрсәтүенә һәм эшчәнлекне баланың сөйләм осталыгын үстерүгә юнәлдерүенә бәйле.

Туган тел шөгыленең төрләре.

Алар түбәндәгечә классификацияләнә.

1. Төп бурычларга бәйле рәвештә: сүзлек формалаштыру шөгыле, телнең грамматик төзелешенә өйрәтү шөгыле, сөйләмдә аваз культурасы тәрбияләү шөгыле, бәйләнешле сөйләмгә өйрәтү шөгыле, сөйләмгә анализ ясарга өйрәтүне формалаштыру шөгыле, матур әдәбият белән таныштыру шөгыле.
2. Күрсәтмә материал куллануга бәйле рәвештә.

а) табигый, чынбарлык предметлары кулланылучы;

б) уенчыклар, сәнгатьле сурәтләү чаралары кулланып;

в) күрсәтмәлелек кулланмыйча, сүз ярдәмендә генә узучы шөгыльләр.

3. Этапларга бәйле рәвештә:

– яңа күнекмәләр формалаштыручы;
– белемнәрне ныгыту шөгыле;
– белемнәрне гомумиләштерү шөгыле;
– гомумиләштерү, тикшерүшөгыле;
–катнаш шөгыль.

4. Телгә өйрәтүдә комплекслы шөгыльләрдә киң таралган. Улфикерләү һәм сөйләм үстерүдә төрле бурычларны берьюлы тормышка ашыруга корыла. Биредә балаларның телгә ия булуы гомум тел берәмлегеннән чыгып карала. Ягъни баланы берьюлы аваз культурасына да, бәйләнешле сөйләмгә дә, грамматик осталыкка да һ.б.ларга да өйрәтү карала.
5. Интегратив шөгыльләр дә игътибарга лаек. Биредә берничә шөгыль максатчан берләштерелә. Әйтик, сөйләмгә өйрәткәндә кошлар турында шигырь укып, кошларның яшәеше белән таныштырыла, рәсем ясарга яки җыр өйрәнергә мөмкин һ.б.лар.
6. Катнашучылар санышнан чыгып, шөгыльләр фронталь, группалы, индивидуаль була.

Сөйләм үстерү шөгыльләре түбәндәге дидактик таләпләргә җавап бирергә тиеш.

1. Шөгыльгә алдан ныклы әзерлек.
2. Материалның яшь үзенчәлекләренә туры килүе.
3. Шөгыльнең тәрбияви характерда булуы.
4. Эмоциональ характер да булу.
5. Шөгыльнең төзелеше төгәл булу.
6. Коллектив һәм индивидальэшләрнең чиратлашуы.
7. Шөгыльне дөрес оештыру.
8. Шөгыльнең алдагы башка сөйләм үстерү эшләре белән бәйле булуы.

Төрле яшь төркемнәренә карап та шөгыльләрнең эчтәлеге аерыла.

*Кечкенәләр төркемендәге* балалар коллективта шөгыльләнә белмиләр, бер-берсен тыңлыйсылары килми. Боларда шөгыльләр, нигездә, эмоциональ, уен характерында (сюрприз өлешләр булса да яхшы), күрсәтмәлелеккә бай булырга тиеш. Шөгыль нигездә, гади, подгруппалап, яки индивидуаль характерда. Тәрбиянченең соравына теләгән кеше генә җавап бирә.

*Уртанчылар төркемендә* тәрбия эшчәнлеге аерыла. Балалар үз сөйләмнәренә игътибарлы була башлыйлар. Эмоциональ сөйләмгә өйрәнәләр. Белем бирү бурычлары билгеләнә. Яңа төр шөгыльләр: экскурсия, сөйләргә өйрәтү, шигырь ятлау һ.б.лар кертелә. Шөгыль вакыты 20 минутка кадәр сузыла.

*Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемендә* шөгыльләрнең характеры үзгәрә. Сөйләү характерындагы шөгыльләр арта. Балалар сорау-җавап бирергә, сөйләргә, үзләре сорау бирергә өйрәнәләр. Күрсәтмәлелекнең роле, эчтәлеге байый, картиналар, лексик күнегүләр, сүзле уеннар арта. Тәрбиянченең роле үзгәрә. Ул хәзер шөгыль белән идарә итүче һәм балаларны сөйләмгә җәлеп итүче.

*Катнаш төркемендә* балалар белән эшләү бергә алып барыла. Кечкенәләр белән зурракларның бурычлары бер-берсеннән аерыла. Кечкенәләр алданрак китә. Алар булганда гади эшләр башкарыла. Сорауларга зурраклар җавап бирә. Әмма тәрбияче балаларның яшен конкрет белергә тиеш.

Озак еллар педагогикада махсус сөйләмгә өйрәтү шөгыльләре кирәк түгел дигән бәхәсләр барды. Әмма бары бу төр шөгыльләрдә генә конкрет сөйләмгә өйрәтү осталыгына, бәйләнешле сөйләмгә өйрәтү тормышка ашырыла. Балалар бакчасы педагогы гомумдидактик, методик принципларга тәңгәл килгән шөгыльләрне алып бару методикасы белән яхшы таныш булырга, балаларга тәсир итү осталыгына ия булырга тиеш.

Гатиятова Л.Л.
пгт. Васильево, МБДОУ "Детский сад общеразвивающего вида №36 "Сосенка" Зеленодольского муниципального района РТ", воспитатель по обучению татарскому языку

## СПОСОБЫ ВОВЛЕЧЕНИЯ ДЕТЕЙ ДОШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА В ПРОЦЕСС ИЗУЧЕНИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

**Аннотация:** Раннее овладение языком имеет большое значение для развития детей. Детский сад играет важную роль в формировании языковых навыков и погружении в культуру. Важно создать комфортное языковое окружение с разнообразными материалами на татарском языке. Одно из таких пособий для обучения - «Алифба», которая помогает детям усваивать материал

с помощью иллюстраций и загадок, формирует национальные ценности, а в условиях межкультурного взаимодействия воспитывает у подрастающего поколения чувство толерантности по отношению к представителям других культур. В общении и игре также важно использовать родной язык, чтобы активно развивать владение им. Обучение детей татарскому языку в детском саду является неотъемлемой частью национального образования и важным шагом на пути сохранения татарской культуры. Оно дает возможность детям с самого раннего возраста овладеть вторым языком, что поможет им в будущем как в личной, так и в профессиональной жизни.

**Ключевые слова:** языковое окружение, «Алифба», татарский язык, ценности, билингвизм.

В современном обществе большое значение придается овладению ребенком родным языком с самого раннего возраста. Детский сад играет непосредственную роль в формировании языковых навыков и способностей детей, так как первые годы жизни ребенка – это время, когда его мозг активно принимает информацию и быстро обучается. Программа обучения татарскому языку в детском саду разработана с учетом их психологических и возрастных особенностей. В рамках этой программы дети не только учатся говорить и понимать татарский язык, но и погружаются в культуру татарского народа, знакомятся с его традициями, обычаями и историей. Поэтому создание условий, способствующих вовлечению ребенка в образовательный процесс на родном языке, становится важной задачей для педагогов и родителей.

Одним из ключевых аспектов является создание комфортного языкового окружения. В детском саду следует обеспечить наличие разнообразных

материалов на родном языке: книги, плакаты, игры и игрушки с языковыми элементами. Это поможет создать непринужденную атмосферу, в которой ребенок будет чувствовать себя уверенно и заинтересованно в изучении языка.

Одним из таких учебно-развлекательных пособий для занятий с дошкольниками может служить «Алифба» Вагизова С.Г. и Валитовой Р.Г..
«Алифба» является учебным пособием, предназначенным для начального обучения грамоте. Он представляет собой некий нарратив с уникальными чертами и характеристиками народа. Одновременно, учебник нацелен на расширение коммуникативных практик и обогащение культурного опыта. Преимуществом использования «Алифбы» в обучении детей дошкольного возраста является большое количество наглядного материала, иллюстраций, загадок, что, безусловно, помогает в усвоении материала детьми.

Так как жизненный опыт ребенка невелик, ему сложнее воссоздать в своем воображении то, о чем повествует писатель. Иллюстрация способствует пониманию ребенком текста, формирует представление о его теме, идее, персонажах, содержит в себе оценку событий и героев литературного действия. Для самых маленьких детей рисунок играет роль основного материала, является той действительностью, которую нельзя заменить словесным описанием. Значительная часть иллюстрации отражает культуру татарского народа: на картинках изображены персонажи в национальных костюмах, символика Республики Татарстан, национальные блюда. Все это формирует национальные ценности, вызывает интерес к своеобразию и самобытности культуры, а в условиях межкультурного взаимодействия воспитывает у подрастающего поколения чувство толерантности по отношению к носителям других языков.

Загадки обогащают словарный запас детей за счет многозначности слов, формируют представления о переносном значении. Они помогают усвоить звуковой и грамматический строй речи, заставляя сосредоточиться на языковой форме и анализировать ее.

Особое внимание в «Алифбе» уделено произношению букв, слогов. Для детей значительно удобнее читать по слогам длинные слова, которые им пока неизвестны. Также детям проще писать и копировать слова, диктовать себе по слогам, чем по буквам, слоги проще запоминаются, они легче воспринимаются как часть целого слова.

Помимо языкового окружения, необходимо активно привлекать ребенка к использованию татарского языка в общении и игре. Создавая для него ситуации, в которых татарский язык является основным средством общения, мы помогаем ему не только активно учиться и развиваться, но и создаем базу для дальнейшего овладения языком. От простых игр-головоломок до интерактивных приключений, существует множество возможностей использования игр для улучшения навыков языка. Игра не только делает процесс обучения более занимательным, но и обеспечивает активное вовлечение учащихся. Стимулируя их к самостоятельным действиям, подход через игру воздействует на различные типы обучения, такие как зрительное, слуховое и подвижное обучение. Дети

непринужденно осваивают татарские слова, фразы и предложения, даже не осознавая своего обучения. Благодаря этому, они легче осваивают правильное произношение особенных звуков татарского языка. Ребенок получает удовольствие от самых игровых действий и стремится играть снова и снова. - Дидактические игры для обучения татарскому языку помогают создать позитивное отношение к языку, улучшают общую работоспособность и позволяют закрепить пройденный материал разнообразными способами. Благодаря играм, учащиеся становятся более свободными и уверенными в использовании татарского языка, что открывает для них новые возможности культурного обмена и понимания окружающего мира. Поэтому игра является идеальным инструментом для освоения татарского языка в увлекательной и эффективной форме.

Обучение детей татарскому языку в детском саду является неотъемлемой частью национального образования и важным шагом на пути сохранения татарской культуры. Оно дает возможность детям с самого раннего возраста овладеть вторым языком, что поможет им в будущем как в личной, так и в профессиональной жизни. Ведь как известно, у человека, который с детства привык говорить на двух языках, формируется особая когнитивная способность: он может легче ориентироваться в меняющейся ситуации, быстрее принимать решения. Владение двумя языками благоприятно влияет на мозг: билингвизм делает ум гибче, развивает креативное мышление и память.

Список использованных источников


1. Иллюстрации в детской книге, ее особенности и роль в развитии ребенка дошкольного возраста | Статья: | Образовательная социальная сеть (nsportal.ru) (дата обращения: 12.10.2023).
2. Кучурина, М. А. Формирование национальных ценностей в учебно-воспитательном процессе (на примере национального костюма) / М. А. Кучурина. — Текст : непосредственный // Молодой ученый. — 2014. — № 19 (78). — С. 569-571. — URL: https://moluch.ru/archive/78/13646/ (дата обращения: 14.10.2023).



Загафарова Г.Ф.
МБОУ” Сизинская ООШ”
Арского муниципального района РТ,
учитель начальных классов


## РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРНЫ ТАТАР СӨЙЛӘМЕНӘ ӨЙРӘТҮ


**Аннотация:** В статье поднимается тема использования коммуникативных технологий, дидактических заданий при обучении татарскому языку. Такие технологии решают проблему понимания национальной культуры и мотивации детей к урокам. В учебно-воспитательном процессе, в первую очередь, большую роль играет отношение между учителем и учеником. Дети, изучая новый

материал, общаются между собой и учителем, глубже усваивают заданную тему. В процессе преподавания ставится цель, чтобы развить познавательную работоспособность и самостоятельность каждого ученика, сделать урок проведенный запоминающимся.

**Ключевые слова:** коммуникативный, компетенция, технология,общение, национальная; коммуникативные технологии, дидактические игры, познавательные навыки, учебно-воспитательный процесс, родной язык, татарский язык.

**Abstract:** The article raises the topic of the use of communicative technologies, didactic tasks in teaching the native language. Such technologies solve the problem of understanding the national culture and motivating children to lessons. The article raises the topic of the use of communicative technologies, didactic tasks in teaching the native language. Such technologies solve the problem of understanding the national culture and motivating children to lessons. In the educational process, first of all, an important role is played by the relationship between teacher and student. Children, learning new material, communicate with each other and the teacher, deeper assimilate a given topic. In the process of teaching, the goal is to develop cognitive performance and independence of each student, to make the lesson memorable.

**Key words:** communicative, competence, technology, communication, national; communicative technologies, didactic games, cognitive skills, educational process, native language.

Мин 33 ел инде башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшлим. Үземнең хезмәтемдә Сәләй Гататдин улы Вагыйзовның һәм Рәмзия Гыйләҗетдин кызы Вәлитованың “Башлангыч сыйныфларда татар телен укыту методикасы” китабын һәм уку-укыту ярдәмлекләрен еш кулланам. Аларга мондый бай хәзинә калдырганнары өчен рәхмәтем һәм хөрмәтем чиксез.

Мин авыл мәктәбендә укытам. Авылда балалар саны елдан-ел кими бара. Булганнарының да күпчелеген күченеп килгән чит милләт вәкилләре тәшкил итә. Алар рус телендә аралашалар. Хәзер авылда да татар балалары рус телендә сөйләшә. Бу проблема балалар бакчаларына төрле милләт балаларының йөрүе һәм аларның рус телендә аралашуыннан килеп чыгадыр дип уйлыйм мин. Балалар бакчасында русча аралашкан бала өйгә кайткач та, ни өчендер, әти-әнисе белән русча сөйләшә башлый. Әти-әни дә кисәтү ясамый, балага кушылып русча җавап бирә. Бүгенге көндә татар баласын татарчага өйрәтү проблемасы да килеп туа. Дәресләрдә балалар сүзнең русчасын белә, татарчасын белми. Кызганыч, татар балаларын да чит милләт балалары белән бергә үз теленә өйрәтергә туры килә.

Татарстан Республикасында гомуми белем бирү системасының төп бурычы-полилингваль шәхес тәрбияләү. Билгеле булганча, рус һәм чит милләт балалары өчен татар теле икенче тел, чит тел. Ә икенче телгә өйрәтү-катлаулы

һәм үзенчәлекле эш. Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен укытуның төп максаты- коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы ) булдыру, телне аралашу чарасы буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру. Татар телен дәүләт теле буларак укыту укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның аралашу культурасын формалаштыру чарасы, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру чарасы.

Рус һәм чит милләт балаларына татар теле укытуның төп максаты – аларны бу телдә сөйләшергә, тыңлап аңларга, укырга һәм язарга, сүзләрне дөрес әйтә белергә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру. Моның өчен тиешле шартлар булдыру – укытучының мөһим бурычы. Укучыларның татар телен тирәнтен үзләштерүе өчен укытучыларга рус һәм чит милләт балаларында да телгә кызыксыну уятырга, сөйләм телен шомартыр өчен, дәресләрне кызыклы итеп үткәрергә, төрле алымнар кулланып эшләргә кирәк. Шуңа күрә укучыларның яшь үзенчәлекләрен искә алып һәм дәрестә төрле алымнар кулланып, аларны актив сөйләмгә тартырга тырышам. Иң беренче чиратта, аларда телне өйрәнү теләге уятырга тырышам. Һәр дәресне башлар алдыннан һава торышы, укучыларның кәефләре турында әңгәмә оештырам, дежур укучы белән әңгәмә корам.

Безнең бурыч – балаларның үтелгән темаларны, өйрәнелгән материалны үзләштереп баруларына ирешү; татар теленә генә хас булган авазларны дөрес кулланып, җөмләләр төзергә өйрәтү; сорау җөмләләрне аңлап, дөрес җавап бирүләренә ирешү; җөмләдә исем, сыйфат, фигыль һ.б. сүз төркемнәрен, зат, сан, килеш кушымчаларын дөрес кулланырга өйрәтү. Моның өчен дәресләрдә сөйләгәнне тыңлап аңлау; диалог-монологлар төзү; ситуатив, коммуникатив биремнәр үтәү; текстларны укып, эчтәлеген аңлап сөйләү, тәрҗемә итү; дөрес язу күнекмәләрен булдыру; текстлар күчереп язу; диктант язу; хаталарны төзәтү; биремнәр эшләү; язма эшләр, тестлар уздыру өстендә эшләргә тиешбез. Яшь үзенчәлекләрен истә тотып, дәресне оештыруның төрле алымнарын кулланып, балаларны мөмкин кадәр активрак сөйләмгә тартырга тырышырга кирәк. Сөйләм осталыгын үстерүдә һәм дөрес итеп сөйләргә өйрәтүдә уеннар зур әһәмияткә ия. Уен барышында укучылар сүзләрне күмәк кабатлыйлар, яңа сүзләрне дөрес әйтергә өйрәнәләр, бер – берсе белән аралашалар. Дәресләрдә “Могҗизалар кыры”, “Ватык телефон”, “Дәвам ит, сүз төзе, сүз уйла” уеннары уздырам. Алар укучыларның сүзлек байлыгын арттыра. Сюжетлы рәсемнәрне, картиналарны да еш кулланам. Чөнки рәсем, картина баланың хисенә тәэсир итә, сөйләмдә образлы сүзләр кулланырга булыша. Рәсемгә карап хикәя төзү – иҗади эш. Бу безнең дәресләрдә шактый урын ала. Һәр дәрес башында фонетик күнегүләргә урын бирергә кирәк. Фонетик һәм лексик күнегүләр, авазларны, сүзләрне дөрес әйтү күнекмәләре, артикуляция өчен күнегүләр –барысы да һәр дәрестә башкарылырга тиеш. Сөйләмнең яңгырау шартларының төрлелеге (аудиоязма, радио, телевизор, музыка астында тыңлау, балаларның үзләрен тыңлау һ.б.) максатка яраклырак булачак.

Рус һәм чит телле балаларны татар теленә өйрәтүдә рольле уеннар актив кулланыла торган ысул булып торалар. Укучыларның дәрес белән кызыксынуы арта, тел һәм сөйләм материалын өйрәнү дә файдалырак була.Рольле уенда парлап һәм төркем составында да катнашырга мөмкин. Бу вакытта сөйләмгә һәм аңа бәйле булмаган хәлдә дә катнашучылар бер-берсенә йогынты ясыйлар.

Балаларда, табигый рәвештә нәрсәдер әйтү, нәрсә турында булса да сорау ихтыяҗы яки әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа. Уеннар вакытында укучыларның белем һәм күнекмәләре камилләшә. Аларда бердәмлек, бер-берсенә ярдәм итү теләге туа. Балалар уен вакытында шатланырга, эшләгән эшләреннән риза, канәгать калырга тиешләр. Уен барышында укучыларның сәләтләрен үстерү өстендә дә эшләргә кирәк. Дәресләрне болай оештыру татар телен өйрәнүгә карата кызыксынуны көчәйтә, балаларның активлыгын арттыра.

Рус балаларына татар телен өйрәткәндә ике телнең дә үзенчәлеген истә тоту зарур. Мәсәлән, татар телендә рус телендәге вид, род, предлог, приставка күренешләре юк. Ә аларга тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу өйрәткәндә игътибар ителә.Укыту барышында текстларда, күнегүләрдә очрый торган яңа сүзләр аңлатыла, шул ук вакытта элек үтелгән-үзләштерелгән сүзләрнең яңа формалары да өйрәнелә.

Укучылар тема буенча җөмләләр төзеп кенә калмыйча, төрле күренешләр хакында үз фикерләрен әйтә белергә һәм аны исбатлый алырга тиеш. Дәресләрдә тәрҗемә эшләренә дә зур урын бирәм. Чөнки рус теленнән татар теленә дөрес итеп тәрҗемә итү бәйләнешле сөйләмнең барлык формаларына ия булуны сорый.

Укучыларда дәресеңә нык кызыксыну уятканда гына, аларның сөйләм телен үстерергә мөмкин. Укытуны дәрес-викторина, дәрес-ярминкә, дәрес-экскурсия, дәрес-бәйрәм, тәрҗемәчеләр конкурсы, КВН, кроссвордлар чишү-үзләре төзү кебек дәрес төрләре белән баету, әкиятләргә пантомимолар эшләү, үзлекләренннән ребуслар төзү, бирелгән сүздән яшерелгән сүзләрне эзләү кебек чаралар куллану дәреснең нәтиҗәлелеген нык арттыра. “Кем миллионер булырга тели?” уенын сүзлек өстендә эшләгәндә уйнарга була.

Дәрестә “Сабыйга”, “Салават күпере”, “Сабантуй” журналлары, “Мәгариф” журналларындагы материаллардан файдалану да отышлы.

Җырлар да дәресне төрләндереп җибәрә, балалар татарча җырларга, чараларда катнашырга бик теләп ризалашалар. Журналистлар булып, төрле темаларга интервьюлар алу да ошый аларга.

Рус, чит милләт, татар балалары белән берлектә дә, дәрестән тыш чаралар үткәрү шулай ук кызыклы. Бу бәйрәмнәрдә алар үзләренең матур итеп җырлый, бии, сәнгатьле итеп сөйли белү осталыгына ия булуларын күрсәтәләр.

Татар халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итү, төрле йола-бәйрәмнәрне үткәрү, татар халык уеннары белән таныштыру – шулай ук бик әһәмиятле.

Сөйләмнең диалогик формасы аралашуда күбрәк очрый һәм сөйләм эшчәнлегенең башка төрләрен тулыландыруны да үз эченә ала. Балаларның тыңлап аңлау һәм монологик сөйләм күнекмәләре дә камилләшә. Һәрбер дәрес укучының сөйләм телен үстерергә тиеш. Мәсәлән, дәрес материалында диалог

бирелгән. Укучылар аны күз йөртеп яисә кычкырып укып чыгалар, бер укучы монолог итеп сөйли, аннары төп фикерне ачыклыйбыз һәм төркемнәрдә эш башлана: төп тема буенча фикер алышалар. Бу эшне тексттан соң да үткәрергә була. Укучылар үзләренең фикерләрен әйтәләр, нәтиҗәләр ясыйлар. Укыту дәверендә дәреслек һәм сүзлек белән эшләүгә аеруча зур урын бирәм. Яңа сүзләр белән җөмләләр төзетәм. Тестларга зур әһәмият бирәм.

Балаларга татар теле укыту методикасын чит ил телләрен өйрәтү ысуллары белән туры китерергә тырышам. Татар теленең аралашу өчен кирәклеген аңлатам. Татар язучыларының, шагыйрьләренең иҗатлары турында да мәгълүмат биреп торам. Районыбыз язучыларын һәм шагыйрьләрен дә онытмыйм. Алар турында мәгълүмат бирәм. Рус һәм чит телле балаларда татар теленә, сәнгатенә, мәдәниятенә, тарихына хөрмәт хисе тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү максатыннан, программа нигезендә дәресләр, чаралар үткәрәм, вакытлы матбугат материаллары белән таныштырам. Укучылар үзләре дә бик теләп мәкаләләр язалар.

Йомгак итеп шуны әйтеп була, әгәр укытучы дәресләрендә тиешле алымнар кулланса, төрле уен ситуацияләре, сөйләм күнегүләре, коммуникатив технология элементларын дөрес файдалана белсә, ул, һичшиксез укучыларның татар телендә камил сөйләшүенә ирешәчәк.

Нәтиҗәдә, рус һәм чит милләт балалары татар телен яратып, дәресләрдә теләп укыйлар, актив катнашалар, татар телен өйрәнергә тырышалар. Район күләмендә уздырылган чараларда актив катнашалар.

Кулланылган әдәбият

1. Әсәдуллин А.Ш. Татар сөйләме: 5 нче с-ф: Рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләүче укытучылар өчен. – Казан: Мәгариф, 2002. - 231 б.
2. Габдинова З. Заманча технологияләр кулланып // Мәгариф. – 2014 - № 5.
3. Харисов Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан, “Мәгариф” нәшр., 2002. – 267-268 б.
5. Хайдарова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М. Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту. – Яр Чаллы, 2015. -52б.
6.

Марданова Л.И.
Муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениясе
«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган урта гомумбелем бирү мәктәбе»,
башлангыч сыйныф укытучысы

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭШ ТӨРЛӘРЕ

Аннотация: Соңгы вакытларда укытучылар алдында торган актуаль сорауларның берсе - бүгенге шартларда укучыларга татар телен ничек нәтиҗәле

итеп укытырга соң? Укытучы әйткәнне генә эшләү укучыларны ялыктыра, кызыксынуларын киметә. Гадәти булмаган алымнарның кайберләре – «Эш бите» һәм интеллект карта. «Эш бите» - укучының мөстәкыйль уку эшчәнлеген оештыруның дидактик чарасы; ничек һәм нәрсә эшләргә кирәклеге турында биремнәр язылган бит. Интеллект карта - мәгълүматны график рәвештә күрсәтү, аны истә калдыруның уникаль һәм гади ысулы. Укучылар мондый төр биремнәрне бик теләп һәм актив рәвештә башкаралар, эзләнәләр, уйланалар; болар барысы да укучыларның иҗат итү мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итә.

Ачкыч сүзләр: «Эш бите», интеллект карта

Безнең бистәбездә төрле милләт вәкилләре яши. Аларның гореф-гадәтләре, диннәре, телләре төрле. Ләкин алар барысы да татар телен өйрәнә. Кемдер бик теләп, күңелен биреп өйрәнә, эти-әнисе дә каршы килми. Ә кайбер баланың өйрәнәсе килми. Шуңа күрә һәр балада телгә карата мәхәббәт, хөрмәт уятырга кирәк дип саныйм мин. Укучыларымның киләчәге мине борчый. Алар киләчәктә нинди булырлар? Мин биргән белемнәр аларга тормышта кирәк булырмы? Нәрсә генә булмасын, нинди генә үзгәрешләр кертелмәсен, башка телне өйрәнү, аның серләренә төшенү, ул телдә аралаша алу – зур дәрәҗә.

Соңгы вакытларда укытучылар алдында торган актуаль сорауларның берсе - бүгенге шартларда укучыларга татар телен ничек нәтиҗәле итеп укытырга соң? Телевидение, интернет, компьютер программалары белән аралашып үскән замана баласын ничек итеп кызыксындырырга? Нинди ысуллар кулланырга?

Безнең алда бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу булса; икенчедән, балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, кызыксынуны үстерү бурычы. Болар барысы да укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булу, иҗади эшчәнлекне, арттыруны сорый. Һәрбер баланың татарча сөйләшә алуына ирешү өчен без ана телендә мультфильмнар карыйбыз, хикәяләр, әкиятләр укыйбыз, эчтәлеген сөйлибез, сюжетлы-рольле, хәрәкәтле һәм түгәрәк уеннар уйныйбыз. Җырлар өйрәнәбез, шигырьләр ятлыйбыз. Картиналар буенча хикәяләр төзергә өйрәнәбез. Сәнгатьле сөйләм, кычкырып уку, хикәя төзеп сөйләү кебек эшләрне башкарганда авазларны дөрес әйтүне беренче урынга куябыз.

Балаларның төп эшчәнлеге уен. Балага белем һәм тәрбия уен аркылы аеруча кече яшьтән әйбәт бирелә. Уйнаган вакытта бала күп нәрсә таный, күнекмәләр ала. Шулай ук укытучы, белем һәм тәрбия бирү бурычын алда тотып, тел дәресләрендә балаларның уеннарын максатка ярашлы итеп оештырырга тиеш. Уен баланың шул фән белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйльлеген, ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, зирәклеген, тапкырлыгын, фикер активлыгынһәм зиһеннәрен үстерүдә ныклы этәргеч булып тора;аны милли бердәмлек рухында тәрбияли, билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә.

Дистәләгән еллар дәвамында Сәләй Вәгыйзовның татар телендә төзегән “Әлифба” сы, уку китаплары, татар теле дәреслекләре, «Рәсемле әлифба», «Кызыклы грамматика» китаплары, методик кулланмалары укытучылар тарафыннан хәзерге көндә дә киң кулланыла.Укытучыларга мирас итеп калдырган методик әсбаплары, “Кызыклы грамматика” китабындагы эш алымнары да бик күп төрле. Шундыйларның кайберләре: дидактик уеннар, грамматик уеннар, проблемалы мәсьәләләр чишү, мавыктыргыч күнегүләр, теге яки бу тел фактын тануга корылган экиятләр, мәзәкләр; башваткычлар, табышмак сораулар, мәкальләрне дәвам итү, логик, стилистик күнегүләр, метаграмма, анаграмма, логограммалар, логогрифлар, шарадалар.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Заман таләпләре татар телен укыту процессында да зур үзгәреш кертүне, яңа эш төрләрен куллануны таләп итә. Тәҗрибә педагогик эшчәнлекнең нигезе булса, яңалыкка омтылу - үсеш - үзгәрешне тәэмин итә. Бүген укытучы, иҗади шәхес буларак, күп укырга, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныш булырга гына түгел, ә яңа эш төрләренең иң нәтиҗәлесен сайлап алып, үзләштереп эшли белергә дә тиеш.

Укытучы әйткәнне генә эшләү укучыларны ялыктыра, кызыксынуларын киметә. Шуңа күрә мин дәресләремдә гадәти булмаган алымнарны кулланып эшләргә тырышам. Шул алымнарның берсе – «Эш бите». «Эш бите» - нәрсә ул? Эш бите - дәрес материалын өйрәнү нәтиҗәләре буенча укучының мөстәкыйль уку эшчәнлеген оештыруның дидактик чарасы. Ул - ничек һәм нәрсә эшләргә кирәклеге турында биремнәр язылган бит, анда теоретик материал да күрсәтелә. Бу материалны аңлату барышында яки теманы өйрәнгәннән соң башкарылырга тиешле биремнәр белән укытучы тарафыннан махсус эшләнгән бит. «Эш бите» ярдәмендә һәр бала уку процессында актив катнаша. Аның төп бурычы - балага уку процессының кызыклы да була алуын күрсәтү. Эш бите ярдәмендә дәрестә уку материалы белән бергә мөстәкыйль эш оештырырга да, дәреснең теләсә кайсы этабында укучыларның эшчәнлеген активлаштырырга, кире элемтә алырга да мөмкин.Эш битендә нинди биремнәр булырга мөмкин? Эш битләре-яңа ситуацияләрдә белемнәрне анализлау, чагыштыру, куллану күнекмәләрен таләп итүче биремнәр. Белемнәрне контрольдә тотуга яки актуальләштерүгә юнәлдерелгән аерым тема яисә бүлек буенча төзелгән төрле катлаулылыктагы биремнәр була ала. Алар ярдәмендә материалның теоретик нигезләре төрле практик биремнәр мисалларында өйрәнелә. Укучылар үзләре белем дә алалар һәм үз нәтиҗәләрен дәреслек яки башка чыганаклардан алынган теоретик мәгълүматлар белән чагыштыралар да. Эш бите биремнәре дәрес материалларын тулыландырып кына калмый, үзләштерү процессын нәтиҗәлерәк итәргә дә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, дәрес барышында ук битне тутыру теоретик белемнәрне шунда ук практик формада күзалларга ярдәм итә. Эш битенә тема турында күбрәк мәгълүмат өстәргә була, анда укучылар үзләре өчен яңа

мәгълүмат табачак, бу үз чиратында предметка кызыксынуны арттырачак һәм уңышлы укуга этәргеч була.

«Эш бите» укытучының эшендә нәтиҗәле алым да булып тора, шул ук вакытта балаларга белем бирүне җиңеләйтә һәм мавыктыргыч та итә.

Хәзерге буын укучылары белемне үзлегеннән ала белергә; аларны практикада кулланырга; төрле мәгълүмат белән эшләргә, аны анализлый һәм гомумиләштерә белергә тиеш. Дәресләрдә киң кулланылучы икенче алым – интеллект карта төзү. Әлеге алым уку һәм белешмә материаллар белән мөстәкыйль эшләргә өйрәнергә, танып белү активлыгын үстерергә ярдәм итә. Интеллект карта - мәгълүматны график рәвештә күрсәтү, аны истә калдыруның уникаль һәм гади ысулы. Дәресләрдә аларны куллану кече яшьтәге мәктәп укучыларының укыту процессын кызыклырак итәргә ярдәм итә, чөнки карта төзү белән уен күп кенә уртаклыклары булган гадәти булмаган эшчәнлек төре. Интеллект карталарны төрле темалар буенча һәм төрле дәресләрдә төзергә мөмкин. Эш барышында балалар үзләре экспериментлар ясый, карталарның төрле формаларын, шартлы билгеләрен, рәсемнәрен уйлап таба ала. Интеллект картасы агач схемасы рәвешендә ясала. Үзәк образдан барлык юнәлешләргә нурлар тарала. Нурлар өстендә ачкыч сүзләр язалар яки бер-берсенә тармакланучы сызыклар белән тоташтыручы образлар ясыйлар. Мондый язма интеллект картаны даими рәвештә тулыландырырга мөмкинлек бирә. Эшләгәндә төсле карандашлар һәм фломастерлар кулланыла. А4 бите горизонталь рәвештә урнаштырыла. Төп проблема (тема) битнең үзәгендә урнаша. Үзәктә төп тармак ясыйбыз, алар калын булырга тиеш. Һәр төп тармакның үз төсе булырга тиеш. Икенче, өченче һ.б. иярчен тармаклар төп тармаклар белән тоташалар, алар нечкәрәк итеп ясала. Аларны кыеграк итеп ясау отышлырак. Һәр тармак өстендә төп сүзләр басма хәрефләр белән языла. Истә калдыру һәм үзләштерү өчен һәр сүз турында рәсемнәр куллану яхшы.

Интеллект карталары белән дәреснең һәр этабында эшләргә мөмкин. Төп сүз теманы фаразларга һәм дәрес биремнәрен ныгытырга булыша. Яңа белем ачу дәресендә карта тикшерү процессы дәвамында тутырыла. Белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү вакытында балалар берничә төп сүз алалар, аннары аларны тутыралар. Белемнәрне контрольдә тоту этабында төрле дәрәҗәдәге индивидуаль карталар буенча эшләргә мөмкин. Уку процессында кыенлыклар кичергән балаларга ярдәмче сүзләр язылган карталар тәкъдим ителә. Карталар ярдәмендә балалар мәгълүматны җиңелрәк истә калдыралар һәм классификациялиләр.

Интеллект карта - иҗади эшләргә, мөстәкыйль фикер йөртә белергә өйрәтүдә куллану өчен отышлы алымнарның берсе. Укучылар мондый төр биремнәрне бик теләп һәм актив рәвештә башкаралар, эзләнәләр, уйланалар. Болар барысы да укучыларның иҗат итү мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итә.

Ялыткыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә, иҗади эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа эш төрләрен, алымнарны өйрәнү һәм дәрестә куллану мөһим.

Кулланылган әдәбият


1. С.Г.Вагыйзов, Р.Г. Вәлитова “Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы” – Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2001 – 343 бит
2. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика: Укытучылар өчен кулланма. - Тулыл. 3нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 207 б
3. Альмиева Р. М. Ролевая игра как средство развития фантазии и творчества учащихся // Творческая активность учащихся: поиск, находки, проблемы. – Казань, 1995. – С. 164-169.
4. Саттарова Н. Шәхесне тәрбияләүдә уен // Мәгариф. – 2004. - № 2. – Б. 42-44.



Минсадыкова Рузиля Флюровна

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение “Средняя общеобразовательная школа № 33” города Набережные Челны Республики Татарстан


# ВОВЛЕЧЕНИЕ УЧАЩИХСЯ НА ИЗУЧЕНИЕ РОДНОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ ЧЕРЕЗ ТВОРЧЕСКУЮ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ


**Аннотация:** В статье прослеживаются основные направления творческой деятельности учащихся на уроках родного языка и литературы, во внеклассных мероприятиях. Это - формы творческих работ при изучении грамматики, при анализе литературных текстов, при организации занятий в кружках, во внеклассных мероприятиях. Практическая значимость статьи заключается в возможности применения методов работы для повышения интереса у школьников в изучении родного языка и литературы..



**Ключевые слова:** способы мышления, творческий потенциал, “Волшебное перо”, “Занимательная грамматика”, родной язык.


Кешелек дөньясы яралганнан бирле зур ачышлар ясала. Галәмдә планеталар табыла, химик элементлар ачыла, географик офыклар киңәя, хайван, үсемлекләр дөньясы ишәя, төрле сортлар яңартыла, техник казанышлар күбәя. Табигатьтә иң өйрәнелмәгән һәм дә ачылмаган дөнья - кеше шәхеседер, мөгаен. Кеше бу дөньяга аваз салганнан алып гомер азагына кадәр үз-үзен өйрәнү юлын кичерә. Шәхси мөмкинлекләрне ачуда иң зур бурычлы затлар – ата-аналар, алардан кала иң төп юнәлеш бирүчеләр – тәрбияче, укытучылар. Мәктәп бусагасын атлап чыгуга, кичәге укучыны тормыш дигән дөнья көтә. Тормыш корабы үзенә, бик теләп, иҗади потенциалы бай булган, фикерли белә торган

шәхесләрне утырта. Әйләнә- тирәгә яраша белмәгән, төрле ситуациядә югалып калу мөмкинлеге зур булган яшьләр тормыш дулкыннары әз генә чайкалды исә абынырга, егылырга, хәтта төшеп калырга мөмкиннәр.

Мин, замана мәктәбенең бер укытучысы буларак, шәхес үсешенә ничек йогынты ясый алам соң? Нинди иҗади алымнар белән кеше формалашуына дөрес этәргеч бирә алам? “

Кеше борын заманнан ук балаларны ана теленә өйрәткән, аның телен шомартуга, сүзлек хәзинәсен арттыруга, сөйләгәндә һәм язганда, аннан оста файдалануга бик нык игътибар иткән.

Ана, баласына “тел ачкычы” бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уеннар оештырган: үсә төшкәч, такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән, бәетләр әйткән, экиятләр сөйләгән.

Баланың үзлектән тел өйрәнү буенча беренче коралы, әлбәттә, - Әлифба китабы. Минем буын - тел белгече Сәләй Вагизов әзерләгән Әлифба китабыннан укырга һәм язарга өйрәнгән буын. Шушы хезмәте өчен генә дә халкым бу галимгә бик рәхмәтле. Әмма язу, уку күнекмәләре белән коралланган балаларга алга таба тел өйрәтү серләрен дә үз хезмәтләрендә бәян итеп калдырган Сәләй Гататович.

Әлифба авторы Сәләй Вагыйзов әлифбадан тыш яңадан кырыктан артык китап һәм дәреслек язган. Күбесен Рәмзия Вәлитова белән берлектә. “Кызыклы грамматика” дигән китабы үз авторлыгында басылган. Сәләй Вагыйзов балага белем һәм тәрбиянең аеруча үтемле итеп уен аркылы бирелгәнлеген яхшы аңлаган. Уйнаган вакытта бала күп нәрсә таный, күнекмәләр ала.

Сәләй Вагыйзовның хезмәтләре балаларга туган тел һәм әдәбиятын укытуда кызыксындыру чарасы буларак әле дә актуаль.

Дөнья үсештә: сәясәт үзгәрә, фәнгә караш, эшкә таләпләр үзгәрә, укучылар үзгәрә. Әмма предмет, аның эчтәлеге әллә ни үзгәреш кичерми. Бары аны бирү юллары, чаралары гына үзгәрә. Профильле укыту оештырылгач, математик, информацион – технологик, экологик юнәлешләр өстенлек иткән мәктәптә татар теле һәм әдәбияты статусын саклау, укучыларның әлеге предметларга карата кызыксынуларын сүндермәү – төп бурычларымның берсе. Мәктәп стеналарыннан филолог, укытучы, журналист, язучы әзерләү (хыялда булса да) – беренчел максатларым түгел. Ә менә балага олы тормышта үз урынын табарга, төрле ситуацияләрдә югалып калмаска, милләтнең ышанычлы вәкиле булырга ярдәм итү – төп уем. Укучыларны туган тел һәм әдәбиятын өйрәнүгә кызыксындыру, фикерләү сәләтләрен үстерү буенча эш төрләрен өчкә бүләм.

Беренче юнәлеш. Тормышта үрнәк алырдай позитив әйберләр аз булган бу заманда әдәбият иң кулай тәрбия чарасы булып кала бирә. Төрле клублар, интернет челтәре дә, мавыктыргыч телевидение дә матаур әдәбият биргән матурлыкны алыштыра алмый. Әдәбият дәресләрендә мин, иң беренче чиратта, балага һәр предмет өчен кирәкле фикерләү ысулларын өйрәтүне максат итеп

куям. Уйлый белмәгән бала белән әдәби әсәргә анализ ясау, аның турында сүз алып бару мөмкин түгел. Төртеп күрсәткәнне уку, укыганны сөйләү – уйлау түгел. Чагыштыра, гомумиләштерә, тарката алган һәм башка фикерләү ысулларын куллана белгән укучы гына әдәби әсәрнең темасын, идеясен табу кебек нәтиҗәләргә килә ала.

Әдәбият дәресләрендә иҗат итәргә өйрәтүнең кайбер формалары:

- төрле халык музыкаларын тыңлау һәм аны рәсемгә төшерү;
- шигъри форманы сөйләм теле белән язу;
- драма әсәрен хикәя рәвешендә яки, киресенчә, хикәяне драма әсәренә әйләндереп язу;
- табышмаклар, кроссвордлар уйлап чыгару;
- бирелгән образларны шигырь калыбына салу;
- бер чор героен икенче заманга күчерү;
- әдәби әсәрне тәмамлау һәм башка бик күп чаралар.

Икенче юнәлеш. Татар теле дәресләрендә грамматика өйрәнелә. Грамматика өйрәнү мавыктыргыч булсын өчен, билгеле инде, С. Вагыйзовның “Кызыклы грамматика”сына мөрәҗәгать итәбез.

- иҗек өстәү юлы белән яңа сүзләр ясау: чын-лачын, мәк-икмәк, шәм-түшәм, су-алсу, тән-иртән, тап-китап, ай- бодай;
- иҗек урыннарын алыштыру юлы белән яңа сүзләр ясау: таба-бата, каба-бака, Куба-Баку, кесә-сәке, чабак-бакча, бая-яба, дару-руда, акбаш-башак

Ләкин иҗадилыкка да урын җитәрлек. Һәрбер дәрес иҗади эш белән тәмамланса, ягъни кабул ителгән материал тормышта кулланылса гына отышлы була. Иҗадилык таләп ителә торган кайбер эш формалары:

- VI сыйныф, сыйфат темасы – ясалышы буенча төрле сыйфатлар кулланып, төрле телдә әниләрне тәбрикләү открыткасы ясау;
- V сыйныф, фонетика – бер авазга башланган сүзләрдән хикәяләр бәйгесе;
- VIII сыйныф, диалог – җансыз предметлар бәхәсе оештыру һ. б. ;

Өченче юнәлеш. Табигатьтән әдәби сәләтле балалар белән эшне тирәнтен һәм киңрәк оештыру максатында “Тылсымлы каурый” дигән иҗат берләшмәсе оештырдым. Төп максатым – иҗади сәләте булган укучыларның эшен автор позициясе югарылыгына кую, үзләренең иҗади көчләрен чарлау. Үзе автор булып караган балада башка авторларның эшенә сак караш тәрбияләнә, һәм әдәби әсәрләрне теләп уку ихтыяҗы туа. Игътибарга лаеклы эшләр стена гәҗитендә урын ала, ярышып эшләү өчен стимул булдырыла, бәйгеләрдә катнашу өчен теләк туа. Югары сыйныф укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, генеология, Татарстан тарихы буенча фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнү берләшмәсе дә оештырдым. Аерым план нигезендә укучылар фәнни хезмәт язу нигезләрен үзләштерәләр. Шәхес, гаилә, милләт агачларын төзиләр, бөек кешеләр тамырларында төрле милләт бәйләнешләрен эзлиләр, үз тамырларын барлауда катнашалар.

Иҗади сәләтне үстерүдә түгәрәк эше белән бергә сыйныфтан тыш чараларның да роле бик зур. Чөнки бала уйлый, уйный, яңалыкка, матурлыкка омтыла. “Сөмбелә” бәйрәме, “Каз өмәсе”, “Моң чишмәсе” кебек әдәби кичәләр сәнгать әсәрләренең кыйммәтен, үзенчәлеген аңларга ярдәм итә. “Покрау”, “Нардуган” бәйрәмнәрен әзерләү үзара якынайта. Балаларның үз сценарийлары буенча куелган “Алтын алма” кичәсе, курчак театры үзләренә рухи азык бирә, мәктәп тормышын кызыклы итә.

Яңалык – онытылган искелек, дигән гыйбәрә яши. Укытуда нинди генә технологияләр белән коралланмыйк, тел галимнәренең сыналган методикалары эшебез нигезе булып калыр.

Йомгаклап, үземнең туган тел укытучысы буларак горурлануымны белдерәм. Мин балаларга анасы сеңдергән тел үзенчәлекләрен һәм шул телдә язылган әдәби байлыкларын ачарга ярдәм итәм. Мин балага анасы да бирә алмаган, кеше туганда ук ябышып килә торган “туган тел” төшенчәсе барлыгын аңларга булышам.

Список использованных источников

1. Атлас истории татарского народа – М: Издательство ДИК, 2005 г.
2. Вагыйзов С.К. Кызыклы грамматика: Укытучылар өчен кулланма – Казан: Магариф, 2002 г.
3. Мифтахов З.З., Мухамадиева Д.Ш. История Татарстана и татарского народа: Учебник – Казань: Магариф, 2007 г.
4. Султанбеков Б.Ф. История Татарстана: Учебное пособие – Казань: Тарих, 2001 г.
5. https://arskmedia.ru/news/sezne-khatlar/sly-vagyyzovny-kyzykly-grammatikasy-turynda

Низамбиева Р.Р.
с.Терси, Агрызский район, МБОУ Терсинская СОШ ,учитель татарского языка и литературы
Гимазова Ф.Г.
с.Терси,Агрызский район, МБОУ Терсинская СОШ, учитель начальных классов и географии

## ТУГАН ТЕЛНЕ ӨЙРӘТҮДӘ ГРАММАТИК УЕННАР КУЛЛАНУГА ЗАМАНЧА КАРАШ (С.Г ВАГЫЙЗОВНЫҢ КЫЗЫКЛЫ ГРАММАТИКА” МЕТОДИК КУЛЛАНМАСЫ БУЕНЧА)

**Аннотация:** В данной статье раскрывается приёмы создания условий для вовлечения ребёнка в мир родного языка через дидактические игры на основе методической разработки С.Г.Вагизова « Занимательная грамматика».

Цель работы:повышение интереса к изучению родного языка посредством дидактических игр, обогащение словарного запаса учащихся ; показать значение использования в изучении родного языка сборника С. Г. Вагизова “ Занимательная грамматика”.

Успех учебно - воспитательной работы заключается в умении заинтересовать учащихся процессом познания, творчески мыслить, учиться самостоятельно, воспитывать духовно-нравственные качества.Следовательно , труды С.Г. Вагизова не теряют актуальности и сегодня. Нужно только уметь использовать и творчески подходить к педагогическим идеям наставника в своей деятельности.

**Ключевые слова:** С.Г.Вагизов, методическое пособие, « Занимательная грамматика», грамматические игры , родной язык, игровая технология, лайфхак.

**Abstract:** This article reveals the methods of creating conditions for involving a child in the world of his native language through didactic games based on the methodological development of S.G.Vagizov "Entertaining grammar".

Purpose of the work:increasing interest in the study of the native language through didactic games, enriching the vocabulary of students; to show the importance of using S. G. Vagizov's collection “Entertaining Grammar” in the study of the native language.

The success of educational work lies in the ability to interest students in the process of cognition, to think creatively, to learn independently, to cultivate spiritual and moral qualities.Consequently, the works of S.G. Vagizov do not lose their relevance today. You only need to be able to use and creatively approach the pedagogical ideas of the mentor in your activities.

**Keywords:** S.G.Vagizov, methodical manual, "Entertaining grammar", grammar games, native language, game technology, life hack.

Замана алга бара. Дөнья үзгәрә. Инновация, модернизация, яңа тенденцияләр. Әмма шулар арасында туган телебез эреп югалып бара. Чыгышың актуальлеге нидә? Телебез югалса, милләтебез юкка чыгачак. Нишләргә? Телебезне ничек яшь буынга кызыклы итеп өйрәтергә?

Чыгышыбызның максаты:

1. Укучыларның дидактик уеннар аша туган телне өйрәнүгә кызыксынуын арттыру, сүзлек хәзинәсен баету; 2. Туган телне өйрәнүдә С. Г Вагыйзовның “ Кызыклы грамматика” җыентыгы, аны куллануның әһәмиятен күрсәтү;

Проблеманы хәл итү юлларын ничек табарга? Беренчедән, укытучы үзе үзгәрергә тиеш. Икенчедән, дәрес моделен үзгәртергә. Өченчедән, укыту- уку шартларын замана белән яраклаштырырга. Телне өйрәтүдә укучыларны җәлеп итәрдәй алымнар кулланырга.

Ни өчен үзгәрергә? Чөнки без яңа буын балалары белән эшлибез. Алар кызыксынучан, мөлаем сабыйлар. Телне аңлый**,** әмма туган телендә аралаша алмый торган яңа замана балалары. Менә шундый замана балалары белән эшләүче укытучы нинди булырга тиеш соң? Сезгә хәзерге заман укытучысының инновацион портретын тәкъдим итик.

1.Укучы теләп укысын, мөстәкыйль белем алу теләге булсын өчен камфорт шартлар тудыручы; 2.Креатив 3.Үзгәрергә курыкмый торган. Яңа төшенчәләрне аңлап эш итүче( фейсбук, сторис, контент, аккаунт лайфхак...)4. Төп сыйфатлары: үз йөзе, үз сүзе, эше һәм сүзенең тәңгәл булуы, милләтпәрвәр шәхес булуы мөһим; 5.Вакытны тоя белүче. Мобиль. Дәрестә яңа заман укытучысы-укучыларны аңлы рәвештә вакыт чикләрен билгели белергә өйрәтүче дә, туган телебез ярдәмендә милли бердәмлек рухы тәрбияләүче дә.

Әдәби уку дәресендә өченче сыйныф укучылары белән Г. Моратның “ Туган тел” шигырен укыйбыз. Шагыйрь язган юллардан укучылар телебезнең әниебез кебек бер генә булуын, аны белергә, яратырга кирәклеген төшенәләр кебек. Кебек, чөнки әдәби телне хәзерге заман укучылары бик авыр аңлый, хәтта " ай",“кояш” сүзләре дә чит аларга.Сыйныфта укучыларның күбесе авазларны да дөрес әйтми. Әйтелеш бер проблема. Дөрес язу - икенче зур мәсьәлә.Сүзләрне дөрес әйтә алмаган бала туган телдә ничек дөрес итеп яза белсен инде...

Бай мирасыбыз ярдәмендә киләчәк буында әхлак сыйфатлары, милли горурлык хисе тәрбияләү дә безнең бурыч. Кызганыч, шигырьдәге “ игелекле”, “ газиз”, дога”, адашмассың” сүзләре аңа чит. Чөнки бала бу сүзләрне аңламый, өйдә, тәнәфестә, урамда –кыскасы бөтен җирдә бала русча аралаша. Сөйләм телен камилләштермәсәк, дөрес язарга өйрәтә алмыйбыз. Менә өстәл сүзенең балалар язган берничә генә варианты: стел, стель, естел...Мондый мисаллар бик күп китерергә булыр иде. “ Сез нинди кошларны беләсез?- дип сорау бирелә. Әлбәттә, укучыларның җаваплары бар. Күп кенә укучылар бу сорауга күбесенчә бертөрле итеп: “ Чыпчык”, - дип җавап бирә.

Укучыларның теле ярлы, җөмлә төзи алмый. Күп сүзләрнең мәгънәсен аңламый бала.Төрле алымнар һәм юллар белән телгә кызыксындыру юлларын эзлибез. Безгә шул вакытта С. Г. Вагыйзовның “ Кызыклы грамматика” методик кулланмасы ярдәмгә килә. Җыентыктагы грамматик уеннар, мавыктыргыч күнегүләр, табышмак, башваткыч, әкият һәм мәзәкләрне туган тел һәм әдәби уку дәресләрендә куллану әлеге мәсьәләне чишәргә ярдәм итә.Мисалга җыентыктан берничә уен.

**“Җиде кош” уены.** Укучылар рәсемдәге кош исемнәрен бирелгән буш шакмакларга тутыралар.Беренче хәрефләрен укыганда, җиденче кош исеме килеп чыга. Шулай итеп, укучылар әлеге уен ярдәмендә кош исемнәрен истә калдыралар.

Фонетика бүлегендә “ Сузыклар һәм тартыклар” темасын үткәндә **” Синең исемең нинди аваздан башлана”** уены үзенчәлекле.Укучылар үзләренең исемнәрен яңгыратканда, һәрвакыт горурлык хисе кичерә.” Әлеге уен ярдәмендә укучы сузык һәм тартык авазлар турында белемнәрен тирәнәйтә. Балалар үзләрен исемнәрен әйтә- әйтә, авазларны аерырга гына өйрәнеп калмыйлар, ә авазларны дөрес әйтергә өйрәнәләр. Хәзерге заман укучылары өчен ө, ү, о авазларын әйтү җиңел түгел.

Дәреснең мотивлаштыру өлешендә проблемалы ситуация тудыру өчен җыентыкка кертелгән грамматик әкиятләр, мәзәкләр ярдәмгә килә. Мәсәлән: **“Авазлар бәхәсе” әкияте** ахырында укучы алдында проблемалы ситуация

тудырыла. Сезнеңчә ничек? Кайсы авазлар әһәмиятлерәк, кирәгрәк? Сузыкларmы, тартыкларmы?Укучылар үзләре мөстәкыйль рәвештә проблемалы сорауга җавап эзли.

Шунысы мөһим: балаларның һәм сыйныфның яшь үзенчәлекләренә карап, җыентыкта бирелгән уеннарны сайлап алырга кирәк. Мәсәлән, малайлар күп булган сыйныфта “ Сузык авазлар” темасын ныгытканда, “ Футбол” уены бик отышлы. Сузык авазлар - футбол туплары.Дөрес урнаштырсак, гол саналачак. Бу уен укучы малайларга бик ошый. Шул ук вакытта укучыларның тел байлыгы да үстерелә.

Сүзле уеннардан “ Ялгызлык исемнәр” темасын үзләштергәндә җыентыкка кертелгән географик мәсьәләләр ярдәм итә.Бер укучы шәһәр исемен әйтә.Калганнары шул исемне өстән аска язып куйганнан соң, шул хәрефтән башланган шәһәр исемнәрен язалар. Укучылар шәһәр исемнәрен дә, бу сүзләрнең язылышын да истә калдыралар. Хәзерге заман укучыларының орфографик дөрес язу күнекмәләрен үстерү актуаль мәсьәләрнең берсе булып кала. Уеннар ярдәмендә дәрестә интеграция, предметара бәйләнеш тормышка ашырыла.( Татар теле, табигать белеме, география). Димәк, укучы грамматик уеннар ярдәмендә төрле фәннәрдән белемен тирәнәйтә ала.С. Г Вагыйзов үзенең методик кулланмаларында укучыга белем- тәрбия бирүдә уен технологиясен беренче урынга куя. Хезмәтләрендә автор уенның бала мөстәкыйльлеген, тапкырлыгын, зирәклеген һәм креатив фикерләвен үстерүдәге әһәмиятен ассызыклый.

Бүгенге укучыны тагын ничек кызыксындырырга? Нинди җайлы һәм уңайлы юл белән укучының теманы үзләштерүенә ирешергә? Бу өлкәдә безнең дә үз методик табышларыбыз бар дип уйлыйм. Туган телне укучыларга кызыксынып һәм җиңел итеп өйрәнүдә сезгә татар теленең һәр бүлеге буенча эшчәнлек барышында тупланган берничә уен-лайфхак тәкъдим итәбез.. Лайфхак-уеннар өр-яңадан нәрсәдер уйлап чыгару түгел, ә булган идеяне креатив итеп башкару.

**1.Фигыль-малай” уены.** Истә калдыру өчен укучы Фигыль образын булдыра.( Рәсем ясый).

-Бу Фигыль. Аның аяклары нишли?( Аяклар ярдәмендә кеше чаба, йөри, йөгерә, димәк, Фигыль хәрәкәтне белдерә).

-Кулларына игътибар итегез. Куллар нишли? ( эшли, димәк, фигыль сүз төркеме эшне, хәлне, хәрәкәтне белдерә).

Укучылар Фигыльне җанландыралар, билгеләмәне истә калдыру өчен үзләре иҗади эшчәнлеккә тартылалар.

**2. “Балык- Җөмлә” уены**. Синтаксис бүлеге. Җөмләнең баш кисәкләре. Балык –Җөмлә моделе”. Тулыландырыгыз.

Балык- Җөмлә. Балыкның башы җөмләнең баш кисәге -Ия, койрыгы-Хәбәр.

**3. «Елга буенда балык тотам» уены**. Укучылар проекты. Проект “ Уңайлы юл тәкъдим итәм” .Бәйлек сүз. Бу исемнәр, бәйлек сүз булып килгәндә

икенче бер сүзгә ияреп, тартымлы юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә булалар.

Укыту- тәрбиянең бүгенге көндәге уңышы укытучының бу процессны сыйфатлы башкаруында, укучыларны танып- белү барышы белән кызыксындыра алуында; иҗади уйларга, мөстәкыйль белем алырга өйрәнүенә, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләвенә бәйле.Бүгенге көндә укучының тыңлап утыруы гына түгел, ә үзе кызыксынып төрле эшчәнлектә катнашуы мөһим. Ә укытучы моңа ирешер өчен, ахыргы нәтиҗәне күзаллап, укучыларны актив эшчәнлеккә тартуның төрле ысулларын эзләргә тиеш дип уйлыйм. Димәк, Сәләй ага Вагыйзов хезмәтләре бүген дә актуальлеген югалтмый. Остазыбызның педагогик фикерләрен эшчәнлегебездә кулланырга, иҗади якын килеп, файдалана белергә генә кирәк.

Кулланылган әдәбият

1.Вагыйзов С. Г. Кызыклы грамматика.Укытучылар өчен кулланма.Казан: Мәгариф, 2002.- 207 б

2.Р. Б. Камаева. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар.КИФУ АФ нәшрияты. 2012.-137 б.

3. Р. Фәхреддин. Адабе тәгълим. – Казан.Академия познания. , 2006.-168 бит.

4.Харисова Ч. М. Татарский язык: справочник/-Казань.Татарское кн. Изд-во. 2014.-191 с.

Сайфуллина Г.Р., Гилмутдинова Н.З.
г. Арск, МБДОУ «Арский детский сад №8»,
воспитатели

## РОДНОЙ ЯЗЫК В ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ ОРГАНИЗАЦИИ: СОЗДАНИЕ УСЛОВИЙ ДЛЯ ВОВЛЕЧЕНИЯ РЕБЕНКА В ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ ПРОЦЕСС (НА ОСНОВЕ ТРУДОВ С.Г. ВАГИЗОВА)

Родной язык – святой язык,
Отца и матери язык,
Как ты прекрасен!
Целый мир в твоем богатстве я
постиг! Г. Тукай

**Аннотация:** в статье рассматривается вопрос важности обучения детей дошкольного возраста родному языку и обозначены возможные пути создания условий для развития активного словаря дошкольников на татарском языке в детском саду и в семье.

**Ключевые слова:** родной язык, дошкольный возраст, ребенок, национальная культура, обучение, национальный региональный компонент.

**Abstract:** the article deals with the issue of teaching preschool children their native language and highlights the importance of creating conditions for the involvement of the child in the educational process.
**Keywords:** native language, preschool age, child, national culture, education, national regional component.

В настоящее время возникает необходимость в том, чтобы ребёнок почувствовал уникальность своего народа, знал его культуру, пришёл к пониманию и осознанию собственной неповторимости и значимости каждого человека, живущего на земле. Приобщение дошкольников к национальной культуре становится актуальным педагогическим вопросом современности, так как каждый народ не просто хранит исторически сложившиеся воспитательные традиции и особенности, но и стремится перенести их в будущее, чтобы не утратить исторического национального лица и самобытности.

Овладение родным языком**,** развитие речи являются одними из самых важных приобретений ребёнка в дошкольном детстве и в современном дошкольном образовании рассматриваются как общая основа воспитания и обучения детей. Поэтому так важно с детства создавать представление о том**,** что язык – это главное сокровище народа; воспитывать любовь и бережное отношение к родному языку. Родной язык необходим не только как средство общения и познания окружающей действительности, но и как средство фиксации, сохранения национальных культурных традиций.

Наш детский сад посещают дети разных национальностей. К сожалению, детей, знающих свой родной язык, мало. В основном на родном языке говорят бабушки, и совсем немного молодых людей современного общества владеют родным языком. Именно поэтому приоритетной задачей дошкольного учреждения является обучение детей татарскому родному языку и развитие у детей первоначальных умений и навыков татарской речи в устной форме, приобщение детей к татарской национальной культуре.

Дошкольный возраст – это период активного усвоения ребенком разговорного языка, становления и развития всех сторон речи. Полноценное владение родным языком в дошкольном детстве является необходимым условием решения задач умственного, эстетического и нравственного воспитания детей. Главная цель речевого воспитания состоит в том, чтобы ребенок творчески освоил нормы и правила родного языка, умел гибко их применять в конкретных ситуациях, овладел основными коммуникативными способностями.

В связи с этим в Республике Татарстан был разработан и составлен учебно-методический комплект «Туган телдә сөйләшәбез», который УМК включает в себя методические пособия по обучению родному (татарскому) языку и развитии речи детей дошкольного возраста, рабочие тетради, начиная со средней группы, аудиозаписи, серии картин. Основная цель УМК - формирование правильной устной родной речи детей дошкольного возраста. Главной задачей для программы является обучение детей правильно и красиво говорить. Он

предусматривает совместную работу с детьми педагогов ДОУ, родителей в различных видах деятельности и в семье.

Непосредственно образовательную деятельность по обучению родному языку в дошкольном учреждении проводит педагог – воспитатель по обучению татарскому языку, воспитатели групп ведут работу по закреплению изучаемого материала в режимных моментах при постоянном общении детей.

Работая в детском саду, мы накопили опыт по обучению детей родному языку. А для этого, в первую очередь, должно быть предусмотрено учебно-методическое, кадровое, материально-техническое, правовое обеспечение. Материальную основу всего учебно-воспитательного процесса современного детского сада составляют программы, наглядные пособия, методическая литература, технические средства обучения. В учреждении с приоритетным направлением необходимо предусмотреть в воспитательных планах и в сетках занятий соотношение часов на изучение родного и русского языков.

Основное содержание программы воспитания в детском учреждении составляет национальный региональный компонент. Дети дошкольного возраста воспитываются в среде с национальным колоритом, знакомятся со сказками, стихами, загадками слушают народные песни, играют, учатся исполнять национальные танцы. При подготовке к занятиям, мы ставим перед собой следующие задачи: воспитывать у детей любовь к родному краю, к её природе и бережное отношение к ней; воспитывать патриотические чувства у детей, гордость и уважение к прошлому и настоящему родного края; познакомить детей с интересными историческими событиями, трудовой деятельностью, культурой, бытом и праздниками татарского народа.

Все эти задачи осуществляются не только на занятии по обучению родному языку, но и реализуются в изобразительной деятельности, самостоятельной художественной деятельности. Огромная роль принадлежит декоративно-прикладному искусству, музыке, ознакомлению с народными обычаями, традициями. Важнейшее значение имеет проведение татарских праздников. Традициями нашего детского сада стали проведение следующих мероприятий:

- малышам очень нравится, когда такие обычаи, как «Сөмбелә», «Каз өмәсе» представляют сами педагоги, показывая тем самым, колорит татарского языка;
- в рамках празднования Международного дня родного языка организуется Фестиваль культур народов Поволжья, где по итогам проектной деятельности, воспитанники каждой группы представляют вниманию маленьких зрителей традиции и обычаи народов, проживающих в Поволжье;
- полюбились нашим воспитанникам праздник Навруз и обычай «Карга боткасы», который мы обычно организуем на свежем воздухе с привлечением родителей и постоянных гостей – экологов;
- заканчиваем каждый учебный год детским Сабантуем, где чествуем воспитанников, показавших лучшие результаты в изучении родного языка, дети в ходе праздника с удовольствием поют народные песни, участвуют в татарских народных играх, праздник завершает традиционная татарская борьба.

Основным направлением обучения родному языку в дошкольном учреждении является формирование и развитие у детей простейших умений и навыков овладения родной речью в устной форме. К концу подготовительной группы, дети должны уметь воспринимать родную речь на слух и вести несложный разговор (диалог), составлять небольшое описание предмета, рассказать о детском саде, о своей семье, о себе, о друзьях и т.д., в пределах доступной их возрасту тематике; усвоенных слов, грамматических форм, синтаксических конструкций и типов предложений. Этот возраст наиболее благоприятен для умственного развития и социальной подготовки ребенка. В исследованиях А. Ш. Асадуллина, С. Г. Вагизова, Р. Г. Валитовой, Ф. Ф. Харисова, Ч. М. Харисовой и др. подчеркивается, что дети старшего дошкольного возраста не только понимают значения слов татарского языка, но и умеют пользоваться словами и словосочетаниями для построения собственных высказываний и через словари знакомятся с богатством родного языка, с обычаями и традициями своего народа.

На практике мы убедились, что основной формой работы с детьми дошкольного возраста и ведущим видом деятельности для них является игра. Именно поэтому наши занятия в основном представляют собой разговорные упражнения, при проведении которых детям прививаются первоначальные умения в диалоге, монологической речи на родном языке, чтение стихотворений, прослушивание аудио сказок, театрализация изученных произведений. В работе по воспитанию у детей дошкольного возраста любви и уважения к национальным традициям татарского народа мною используется татарский фольклор и детская национальная литература. Дошкольники младшего и среднего возраста лучше воспринимают потешки, песенки, народные игры с речетативом. В этих группах не ставим целью запоминание национальной принадлежности фольклорного материала. Как воспитатели, работающие с современными детьми, мы стараемся использовать в своей работе мультимедийные ресурсы нового поколения. Использую различные презентации, просмотр мультфильмов, прослушивание аудиосказок.

При изучении родного языка, мы стараемся постепенно включать в свою речь новые слова, формы слов, типы предложений, образцы связной речи. Прилагаем все усилия, чтобы изученные слова регулярно использовались в речи детей. Наш опыт работы показал, что изучение родного языка в дошкольном учреждении может быть успешно реализовано в том случае, если язык будет выступать не только в качестве предмета изучения, но, и будет регулярно, активно использоваться детьми в их повседневной жизни и деятельности.

Дети очень любят сказки. Татарские народные сказки раскрывают традиции народа, его устои: глубокую почтительность и отзывчивость, сострадание к ближнему. Знакомим детей с бытовыми сказками и сказками о животных: «Саран и юмарт», «Хвосты», «Три дочери» и т.д.; с замечательными сказками основоположника татарской детской литературы Г. Тукая «Шурале», «Водяная», «Сказка о козе и баране». Художественная литература дает богатый материал для нравственного воспитания, заставляет ярче и глубже переживать

нравственные поступки, чувства героев. Ежегодно в детском саду проводим литературные вечера по творчеству татарских писателей Абдуллы Алиша, Раифса Корбана, Мусы Джалиля, Фаниса Яруллина, Габдуллы Тукая, на которых приглашаем работников библиотек района. Гордимся, что наши воспитанник могут показать свои знания, участвуя на различных конкурсах, проводимых на татарском языке, и занимают призовые места.

Таким образом, основным компонентом национальной культуры выступает национальный язык. Именно благодаря ему сохраняется нация, правильное понятие о древних традициях и культуре, знания о своей религии. В образовательной деятельности при обучении родному языку дошкольники получают не только новые знания о родной земле, о национальностях, проживающих на территории Республики, а тем самым создаются условия для формирования нравственных чувств.

Язык - это такой символ культуры, который ничем не заменить. Это богатство. И чем больше языков знает человек, тем он духовно богаче! А для этого нам нужно уметь искать, собирать знания по крупицам и быть упорными в приобретении знаний. Именно этому мы должны учить детей. И делать это будет намного эффективнее в тесном сотрудничестве с родителями. В результате своих размышлений, мы пришли к выводу, что ничто другое так не оказывает влияния на душу ребенка, как личный пример взрослого. А значит, впереди нас ждет большой и упорный труд, который непременно принесет свои плоды.

Список информационных источников

1.Алексеева, М.М. Методика развития речи и обучения родному языку дошкольников / М.М. Алексеева, В.И. Яшина. – 3-е изд. – М.: Академия, 2000. – 412 с.
2.Сохин, Ф.А. Основные задачи развития речи // Психолого-педагогические основы развития речи дошкольников /Ф.А. Сохин. - М.: 2002. -324 с.
3.Ушакова, О.С. Методика развития речи детей дошкольного возраста / О.С. Ушакова, Е.М. Струнина. – М.: Гуманитар. изд. центр ВЛАДОС, 2008. – 287 с.

Сафина Г.Н.
ТР Биектау районы Олы Битаман төп гомуми белем мәктәбе
башлангыч сыйныф укытучысы

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНА ТУГАН ТЕЛГӘ МӘҺӘББӘТ УЯТУ АЛЫМНАРЫ

**Аннотация:** Родной язык – основа развития интеллекта, формирование эмоциональной сферы ребёнка, его морального облика, становления творческой личности, способной создавать национальные и культурные ценности. Это наилучшее средство познания истории народа, его духа, воспитание любви и

уважения к родному народу, чувство гордости за тот вклад, который он вносит в общечеловеческую культуру. Именно поэтому педагоги нашего учреждения активно работают над решением данной проблемы.

И туган тел, и матур тел!<br>
Әткәм-әнкәмнең теле!<br>
Дөньяда күп нәрсә белдем<br>
Син туган тел аркылы.<br>
Г.Тукай

Хәерле көн хөрмәтле коллегалар! Бугенге көндә кече яшьтәге балаларның туган телдә бәйләнешле сөйләмнәре түбән булуы- хәзерге заман педагогикасында иң актуаль һәм катлаулы проблемаларның берсе булып тора**.**

Сәбәбе: Безнең гомуми компьютерлаштыру гасырында өлкәннәр балалар белән компьютер, планшетлар, телефоннар аша эш итә. Ә китап арткы планга күчә. Безгә, башлангыч сыйныф укытучыларына, баланы нәкъ менә матур әдәбият белән кызыксындыру өчен күп көч куярга туры килә. Биредә халкыбызның борынгы гореф-гадәтләре, уеннары, әкиятләре ярдәмгә килә.

Әкият бала тормышына төрлелек кертә, аңа шатлык бүләк итә һәм сөйләмне үстерүнең иң нәтиҗәле ысулларының берсе булып тора. Ул баланың сүзлек запасын киңәйтергә, шулай ук логик сөйләмне үстерергә ярдәм итә. Әкиятләр ярдәмендә сабыйның сүзе эмоциональ, образлы, матур булырга тиеш. Әкиятләрдә тасвирланган тылсымлы тарихлар аралашуга ярдәм итә, сораулар бирә, сүзләр, тәкъдимнәр һәм сүзтезмәләр төзи белүгә өйрәтә.

Бала тормышында әкияттәге иң төп моментларының берсе – аларда һәрвакыт яхшылык җиңә. Киләчәктә бу балага бик ярдәм итәчәк, аны тормыш авырлыкларын җиңәргә өйрәтәчәк. Тормыш, әлбәттә, үз төзәтмәләрен кертәчәк, тик, шуңа да карамастан, балалар аңында бернәрсә дә югалмаячак.

Шуларны истә тотып без укучылар белән төрле халык әкиятләрен, мультфильмнарын туган телебезгә тәрҗемә итәбез, геройлар өчен бергәләп костюмнар әзерлибез һәм сәхнәләштерәбез:

- “Лунтик һәм аның дуслары”
- “Карбикә” (Снежная королева)
- “Теремкәй”
- “Шалкан”
- “Алтын аламалар”
- “Чукмар белән Тукмар”
- “Буратино”
- “Алтын башак” һ.б. әкиятләрен бик яратып өйрәнделәр.

Әкиятне сәхнәләштергән вакытта балада үз-үзенә ышаныч арта, бала вакыйгаларның чынлыгына ышана, шатлана яки киресенчә борчыла. Бу нәни баланың эчке активлыгын, аның күңел көчләрен уңай якка юнәлтергә, аң һәм белем эшчәнлеген активлаштырырга ярдәм итә. Ул дөрес интонация белән, төрле хәрәкәтләр, мимикаларны кулланырга, эмоциональ һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнә. Ягъни бу эшчәнлектә без балаларның иҗади сәләтләрен устерәбез һәм

инде явызлыкны, усаллыкны гаепли, ә гаделлекне яклый, барлык кешеләргә карата да гадел, игелекле, мәрхәмәтле булырга өйрәтәбез.

Әкиятләргә карата рәсем күргәзмәләре оештырабыз, татар мультфильмнарын карыйбыз. Билгеле бер әкият, мультфильм белән яхшылап танышып, өйрәнеп, сәхнәләштереп үзләштергәннән соң, дидактик уеннар белән ныгытабыз.

1. Интерактив дидактик уеннар. Мәсәлән, “Бу нинди әкият” уенында интерактив тактада әкияттән сюжет, өзек куябыз, бала әкиятнең исемен әйтә, өзекне сөйли. Шушы ук алымны әкият геройларына карата да кулланабыз. Балалар герой, персонажларның характерын, үз-үзен ничек тотышын сөйли, нинди әкияттән икәнлеген әйтә.

2. Өстәл уеннары. Шулай ук әкиятләрне өстәл уеннары аша да ныгытып була. Мәсәлән балаларга татар халык әкиятләре төшкән рәсемле шакмаклар бирелә. Алар шакмаклар ярдәмендә бер әкиятне сайлап, аның сюжетын төзиләр, һәм кыскача эчтәлеген сөйлиләр. Икенче вариантта шакмакларда әкиятнен бер сюҗетлы рәсеме ясалган, балалар шул шакмаклардан пазл кебек рәсем төзеп бирергә тиеш.

3. Мнемотаблица. Зурлар төркемендә мнемотаблица алымын кулланырга була. Бала таблицада бирелгән символларны танып, экиятнең эчтәлеген этап буенча сөйли ала. Бу балаларда игътибарлык, хэтер, логик фикерләү, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерә.

4.ТРИЗ алымын кулланганда балаларга әкиятләрне үзләренчә дәвам итәргә яки яңа әкиятләр иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Балалар иҗатын һәрвакыт хупларга, иҗатларын һәрьяклап үстерүдә ярдәм итәргә кирәк. Бу алымнар балаларның сөйләм телләрен үстерүгә зур этәргеч ясый

Өйрәнгән уен, экиятләрне, җырларны мәктәп сәхнәсендә генә уйнап калмыйча төрле конкурсларда да актив катнашып урыннар алабыз. Җиңү яулаган укучыларда әлбәттә туган телгә мәхәббәт, телне өйрәнү теләге тагын да көчәя.

Гореф-гадәтләрнең, милли уеннарның да кече яшьтәге балаларга туры килгәннәрен сайлап өйрәтергә тырышабыз. Кызыклы да, файдалы да булсын. Мәсәлән:

- “Түбәтәй”
- “Күрсәт әле үскәнем”
- “Утыр, утыр, Мәликә”
- “Ак калач”
- “Миңлебай”
- “Яулык алыш”

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар һәм бер кеше яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

Талым, талым, талчыбык,<br>
Уртасында бал чыбык,<br>
Ал яулык, гөл яулык,

Бир син миңа бер яулык, - дип, такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

- “Түбәтәй”

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр:

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ераклардан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккатырыйм, дигәнсең.
Кушымта: Түп – түп-түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, әтәч булып кычкыра һ.б.) Уен шулай дәвам итә.

Шулай ук тәнәфесләрдә туган телебездә шигри юллар, җыр сүзләре белән уйнаган уеннар да туган телне өйрәнүдә мөһим роль алып торалар.

Укучылар белән нинди генә чаралар уздырсак та, нәрсә генә өйрәнсәк тә, иң беренче чиратта, туган телебезгә, халкыбызга, гаиләбезгә, гореф-гадәтләребезгә, әби-бабаларыбызга хөрмәт, тугрылык хисе тәрбияләү тора. Балаларның авазларны дөрес әйтеп, үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә һәм бәйләнешле итеп сөйли белүләренә ирешү, туган телнең матурлыгын, аһәңлелеген тоя-күрә белергә өйрәтү бурычлары тормышка ашыруда әдәби әсәрләр, нәфис сүз, халык авыз иҗаты әсәрләрләренең әһәмияте гаять зур.

Безнең киләчәгебез балалар кулында. Ә баланың әдәпле, кешелекле булып үсүе безнең үзебездән, ягъни гаиләдән һәм әйләнә тирә мөхиттән тора. Әгәр кеше күңеленә кечкенәдән үк матур сыйфатлар сеңдерелсә, ул инде гомерлек була.

Төхфәтуллина Әлфия Госман кызы
Арча ш., ДАҺБУ “Г.Тукай исемендәге
Арча педагогия көллияте”,

## БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА МИЛЛИ ТӘРБИЯ БИРҮ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация:** Статья посвящена одной из важных проблем современной системы дошкольного образования. Она отражает содержание, особенности национально-регионального компонента в дошкольном образовании.

**Ключевые слова:** национальное образование, обучение, родной язык, воспитание детей, обучение грамоте.

**Abstract:** The article is devoted to one of the important problems of the modern system of preschool education. It reflects the content and features of the national- regional component in preschool education.

**Keywords:** national education, education, native language, parenting, literacy training.

Галим, педагог Айдар Низамов: “Шәхес формалашу чорында аңа үз милләте турында дөрес мәгълүмат бирелсә, милләтнең язмышы һәр милләт вәкиленә бәйле булу белән аңлатылса, шәхес үз милләтенә хезмәт итү кыйбласыннан читкә китмәс”, - дигән. Чынлап та, шәхескә белем бирү, аны тәрбияләү һәм тормышка әзерләүдә күп факторлар катнаша: гаилә, балалар бакчасы, мәктәп, башка уку йортлары, тирә-юнь, урам, һәм шулар белән белән беррәттән милли-региональ үзенчәлекләр. Һәр халык, һәр милләт үзенең рухи байлыгын үзенчәлекле шартларда, үзенчәлекле юллар һәм алымнар белән туплаган. Аларның һәрберсе дөнья мәдәниятенә үзеннән сизелерлек өлеш кертә, баета. Милли рухи байлык аерым халыкның гына түгел, ул – гомум кешелек кыйммәтләренең нигезе. Димәк, балаларны кечкенәдән үк үз халкының , үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру гомум кешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора.

Татар мәгърифәтчеләренең хезмәтләреннән күренәгәнчә, милли тәрбия бирү заманның иң катлаулы һәм болгавыр чорларында ук алып барылган һәм иң кыйммәтле хәзинә булган. Әйтик, XX гасыр башында да милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне, халкыбызның милли тәрбия өлкәсендәге тәҗрибәсен, кыйммәтле җәүһәрләребезне саклау буенча зур эш алып барылган. XIX гасыр азагы – XX гасыр башында барлыкка килгән «Милләт аналарын» хәрәкәте әнә шуңа ачык мисал. «Хатын-кызны тәрбияләү максаты — милләт аналарын тәрбияләү. Чөнки мәгърифәтле, белемле аналар гына милләтне тәрбияли ала», — дип язган галим Альта Хаҗиевна Мәхмүтова

«Милләт аналары» сүзе, термин буларак, беренче тапкыр Риза Фәхретдин китапларында очрый. Аныңча, тәрбия, беренче чиратта, гаиләдә бирелә. “Гаилә - кечкенә бер дәүләт кебидер”, Һәм гаиләдәге тәртип һәм тәрбия – “җөмләсе гаилә башлыгы улган хатын вазифасыдыр. Димәк, Р.Фәхретдинов сүзләренчә, милләтне тәрбияләүне әниләрдән башларга кирәк.

Беребезгә дә сер түгел, нинди генә кануннар кабул ителеп, чаралар үткәрелеп, кыйммәтле дәреслекләр нәшер ителсә дә, бала гаиләдә туган телдә аралашмаса, аны ишетмәсә, нәтиҗә бик аз булачак. Нәкъ менә гаилә туган телләрне саклау һәм үстерү чылбырында мөһим буын булып тора.

Мәктәпкәчә яшьтәге тәрбия учреждениеләре, берсүзсез, милли тәрбияне тормышка ашыруда беренче баскыч булып торалар. Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү мәктәпкәчә чордан ук башланса, нәтиҗәләр күпкә яхшырак булачагы һәркемгә мәгълүм. Бары тик эшне дөрес оештырырга, тиешле юнәлеш кенә бирергә кирәк.

Без, педагогларның бурычы– үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү.

Күп кенә белгечләр фикеренчә, милли тәрбиядә беренче чиратта гаиләгә, йола һәм гореф-гадәтләргә, әниләрне тәрбияләүгә һәм “сәламәт милләт” төшенчәсенә игътибарны юнәлтергә кирәк. Димәк, тәрбия эшендә төп игътибарны әти-әниләр белән эшләүгә юнәлтү кирәк. Минемчә, алар белән уртак проектлар, чаралар үткәрү уңай нәтиҗәләр бирәчәк. Әти-әниләргә телләр өйрәнүнең әһәмиятен, моның баланың шәхес буларак үсешенә һәм киләчәк тормышта уңышлы булуына йогынты ясавын төшендерергә кирәк. Бу өлкәдә уңышка ирешү өчен, шулай ук, балага шәхси караш булдыру шарт. Ягъни, бала белән аерым шөгыльләнү, баланы мактау, аның уңышларын күрә һәм башка балаларга да күрсәтә белү, тел өйрәнүдәге омтылышларын хуплау кебек алымнар отышлы. Һәм инде тагын бер мөһим әйбер - балаларны кызыксындыра алырлык предметлы тел мохите булдыру. Бакчадагы тирәлекнең стандарт шартларына туры килүе мөһим: ул үзгәрүчән, интерактив, балаларның кызыксынуларына, яшь һәм шәхси үзенчәлекләренә туры килергә тиеш. Татар телен өйрәтү балалар бакчасындагы тел мохите баланы кызыксындырса, өйрәнергә, үзгәртергә, ни дә булса эшләргә теләк уятса гына уңышлы була. Бернинди дә үзгәрешләр булмый торган, бертөрле генә «катып калган» тирәлек балаларның сөйләм активлыгын үстерә алмый.

Икенчесе максат балалар бакчасында татар теле шөгыльләрен үткәрүгә юнәлдерелгән. Еш кына татар теле шөгыльләре балалар һәм аларның әти-әниләре тарафыннан кирәксез һәм файдасыз бер шөгыль буларак карала. Балаларның да кайберләре нәкъ менә татар теле шөгыльләрендә үзләрен пассив тоталар. Ничек итеп һәм нинди юллар аша балаларыбызда татар теленә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләргә соң? Бу проблеманың Дәүләт, гаилә, җәмгыять күләмендә каралырга тиешле якларыннан тыш, без – педагогларга караган өлешләре дә шактый. Шундыйларның берсе - татар теле шөгыльләрен ничек кызыклы һәм мавыктыргыч итеп үткәрү. Без, балалар бакчасында татар теленә өйрәтү методикасы дәресләрендә һәм практик әзерләнгәндә студентларыбызга да еш кына әлеге мәсьәләне күздә тотуларын сорыйбыз. Зифа Мирхатовна Зарипова җитәкчелегендә чыгарылган “Туган телдә сөйләшәбез” УМК уңайлыклар тудырды. Әмма миңа калса, безгә андагы тематиканы үстерү, эчтәлеген һәр тәрбиячегә үз күзлегеннән чыгып киңәйтү зарур, чөнки анда темаларның кабатлануы, кайберләренең артык кыска, яисә артык зур, яки катлаулы икәнлеген күрәбез. Бәлки кайбер өлешләрне заман күзлегеннән чыгып үзгәртү кирәктер. Тәрбиячеләргә балаларның сүзлек запасы гамәлдәге УМК минимумыннан арттырып, аның кысаларыннан чыгарга вакыт. Бу максаттан төрле сюжетлы-рольле уеннар, әкиятләрне сәхнәләштерү кебек чаралар уңай нәтиҗә бирүен без инде беләбез.

Төркемнәрдә шөгыльләр һәм режим моментларында балаларның татар теле дәресләрендә алган белемнәрен ныгыту өчен, бай дидактик материал булдыру яхшы. Бала күрде, тойды һәм исендә калдырды принцибы белән эш итү

күпкә уңышлырак нәтиҗәләр бирәчәк. Шөгыльләргә күрсәтмә материаллар әзерләгәндә дә аларның балаларга тотып каралык, алар белән эш итәрлек булы күпкә отышлырак булыр иде. баланың бакчада булган бар вакытын - иртән килеп, кичен өенә кайтып киткәнче – эмоциональ яктан бизәргә, төрләндерергә, кызыклы итәргә тырышу мөһим. Ягъни тәрбия - сүздә түгел, гамәлләрдә булырга тиеш!

Милли - мәдәни юнәлештә эшләүгә милли традицияләрне өйрәнү, мәдәни чаралар, бәйгеләрдә катнашуның да роле зур. Баланың продуктив эшчәнлеге танып-белү үсеше, сөйләм үсеше, аралашу белән нык бәйләнгән. Ә мондый чараларга әзерләнгәндә аларда аралашу ихтыяҗы күпкә зуррак. Тел өйрәнүгә ихтыяҗ булмый торып, бала аның кирәклеген тоймаячак. Шул уңайда балалар бакчасы эчендә генә булса да төрле бәйгеләр үткәрү һәм аларда әти-әниләрнең үзләрен катнаштыру яхшы.

Президент тарафыннан рәсми рәвештә Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан ителгәч, ул бу өлкәгә игътибарны тагын да арттырачак дигән сүз. Без игътибарга бик мохтаҗ. Чөнки вазгыять катлаулы, киеренке. Шундый вазгыятьтә үз-үзебезне саклау – бер-берсенә бәйле. Милли мәдәният, тел, милли мәгариф – бөтенесе бербөтен организм. Аларны аерып карарга карамый. Без һәрбер юнәлешкә зур игътибар бирергә тиеш."

Халык җәүһәрләрен дә балалар җиңел, табигый кабул итәләр. Аларда юмор да бар, ямансулык та, бер-береңә, иптәшләреңә, үз туганнарыңа һәм ниһаять иң мөһиме төрле милләт халкына тирән мәхәббәт ята. Шушы балаларга якын серле дөньяда алар яраткан, хәрәкәтле, җырлы-биюле, Идел буе халыклары уеннары да уйнатсак - бу алар өчен кызыклы да ,файдалы да була дип уйлыйм.

Бергә татарча мультфильмнар, ТНВ каналыннан татарча тапшырулар карарга чакырабыз, шулай ук «Ана теле» он-лайн курсларында белем алырга тәкъдим итәбез.

Менә шулай итеп эшләп, без бакчабызда тудырылган шартлар һәм белем бирү тирәлеге уңайлы һәм балаларга татар телен җиңелрәк һәм кызыклырак итеп үзләштерергә мөмкинлек бирә дигән нәтиҗәгә килдек.

Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр милли мәгариф үсеше концепциясе расланды. Концепциянең максаты : заман шартларында милли мәдәниятне һәм телне саклау, үстерү, киләчәк буыннарга тапшыру өчен милли мәгарифне камилләштерү. Милли мәгариф системасын үстерү бүгенге көннең актуаль проблемаларының берсе булып санала. Дәүләт һәм ата-аналар алдында гаиләдә, балалар бакчасыннан алып, мәктәпкәчә ана телендә тәрбияләү һәм укыту мәсьәләсен хәл итү бурычы тора.

Соңгы вакытта татар теле шөгыльләрендә кулланырга мөмкин булган электрон ресурсларның күренә башлавы куанычлы. Аларның берсе һәм мөгаен күбебезгә таныш булган - “Бала.РФ” дип аталучы интерактив мультимедияле, тавышлы китапханә. Материалны укып өйрәнгәнгә караганда, аны күреп һәм тыңлап өйрәнү – сөйләм күнекмәләрен үстерүдә күпкә нәтиҗәле алым. Ассызыклап әйткәндә, республикабыз интернет кулланучылары өчен әлеге китапханә – әдәби әсәрләрне балага җиткерүнең яңа формасы булып тора. Әлеге

онлайн мультимедиа-китапханәгә 150 гә якын ресурс урнаштырылган. Интерактив формадагы татар әкиятләре, классик язучыларыбызның билгеле әсәрләре тупланган әлеге бүлекнең мультфильмнан өстенлеге шунда – бала аны, диафильм караган сыман, күпме тели, ничек тели, кайчан тели – шулай файдалана ала. Караоке ярдәмендә җөмләләрне, сүзләрне кабатларга мөмкинлек тудырылган. Балаларның фикерләвен үстерү өчен бирелгән тестлар игътибарны тупларга, мәгълүматны ишетеп аңларга, хәтерне ныгытырга ярдәм итсә, фикер алышу өчен тәкъдим ителгән сораулар укучыларның сөйләмен үстерә, сүзлек запасын арттыра, ә сәнгать әһелләре тарафыннан башкарыла торган әсәрләрнең теле, үрнәк әйтелеш актерлык осталыгына, сәнгатьле сөйләмгә өйрәтә.

Tatmedia junior проекты кысаларында Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән«Салават күпере» һәм «Сабантуй» журналлары тарафыннан тормышка ашырылган
«Күңелле әлифба» проектын да хәрефләрне өйрәнгәндә кулланырга мөмкин. Театр актеры Алмаз Гәрәевның кызы Зөбәйдә белән төшерелгән мавыктыргыч видеоларын ютуб каналында табарга була. Ул бөтен хәрефләргә дә төшерелгән. Мондый видеолар балаларда татар теленә карата кызыксыну уятмый калмас минемчә. Видеода әти белән кызның бергәләп әлифба өйрәнүләре күрсәтелә. Сюжет буенча әлифбаның һәр хәрефе я качып киткән, я сихерләнгән. Төп геройларга аларны коткарырга кирәк була. Әлифбада 39 хәреф булганлыктан, проект та 39 тапшырудан тора. Һәр хәреф анимацияләнгән, ул сөйләшә һәм хәрәкәтләнә. Шулай итеп, әти белән кыз һәр хәреф белән сөйләшеп, танышып чыга.

2021 елдан Салават күпере» һәм «Сабантуй» журналлары кече яшьтәге балалар өчен җырлы-биюле «СалаваTik» дип аталган проект башлады. Проектның төп максаты без кечкенәдән тыңлап, җырлап үскән татарча балалар җырларын бүгенге заман балаларына аңлаешлы формада өйрәтү, таныту Видеоязмаларны YouTube каналда гына түгел, бүгенге көндә балалар арасында популяр булган Tik-Tok һәм башка социаль челтәрләргә дә табарга була.

Шулай ук Шаян тв каналы да татар телен үстерү юнәлешендә күп эш башкара. Даими конкурслар үткәреп тора, Тәүлек буенча эшләүче каналда күрсәтелгән Татарча мультфильмнар, кызыклы һәм мавыктыргыч тапшыруларны, шулай ук татар теленә өйрәтүче Бергәләп өйрәник тапшыруын интернет аша да карага мөмкин.

Әйе, тәрбия – сүздә түгел, гамәлләрдә чагылырга тиеш. “Рухи хәзинәләребез – илһам чыганагы, милләтне яңарту, яңа үсеш офыклары ачу өчен бетмәс-төкәнмәс байлык. Иң мөһиме – үз халкың хакына аңлы гамәлләр кылу һәм аңа хезмәт итү,” – дип язылган татар халкының гамәл стратегиясендә. Татар мәдәниятенең ни белән дан казаначагы, балаларыбызның бездән нинди сабак алачагы безнең һәрберебездән тора...

## Кулланылган әдәбият исемлеге

3. Сафиуллина Г. Мәктәпкәчә белем бирү стандарты: таләпләр һәм мөмкинлекләр // Мәгариф. . – 2014. – № 12. – Б. 11- 14
4. Туган телем – бөек анам теле: татар балаларын ана теленә өйрәтү өчен тәрбиячеләргә методик кулланма – Яр Чаллы, 2004. – 127 б.
5. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма. – Казан: Фолиант, 2013. – 224 б.

Фазлиева Ильсеяр Абударовна
МБОУ «Кузякинская ООШ» Актанышского муниципального района
Республики Татарстан

## ТУГАН ТЕЛЛӘРНЕ УКЫТУНЫҢ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Туган тел-халыкның җаны. Һәм һәр халык (ул зурмы, әллә кечкенәме) үз телен бер максат белән саклый – аны үз нәсел варисларына тапшыра.

Тумыштан ук бала туган телнең матурлыгын, тирәнлеген һәм байлыгын, көчен һәм бөеклеген ишетергә, тоярга тиеш. Бүгенге көндә безнең максат-туган телне, туган әдәбиятны һәм мәдәниятне өйрәнүгә, балаларыбызны үз халкының иң яхшы гореф-гадәтләрендә тәрбияләү, балаларны Белем белән коралландыруга, фикерләүнең мөстәкыйльлеген формалаштыруга кызыксынуны арттыру.

Балаларны туган телгә өйрәтү түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә:
беренчедән, балаларда сүз сәләте дип аталган тумыштан килгән рухи сәләтне үстерү;

икенчедән, балаларны туган тел хәзинәләренә аңлы рәвештә ия булуга кертергә

өченчедән, балаларга бу телнең логикасын үзләштерү. Бу максатлар һәм бурычлар бер-берсеннән соң түгел, ә бергә ирешелә.

Бу максатлар һәм бурычлар үтәлсен өчен күп көч куярга кирәк. Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә моны ничек эшләргә? Нинди яңа формалар кертергә, балаларны нәрсә кызыксындырырга?

Сүз һәртөрле акыл үсешенең һәм барлык белемнәрнең нигезе булып тора. Балаларның сөйләмен вакытында үстерү, аның чисталыгына һәм грамоталылыгына игътибар итү бик мөһим. Баланың сөйләме никадәр баерак һәм дөресрәк булса, аңа үз фикерләрен әйтү шулкадәр җиңелрәк, аның чынбарлыкны танып белү мөмкинлеге шулкадәр киңрәк, балалар һәм өлкәннәр белән мөнәсәбәтләре эчтәлекле һәм тулырак, аның психик үсеше шулкадәр активрак бара.

Туган телләрен яхшырак белгән саен, алар үз фикерләрен телдән һәм язма сөйләмдә яктырак, матуррак һәм баерак белдерәләр. Тирә-юнь дөньясы һәм кеше эшчәнлеге турында беренчел мәгълүматны балалар туган телләре аша алалар, алар өйдә, сыйныфта, урамда аралашалар. Шуңа күрә мәктәпнең иң беренче бурычы-балаларны туган телләрен яхшы белергә өйрәтү.

Туган телләрне саклау һәм үстерү бурычын мәгариф системасына гына йөкләү, аны башка тәрбия институтларыннан, аерым алганда гаиләдән, беренче чиратта ата-аналардан алу, димәк, безнең телләрне ясалма яшәүгә яки юкка чыгуга дучар итү. Ә бүген бу бурычларны нигездә уку йортлары һәм мәдәният учреждениеләре генә хәл итә. Әмма телне көч кулланып саклап булмый, аны саклап калырга мөмкин, туган телне яраталар, бу телдә сөйләшәләр, аның белән горурланалар, ә мәхәббәт хисе гаиләдә генә урнаштырыла ала.

Туган телне өйрәнү проблемалары укучыларның милли үзаңын формалаштыру мәсьәләләре белән бәйле. Аларны чишү кирәклеге бүгенге дәресләребезнең характерына тәэсир итми кала алмый дип уйлыйм.

Беренчедән, дөньяга караш белән бәйле сорау бик кискен тора. Туган тел һәм сөйләм милли тормышның аерым чынбарлыкларын тапшыра, күп гасырлык тарихы бар. Бу фольклорда һәм сүз осталарының әсәрләрендә чагылдырылган мәдәни мирас.

Икенчедән, бүгенге көннең иң үзенчәлекле омтылышы – җәмгыятьне һәм мәктәп укуын гуманизацияләү юлларын эзләү. Шуңа күрә туган телебезне өйрәнүгә кызыксыну тудыру – бу әле дә безнең фәнне укытуның көнүзәк мәсьәләләренең берсе. Туган телне камилләштерү омтылышының иң мөһим двигателе булып әкренләп формалашкан аң тора, милли тел өйрәнү предметы гына түгел, ә горурлык предметы, моңа аерым эмоциональ мөнәсәбәт. Туган телдә, Туган тел аша балалар милли тормышны өйрәнәләр, халыкның мәдәни мирасына кушылалар, уку предметы аша "туган тел" тел традицияләрен һәм закончалыкларын үзләштерәләр. Һәм шул вакытта укучыларның үз телләрендә генә түгел, ә үзләре дә үзенчәлекле, тере һәм табигый телдә сөйләшәләр дигән ышануларын үзләштерү бурычы беренче планга чыга.

Туган тел дәресләрендә якташлар һәм якташлар турында тере сүз Кече ватан дип аталганнарга кызыксыну уята, аның тарихы һәм бүгенге көн турында күзаллауны киңәйтә.

Шуңа бәйле рәвештә, уку-тәрбия процессында халыкның яшәү рәвеше, кыйммәтләре һәм психологиясе белән бәйле. Минемчә, уку һәм сыйныфтан тыш эшләрдә прогрессив халык традицияләрен системалы куллану зур һәм көтелгән нәтиҗәгә китерергә мөмкин.

Мәгариф идарәсе органнарының, мәгариф учреждениеләренең һәм фәнни учреждениеләрнең тыгыз хезмәттәшлеге; туган телләрне укытуда инновацион алымнарны кертү буенча эшне активлаштыру; туган телләрне укытуны фәнни, методик һәм психологик-педагогик тәэмин итү системасын үстерү буенча эшне дәвам итү.

Туган телләр буенча мәктәпнең матди-техник базасы ярлы булуы да актуаль булып кала. Башка дисциплиналардан аермалы буларак, бүген дидактик, методик материаллар аз чыгарыла. Туган телне үстерү белән шөгыльләнүче укытучылар контингенты бик кечкенә, туган телләрне өйрәнүнең теоретик һәм методик нигезләрен яхшы белә.

Шулай ук мультимедия программалары, УМК, сөйләм дәрәҗәсендә күрсәтелгән фәннәрне өйрәнергә мөмкинлек бирүче факультатив курслар

программалары; техник укыту чаралары, дидактик материаллар һәм күзаллау чаралары (күрү, тавыш), туган телләр һәм әдәбият буенча методик журналлар булмау, бу методик эш тәҗрибәсе белән уртаклашу, аны тарату һәм гомумиләштерү мөмкинлеген чикли.

Компьютер мәгълүматлары, видеомәгълүмат, сөйләм, музыкасы булган мультимедия продуктлары җитми яки бөтенләй юк, анда тамашачы һәм мультимедия продуктларын тыңлаучы пассив булып калмый, туган телдәге уку мәгълүматлары язма текст белән дә, сөйләм белән дә, видео сюжет һәм музыкаль озата бару белән дә бирелә ала. Санлы мәгариф ресурсларын куллану өйрәнүдә индивидуаль һәм дифференциаль алымны яхшырак кулланырга мөмкинлек бирә дип саныйм.

Туган телләрне өйрәнү проблемаларын хәл итү максатыннан, дәресләрнең сыйфат дәрәҗәсен күтәрү, дәресләрне, дәрестән тыш һәм мәктәптән тыш чараларны төрлеләштерү; предметлар арасындагы элемтәләрне, бигрәк тә тарих, сынлы сәнгать, музыка, театр белән оста алып бара.

Безнең өчен мөһим проблема-мәктәп китапханәләрендә җитәрлек сүзлекләр булмау, сыйныфтан тыш әдәбият яңартылмавы, өстәмә уку материаллары, уку-күрсәтү әсбаплары аз. Без мультфильмнар кулланабыз, ләкин алар да бик аз.

Әгәр дә без балаларыбызның туган телләрен яхшырак белүләрен телибез икән, аларның статусын күтәрергә.

Туган телне яхшырак үзләштерүдә, аны өйрәнүгә кызыксынуны стимуллаштыруда конкурслар, олимпиадалар, түгәрәк өстәлләр, семинарлар, фәнни-гамәли конференцияләр зур роль уйный.

Төп юнәлешләрнең берсе буларак сәләтле балалар белән эшләүне тәкъдим итәсем килә. Талантлы яшьләргә ярдәм итү сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү һәм һәр баланың сәләтләрен күрсәтү һәм үстерү өчен мохит формалаштыру буенча махсус система булдыруны күздә тота.

Без укытучыларны һәм укучыларны өстәмә грамоталар, Рәхмәт хатлары белән стимуллаштырырга тырышабыз.

Югарыда әйтелгән шартларны, һәм факторларны шартлы рәвештә түбәндәгечә гомумиләштерергә мөмкин:

* Дәреслекләр, сүзлекләр, сыйныфтан тыш әдәбият һәм шул исәптән милли халык әкиятләре (бигрәк тә төсле иллюстрацияле), нәфис әсәрләр, уку-методик, уку-күрсәтү материаллары бик аз.

* туган телләрдә мультфильмнар яңартылмый.

* Күпчелек ата-аналарның балаларының туган телләрен өйрәнүгә пассив мөнәсәбәте.

* Җәмәгать эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә туган телләрнең гамәли ихтыяҗы җитәрлек түгел.

Мәдәниятебезне, туган җиребезне, бай тарихы һәм кабатланмас традицияләре булган телебезне саклыйк!

Хурамшина Айсылу Масхут кызы
Арча муниципаль районы
«Югары - Аты балалар бакчасы» муниципаль
бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе
тәрбиячесе

# МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫ ГРАМОТАГА ӘЗЕРЛӘҮНЕҢ АСЫЛЫ

**Аннотация:** В данной статье рассматривается опыт работы по обучению грамоте детей дошкольного возраста. Звуковая культура речи – основа подготовки детей к обучению грамоте. Чтобы сделать обучение грамоте в школе более успешным, необходимо часть умений формировать в детском саду.

**Ключевые слова:** речь, дошкольник, грамотность, обучение, воспитание, культура речи.

**Abstract:** This article discusses the experience of teaching literacy to preschool children. The sound culture of speech is the basis for preparing children for literacy. To make literacy training at school more successful, it is necessary to form part of the skills in kindergarten.

**Keywords:** speech, preschooler, literacy, education, upbringing, culture of speech.

Грамотага өйрәтүнең төп бурычы – баланы укый һәм яза белергә өйрәтү.

Грамотлык – текстлар уку һәм яза белү, үз фикереңне язма рәвештә башкаларга җиткерү.Грамотага өйрәтү өчен нигез булып балаларның гомуми үсеше тора. Шуңа күрә грамотага әзерлек вакытында балалар бакчасында сөйләм телен, сүзлек, сөйләмнең грамматик ягын үстерү, сөйләм культурасын тәрбияләү мөһим. Баланы грамотага өйрәтү сөйләм эшчәнлеге белән бергә алып барыла.

Грамотага ия булу – катлаулы акыл эшчәнлеге. Ул баланың күп кенә психик функцияләренең җитлеккән булуыын таләп итә. Мәктәптә грамота алу өчен һәр бала өлкән мәктәпкәчә яшьтә булырга тиеш, билгеле бер дәрәҗәдә когнитив, мотор, тел, шәхси үзлекләр формалашу шарт. 6-7 яшьлек балаларның сөйләм үсеше бүлекләренең берсе “грамотага әзерлек” булып тора. Ул төрле юнәлешләрдә тормышка ашырыла төрле эшчәнлек төрләре, шул исәптән грамотага өйрәтү дәресләрендә дә.

Билгеле, грамотага өйрәтү баланың гомумсөйләм үсешенә нигезләнә. Шуңа күрә укырга өйрәтергә әзерләнгәндә баланың барлык сөйләм процессы мөһим роль уйный: бәйләнешле сөйләм үсеше, сүзлек байлыгы, сөйләменең грамматик төзелеше, авазларның дөрес әйтелеше. Педагоглар фикеренчә, сөйләм үсеше камил булган балалар грамматиканы һәм башка предметларны тиз һәм уңышлы үзләштерәләр.

Сөйләм рефлекциясе, ирекле сөйләм формалаштыру да язма сөйләм формалаштыруда әһәмиятле аспект. Бу үзенчәлек баланың мәктәпкә психологик әзерлегенең төп өлешен тәшкил итә. Сөйләмне ирекле һәм аңлы төзү язма сөйләмнең психологик характерын билгели.

Сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре формалаштыру, тел һәм сөйләм күренешләрен тану – сөйләм үсешенең бәйләнешле яклары. Максатчан рәвештә грамотага өйрәтү, сөйләм турында элементар белемнәр сөйләмне ирекле һәм аңлы кулланырга өйрәтә. Ә бу исә баланың бәйләнешле сөйләм үсешенә тәэсир итә. Шулай итеп балалар бакчасында сөйләм үсеше һәм грамотага өйрәтү арасында ике яклы бәйләнеш хасил була.

Механик уку һәм язу хәзерге психологиядә кодлаштыру (кодирование) һәм кодлаштыру алды (декодирование) процессы дип карала. Телдән сөйләмдә һәр сүзнең мәгънәсе аерым авазлар комплексында кодлаштырылган. Ә язма сөйләмдә телдән сөйләмгә яраклаштырылган аерым код (хәрефләр). Бер кодтан икенчесенә күчү яңадан кодлаштыру дип атала. Уку – хәрефләр кодын аваз яңгырашына, ә язуны телдән сөйләмгә кодлаштыру ул.

Д.Б. Эльконин күрсәткәнчә, уку механикасы теге яки бу телнең язу системасы белән билгеләнә.

Рус графикасына нигезләнгән хәзерге татар язуындагы хәрефләр авазларны белдерсәләр дә, сүздәге авазлар белән хәрефләр арасында тулы тәңгәллек юк. Укырга-язарга керешкән бала иң элек сөйләм авазларын хәрефләр белән күрсәтә белергә (сүз төзергә яки язарга) һәм хәрефләр буенча җанлы сөйләм авазларын сөйләткәндәгечә әйтергә (укырга) өйрәнә. Шуңа күрә грамотага өйрәнүче бала башта аваз белән хәрефне аера белергә тиеш.

Өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларны мәктәпкә әзерлек буенча укыту грамотасына түбәндәгеләр кирә:

- балаларны сүз белән таныштыру, сүз ачыклау. Аны мөстәкыйль мәгънә бирәмлегеннән сөйләм агымына кертеп җибәрү;
- яңа материалны үзләштерү, дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү, уку эшчәнлеген оештыра белү;
- сүзләрнең аваз төзелеше белән танышу;
- хәрефләр белән танышу.

Бу эштә иң мөһиме – сәләтне формалаштыру

Алда әйтелгәннәрдән чыгып, балалар бакчасы педагоглары алдында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны китап укуга өйрәтү бурычы куела. Бу күнекмәләрне аларга мәктәптә, шул ук вакытта балалар бакчасында да үзләштерергә туры киләчәк.

Кулланылган әдәбият


6. Алексеева М.М. Методика развития речи и обучения родному языку дошкольников /М.М.Алексеева, В.И.Яшина. – М.: 2020. – 400 с.
7. Сафиуллина Г. Мәктәпкәчә белем бирү стандарты: таләпләр һәм мөмкинлекләр // Мәгариф. . – 2014. – № 12. – Б. 11- 14
8. Театр уйнап үсәбез: балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр өчен ярдәмлек /Төз.: А.Т.Хуҗина. – Яр Чаллы, 2009. – 58 б.

# СЕКЦИЯ 8. НАСТАВНИЧЕСТВО КАК ЭФФЕКТИВНАЯ ФОРМА ПОМОЩИ МОЛОДЫМ СПЕЦИАЛИСТАМ

# 8 НЧЕ СЕКЦИЯ. ЯШЬ БЕЛГЕЧЛӘРГӘ ЭФФЕКТИВ ЯРДӘМ ФОРМАСЫ БУЛАРАК ОСТАЗЛЫК

Абдуллина Ю.И.
МБДОУ «Арский детский сад №2» Арского муниципального района РТ,
музыкальный руководитель

## НАСТАВНИЧЕСТВО, КАК ОДИН ИЗ ФАКТОРОВ СТАНОВЛЕНИЯ МОЛОДОГО ПЕДАГОГА

Работа, связанная с преподаванием, всегда считалась одним из наиболее сложных и в то же время почетных занятий.

Преподавательская деятельность – это сложный и последовательный труд от организации студентов до написания исследовательских работ. Преподавателю необходимо знать технологические приёмы работы по профилю своей специальности, основы педагогики, психологии, а также законодательные документы по вопросам образования. Поэтому и спрос с преподавателей особый. Человек, решивший стать преподавателем, должен быть готов к тому, что ему придется преодолевать множество трудностей и, несмотря на это, двигаться вперед.

Современный педагог – это активная, компетентная личность, отличающаяся мобильностью, постоянно совершенствующая свой профессиональный уровень. Но в самом начале педагогической деятельности молодой преподаватель испытывает различные трудности в профессиональном становлении.

Начиная свою педагогическую деятельность, обычно молодой педагог теряется. Даже при достаточных знаниях предмета молодому преподавателю не хватает педагогического опыта. Он сталкивается с различными трудностями. Основные проблемы, с которыми сталкивались молодые преподаватели нашего техникума, - это сложность в ведении документации, рассчитать время на занятии и неуверенность во время выступления перед большой аудиторией. Что помогло молодым специалистам адаптироваться к новым условиям работы? Ответ был практически у всех один: помощь и советы коллег.

Молодой преподаватель должен чувствовать постоянную поддержку старших, опытных наставников: администрации, преподавателей-коллег, кураторов. Ведь все они могут помочь новичку в календарно-тематическом планировании, рассказать о специфике работы со студентами и поделиться

опытом многими другими способами. Ведь каждый из них - мастер своего дела. Молодому специалисту необходима постоянная товарищеская помощь.

Наставничество - процесс передачи опыта и знаний от старших к младшим членам общества; форма взаимоотношений между учителем и учеником. Наставничество в широком смысле присуще всем формам обучения и системам образования. В отечественной практике получило развитие массовое движение наставничества в системе профессионально-технического образования и производственного обучения.

Педагогическое наставничество – форма передачи педагогического опыта, в ходе которой начинающий педагог практически осваивает профессиональные приемы под непосредственным руководством педагога-мастера.

Наставничество – это двусторонний процесс, при этом системно организованное наставничество предполагает передачу педагогического опыта и одновременно открывает возможности для самообразования и повышения квалификации самого наставника.

Наставник – высококвалифицированный специалист или опытный работник, у которого другие работники могут получать совет и поддержку.

Наставничество — одна из наиболее эффективных форм профессиональной адаптации молодых учителей, способствующая закреплению педагогических кадров. Задача наставника — помочь молодому преподавателю реализовать себя в профессии.

Особенностью труда начинающих педагогов является то, что они с первого дня работы имеют те же самые обязанности и несут ту же ответственность, что и опытные коллеги, а обучающиеся, сотрудники, руководство ожидают от них столь же безупречного профессионализма. Решение задач профессионального становления молодого специалиста, полного освоения педагогической профессии, адаптации в трудовом коллективе, налаживания педагогических контактов возможно через создание системы наставничества в рамках образовательного учреждения.

Основными категориями процесса наставничества являются развитие, воспитание и профессиональная адаптация человека в трудовой производственной деятельности. Под развитием человека понимается процесс становления его личности под влиянием внешних и внутренних, управляемых и неуправляемых социальных и природных факторов. Под воспитанием – целенаправленный процесс формирования интеллекта, физических и духовных сил личности, подготовки ее к жизни, активному участию в трудовой деятельности. Под профессиональной адаптацией понимается процесс приспособления (привыкания) человека к содержанию, условиям, организации и режиму труда, к коллективу. Успешная профессиональная адаптация является одним из показателей обоснованности выбора профессии и способствует развитию положительного отношения работника к своей деятельности, сближению общественной и личной мотивации трудовой деятельности .

Для молодого специалиста вхождение в новую деятельность сопровождается высоким эмоциональным напряжением, требующим

мобилизации всех внутренних ресурсов. Решить эту стратегическую задачу поможет создание гибкой и мобильной системы наставничества. В этой системе отражена жизненная необходимость молодого специалиста получить поддержку опытного педагога-наставника, который готов оказать ему практическую и теоретическую помощь на рабочем месте и повысить его профессиональную компетентность. Задача наставника – помочь молодому специалисту реализовать себя, развить личностные качества, коммуникативные и управленческие умения.

Таким образом, профессиональная адаптация личности напрямую зависит от уровня педагогического мастерства, опыта и знаний наставника.

Но при назначении наставника мы стараемся учитывать обоюдное согласие наставника и молодого специалиста в совместной работе.

Основное содержание педагогического наставничества заключается в оказании помощи молодым специалистам при изучении нормативно-правовых документов; изучении и внедрении в практику образовательной организации передового педагогического опыта; совершенствовании теоретических знаний и практических умений, педагогического мастерства; ознакомлении с новыми достижениями психолого-педагогических наук и методики преподавания предмета; овладении учебным материалом и организации собственного учебно-познавательного процесса; овладении новыми формами и методами оценивания учебных достижений обучающихся; изучении индивидуальных особенностей студентов.

Наставничество – это постоянный диалог, межличностная коммуникация, следовательно, наставник прежде всего должен быть терпеливым и целеустремленным.

Молодые и малоопытные преподаватели получают поддержку наставника, который способен предложить практическую и теоретическую помощь на рабочем месте. При этом используются разнообразные формы взаимодействия друг с другом, например: совместное планирование будущего рабочего дня и подведение итогов предыдущего; помощь наставника при составлении подробного конспекта занятия помогает выбрать оптимальные методы и приемы, которые будут наиболее приемлемы в данное время.

Одна из главных целей моей работы – оказание помощи в организации педагогического процесса, пополнению багажа теоретических знаний молодых педагогов, развитию навыков практического применения полученных знаний. Поэтому с помощью диагностики, анализа, выводов и рекомендаций оказываю методическую помощь молодым специалистам. Наставник должен быть максимально тактичным в своих высказываниях, особенно если они носят критический характер. Здесь я руководствуюсь принципом Теодора Рузвельта: "Не ошибается лишь тот, кто ничего не делает. Не бойтесь ошибаться – бойтесь повторять ошибки". Молодой преподаватель испытывает потребность в своевременной положительной оценке своего труда, поэтому заметив его педагогические успехи, непременно отмечаем их на заседаниях цикловых комиссий, педагогических советах. Ведь похвала поднимает настроение, стимулирует, вселяет уверенность, повышает интерес к делу. В таких условиях

начинающий преподаватель быстро и безболезненно входит в педагогический коллектив.

Мои основные задачи в рамках наставничества:

- способствовать формированию потребности заниматься самоанализом результатов своей профессиональной деятельности;

- показывать собственный положительный пример в поиске научных знаний, в готовности передавать их подрастающему поколению;

- способствовать формированию приемов педагогического контроля и самоконтроля молодого специалиста;

- ориентировать начинающего преподавателя на творческое использование передового педагогического опыта в своей педагогической деятельности;

- привить молодому специалисту интерес к педагогической деятельности;

- ускорить процесс профессионального становления преподавателя и развитие способности самостоятельно и качественно выполнять возложенные на него обязанности по занимаемой должности.

Литература

Бим-Бад Б. М. Педагогический энциклопедический словарь. — М., 2002. С. 162.

1. И. Круглова «Наставничество в повышении профессиональной компетентности молодого учителя»/ Журнал «Народное образование» № 9, 2009г.
2. Кибанов А. Я. Управление персоналом организации. М.: ИНФРА-М, 2003.
3. Мороз А. Г. Адаптация молодого учителя. Киев, 1990.
4. Педагогика: Большая современная энциклопедия [Текст] /сост. Е.С. Рапацевич. – Мн.: «Соврем. Слово», 2005. – 720 с.
5. Райзберг Б.А., Лозовский Л.Ш., Стародубцева Е.Б. Современный экономический словарь. 2 е изд., испр. М.: ИНФРА М. 479 с.

Ахмадуллина Г.И.
МБОУ “Смак-Корсинская СОШ”
Арского района , учитель начальных классов

## ЯШЬ БЕЛГЕЧЛӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮНЕҢ НӘТИҖӘЛЕ ФОРМАСЫ БУЛАРАК ОСТАЗЛЫК

**Аннотация:** В настоящее время тема наставничества в образовании является одной из центральных в нацпроекте «Образование». Наставничество в образовании — важнейшее условие в профессиональном становлении молодого учителя, инструмент в развитии профессиональных компетенций педагога, в повышении его педагогического мастерства. В самом общем виде наставничество можно определить, как способ передачи знаний, навыков и установок от более опытного человека – менее опытному. Традиционно в образовательных организациях распространена такая практика наставничества,

как работа с начинающими, вновь прибывшими педагогами. Опыт организации наставничества в нашей школе показывает, что наставническая среда может и должна охватывать не только молодых специалистов, а в идеале, всех участников образовательного процесса.

**Ключевые слова:** остаз, киңәш, тәкъдим, критерийлар, күрсәткечләр.

***" Үзең өйрәнүгә караганда башканы өйрәтер өчен, күбрәк акыл кирәк" М. Монтень***

2023 ел педагог һәм остаз елы итеп билгеләнде. Шуңа бәйле рәвештә остазлык темасы Мәгариф өлкәсендә төп темаларның берсе булып тора.

Россиядә мәгариф системасын модернизацияләү шартларында остазлык системасы белем бирү сыйфатын арттыру коралы һәм яшь педагогларны адаптацияләү механизмы буларак тора. Остазлык системасы ул - буыннар дәвамлылыгы формасы, һөнәри тәҗрибә тапшыру процессын гамәлгә ашыручы социаль институт. Бу һөнәри адаптациянең иң нәтиҗәле формаларының берсе, ул һөнәри компетентлыкны арттыруга һәм педагогик кадрларны ныгытуга ярдәм итә.

Остазлык - тәҗрибәле яки белемлерәк кеше тәҗрибәсезрәк яки белемсезрәк кешегә билгеле бер компетенцияләрне үзләштерергә ярдәм итә торган мөнәсәбәтләр.

Остазлык - мәгариф учреждениеләрендә педагогик эшчәнлектә хезмәт стажы булмаган яшь белгечләр белән яки алар эш тәҗрибәсе булмаган вазифага билгеләнгән белгечләр белән шәхси тәрбия эше.

Остазлыкның максаты - яшь белгечләргә һөнәри формалашуда ярдәм күрсәтү, яшь белгечне хезмәт процессына һәм иҗтимагый тормышка тыгыз җәлеп итү, башлангыч педагогның һөнәри компетенциясен арттыру. Яшь белгечкә тәҗрибәле педагог – укытучы ягыннан ярдәм кирәк, ул аңа практик ярдәм күрсәтә, аның теоретик һәм һөнәри компетентлыгын арттыра ала. Остаз өчен яшь белгеч белән эшләү - үз-үзеңне тормышка ашыру ысулы, квалификация күтәрү, һөнәри компетенциянең югарырак дәрәҗәсенә чыгу.

Максат: яшь белгечләр өчен үз-үзләрен тормышка ашыру буенча шартлар тудыру, педагогик эшчәнлек өчен кирәкле гамәли күнекмәләр алу, яшь белгечләрне коллективта ныгыту.

Бурычлар: педагогик коллективта яшь педагогларга ярдәм атмосферасы булдыру, практик эшчәнлек күнекмәләрен үзләштерүдә, уку эшчәнлеген планлаштыруда һәм оештыруда ярдәм күрсәтү.

Төп принциплар:

Кешегә хөрмәт һәм ышаныч принцибы.
Бөтенлек принцибы.
Хезмәттәшлек принцибы.
Индивидуальлек принцибы

Эшнең төп юнәлешләре:

Предмет буенча эшне планлаштыру һәм оештыру.
Тәрбия эшен планлаштыру һәм оештыру.
Документлар белән эшләү.

Үз-үзеңне укыту эше.
Яшь белгечнең эшчәнлеген контрольдә тоту һәм җитәкчелек итү.
Психологик-педагогик ярдәм.

Яшь белгеч белән эшләү этаплары

1 этап - адаптацион
2 этап - төп проектлау
3 этап - контроль-бәяләү

Остазлыкның көтелгән нәтиҗәләренә түбәндәгеләр керә: яшь белгечләрне белем бирү оешмасы коллективына беркетү, яшь белгечләрдә белем алу ихтыяҗын формалаштыру.

Яшь педагог белән аралашу конструктив булсын һәм кирәкле нәтиҗәләр китерсен өчен, педагог – укытучыга аралашуның кайбер кагыйдәләрен истә тотарга кирәк: боерык бирмәскә («сез тиеш»), вәгазьләмәскә («сезнең өстегездә җаваплылык ята»), үгетләмәскә («әгәр сез мине тыңласагыз»). Укытучы яшь педагогка профессиональ ярдәм процессын стимуллаштырырга тиеш. Тәрбияләнүченең шәхси җиңүе-остазның уңышы һәм, ахыр чиктә, бөтен мәгариф системасының уңышы. Шәхес һәм һөнәри шәхес очкынын тапкан һәм кабызган яшь кешенең эшчәнлеге мәгарифнең прогрессив үсешенә ярдәм итә. *"Укытучы укыганда яши, әгәр ул укуын туктатса үлә».* Бөек педагог Константин Ушинскийның бу сүзләре остаз һәм яшь педагогның лейтмотивы

Остазларны сайлап алу критерийлары һәм күрсәткечләре :

Укытучыларның гомуми һәм мәҗбүри критерийлары булып:
- остаз, куратор булырга шәхси теләк булу (хәтта аны администрация яки коллектив тәкъдим иткән очракта да);
- төп компетенцияләрнең югары үсеш дәрәҗәсе:
• башкаларны үстерү сәләте,
• тирә-юньдәгеләр белән мөнәсәбәтләр төзү сәләте,
• җаваплылык,
• нәтиҗәгә юнәлеш,
• башкаларны дәртләндерә һәм рухландыра белү,
• үзендә профессиональ һәм шәхси үсеш сәләте булу.

Остазлар булып югары һөнәри сыйфатларга , эштә тотрыклы күрсәткечләргә , югары яки урта махсус белемгә ия, педагогик эш стажы 5 елдан да ким булмаган укытучылар тора ала.

Тәрбияче булырга мөмкин:

Эш тәҗрибәсе аз булган яшь белгеч , уку процессын оештыруда, укучылар, педагоглар яки администрация белән үзара хезмәттәшлектә кыенлыклар кичергән. яңа эш урынында адаптация процессында булган белгеч, эмоциональ яну, хроник арыганлык хәлендә булган педагог.

Остаз эше өчен кирәкле документлар:

«Яшь белгеч белән эшне оештыру турында»боерык.
Остазлык турында нигезләмә.
Яшь белгечләр белән эшләү планы.
Остазга методик киңәшләр.

Яшь укытучының адаптациясен контрольдә тотуның аналитик документациясе.

Остазның башкарылган эш турында хисаплары: предмет-цикл комиссиясе утырышы, методик совет утырышында карала.

Остазларга киңәшләр һәм тәкъдимнәр :

Остазга тәкъдимнәр:

1. Тәҗрибәне бушлай, үгет-нәсыйхәтсез, игелекле итеп уртаклашу.
2. Сабыр булып, үз вакытында, ныклап ярдәм итү. Эштә уңай якларны билгеләргә беркайчан да онытмаска кирәк.
3. Яшь укытучының дәресләренә йөрү, анализлау, уңай динамиканы билгеләү, аны үз дәресләренә чакыру, бергәләп фикер алышу.
4. Яшь белгеч белән ярышып эшләү. Дәресләргә әзерләнүдә, бигрәк тә беренчеләренә ярдәм күрсәтү. Иң авыр темаларны бергә эшләү. Яшь укытучыга иң катлаулы темаларны методик рәвештә ачу мөмкинлеге бирү өчен, материалны берничә дәрескә алдарак өйрәнергә тырышу.
5. Яшь белгеч белән уку программаларын һәм аларга аңлатма язуларын җентекләп анализлау. Һәр чирек ахырында, уку елы ахырында, уку курсы ахырында фәннәр буенча белем бирү программасын үзләштерүнең предмет нәтиҗәләрен анализлау.
6. Дидактик материалны, күрсәтмә әсбапларны, бирем текстларын, күнегүләрне, контроль эшләрне ничек әзерләргә һәм сайларга икәнен күрсәтү.
7. Үз-үзеңне укыту планын (айлык план-график) төзергә һәм үз-үзеңне укыту өчен методик әдәбият сайларга ярдәм итү.

Укытучылар өчен киңәшләр "Ничек уңышлы остаз булырга?"

1. Шәкертләреңә остаз бул. Укучының шәхесен үстерүдә диагност һәм ярдәмче бул.
2. Үз шәкертләреңнең хәтта кечкенә уңышларына да шатлана һәм аларның уңышсызлыкларына теләктәшлек күрсәтә бел.
3. Авторитар булма: иҗат, хезмәттәшлек һәм уңай энергия үз җимешләрен бирәчәк.
4. Гомер буе өйрәнергә һәм үз өстеңдә эшләргә әзер бул.
5. Дәресләр шаблонлы һәм стандарт булмасын өчен тырыш (күңелсез): балага дәрестә кызык булырга тиеш.
6. Сезнең һәр дәрес кечкенә булса да, алга таба бер адым булырга тиеш. Укучыларыңны яңа казанышларга этәр.
7. Үз шәкертләреңне үз алдыңа лаеклы максатлар куярга һәм эшне логик ахырына җиткерергә өйрәт. Шәкертләрең өчен эзлекле бул.
8. Балага ышаныгыз. Аңа канатлар бир. Аңа өмет бир. Үзеңне уку процессында актив катнашучы итеп хис ит.
9. Берәр сорауны белмәвеңне таныырга курыкма. Балалар белән бергә эзләгез.
10. Шәкертләреңнең абруен төшермә: аларның һәрберсе шәхес.

Кулланылган әдәбият исемлеге

Интернет ресурслар:

https://infourok.ru/razrabotka-na-temu-praktika-nastavnichestva-v-obrazovatelnoj-organizaciii-6128814.html
https://multiurok.ru/files/nastavnichestvo-kak-effektivnyi-metod-professional.html
https://infourok.ru/pamyatki_sovety_molodomu_uchitelyu-317002.htm

Багавиева Н.С.
РТ, Высокогорский район,
учитель начальных классов
МБОУ «Большебитаманской ООШ»

# АВТОМАТИЗАЦИЯ СЛОГОСЛИЯНИЯ

Цель: Научить правильно, быстро собирать слоги на начальном этапе обучения.

**Аннотация:** В букварный период на уроках обучения грамоте основные усилия сосредоточиваю на формировании и автоматизации навыков слогослияния или чтения целыми словами, поскольку слогослияние представляет для детей наибольшую трудность. При простом знакомстве с буквой ребенок связывает с ней только одно типовое звучание. В процессе же чтения слогов или слов этой букве соответствуют различные звучания в зависимости от последующих звуков. Звук в потоке речи редуцируется и произносится нетождественно изолированному.

На начальном этапе овладения чтением, когда алфавит усвоен, основные усилия сосредоточивается на формировании и автоматизации навыков слогослияния или чтения целыми словами. Анализ результатов показывает, что при своевременном начале работы (1-2-йкласс) положительного эффекта удается достичь в 60-70% .

1. Дети, не владеющие слогослиянием, пытаются угадывать нужный слог, опираясь на смысловой и звуковой контекст. Это порождает большое количество ошибок и тормозит перестройку навыка чтения. Чтобы избежать этого, целесообразно на начальном этапе использовать слоговой материал. В этом случае угадывание становится невозможным. Ребенок вынужден опираться при выполнении задания только на навык слогослияния. Для этого используется слоговые таблицы.

| | | |
|---|---|---|
| МА | ОК | ИМ |
| УМ | МИ | ГО |
| КО | АМ | МУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| БА | СО | АП | ЕЛ |
| ЛЕ | ИЛ | СА | ПУ |
| БУ | ЛИ | БЕ | ЗО |
| БУ | ЛИ | БЕ | ЗО |
| ОС | БИ | ПА | АС |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| МЕ | АШ | РИ | АМ | КУ | ЛЕ |
| ОМ | СУ | ВЕ | СИ | ОК | ПИ |
| ТУ | ОР | ИМ | ЛЯ | УС | ДО |
| ТУ | ОР | ИМ | ЛЯ | УС | ДО |
| ШИ | УК | РУ | ВЕ | ИЛ | ЧУ |
| ХА | ДИ | ИК | ЛИ | ИР | СО |
| СЕ | ПО | ША | РО | МИ | УТ |

Педагог в случайном порядке называет слоги таблицы и предлагает ребенку максимально быстро указать соответствующий слог в таблице и прочитать его. При этом слитно прочтение найденного слога облегчает предшествующим называнием его преподавателем. Требование быстро найти слог понуждает ребенка к глобальному его опознанию, что намного ускоряет поиск по сравнению с побуквенным прочтением каждого слога. В каждой таблице должен присутствовать как прямые, так и обратные слоги тоже буквенного состава (н-р:МОиОМ), с мягкими и твердыми согласными следует исключить , т. к. при произнесении они оглушаются

